# ШУРА

№ 38

2022




2000999960604

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . 5

Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . 11

ВӘГАЗЬЛӘР . . . 15

Пәйгамбәребез – Мөхәммәд Әмин . . . 16

Аллаһыны һәм Пәйгамбәребезне ярату . . . 20

Изгелек кыл да, суга сал . . . 25

Сәламәтлек — Аллаһы бүләге . . . 30

Әл-Фатиха сүрәсе турында . . . 34

Хафизлар – Коръәннең былбыллары . . . 39

Фикерләүчеләр өчен аятьләр бар . . . 44

Җәмәгать белән намаз уку . . . 48

Нәфел намазларны укуның әһәмияте . . . 54

«Яшәр өчен ашыйм» . . . 59

Васыятьнамә һәм мирас . . . 64

Хәерле әҗәл бирсәң иде . . . 72

Киләчәккә план кору, үткәннәргә нәтиҗә ясау . . . 77

ҮРНӘК . . . 82

ЗАТЛАР . . . 82

Рабига Әл-Гадәвиянең тәкъвалыгы . . . 83

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ . . . 87

Исеме һәм хезмәте онытылмас Фаиз хәзрәт . . . 88

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . 95

Июль-июнь-сентябрь . . . 96

ТАРИХ . . . 117

Харбин шәһәрендә Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы билгеләп үтелгән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Гарәп географлары һәм сәяхәтчеләре Болгар хакында . . . . . . . . . 123

ФӘН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Әбү Хәнифәнең сәхабәләр белән күрешүе . . . . . . . . . . . . . . . . . 127

ТӘРБИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Әдәпләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Сөләйман галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Коръән сүрәләренең мәгънәви тәрҗемәләре . . . . . . . . . . . . . . . 147

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Гөнаһлардан үкенеп, Аллаһы Тәгаләгә кайту бүлеге . . . . . . . . . . . 166
Коръәндә үләннәрнең шифалы үзенчәлекләре турынданиләр әйтелгән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182

ӘДӘБИ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188

СӘХИФӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Иман нуры берүк сүнмәсен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Ихлас дога көче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196

**«ШУРА» дини альманах, №38**

*октябрь–декабрь 2022*
*рабигыль-әүвәл–җөмәдәл-ахыр 1444*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Айсылу Юлдашева

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ленар Хамматов

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ООО «Медиа Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштерен бастырылды.*
*Адрес: 420021, Казан шәһ., Г.Камал ур., 53-46.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 21.09.2022
Чыгу көне: 06.10.2022

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

______________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ
تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ۞
أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسْلَامُ ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ ۞
اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ
الرَّاحِمِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ ۞ مُحَمَّدٍ
وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ ۞ فَقَالَ
عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:
إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً ۞
اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ
إِبْرَاهِيمَ ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ ۞ كَمَا

بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ۞
اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللَّهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وَهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин», – дип әйтә.

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһү. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыйҙү билләһи: ________________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________
________________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйзү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә

вә Галийййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә'мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин», – дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[1] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

________________________________________________________________

[1] 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ______________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә

сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән,**

**[көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*14 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Пәйгамбәребез – Мөхәммәд Әмин

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, безне Үзенең күпме генә санасак та санап бетерә алмаслык сый-хөрмәтләрендә, киң нигъмәтләрендә яшәтүче бердәнбер Раббыбыз, җир һәм күкләрнең Раббысы, гыйбадәткә лаек булган Хак Илаһыбыз Аллаһы Тәгаләгә мең-мең шөкерләребез, барча мактауларыбыз, барча олуглауларыбыз булсын. Раббыбыз Аллаһы безне юктан бар кылды, безне шушы җир өстенә урнаштырды. Бөтен тирәюньне: җирне дә, күкне дә, җир һәм күк арасында булган бар нәрсәне безгә хезмәткә тапшырды. Безнең өчен Аллаһы иртә белән таңнарны аттыра, безнең өчен яңгырлар ява, безнең өчен хайваннар, кошлар, бөҗәкләр, балыклар һәм башка мәхлүкълар яши, безгә хезмәт итә. Аллаһының нигъмәтләрен күреп тә, аңлап та һәм, әлбәттә, шөкер итеп тә бетерә алмыйбыз, шуңа күрә Аллаһы Тәгаләгә тәүбә-истигъфарлар белән кайтабыз. Раббым, безне кичер, безнең рәхмәтсез, ваемсыз булуларыбызны, безнең шушы дөньяга бирелеп, күп вакытта Сиңа шөкер итәргә онытуларыбызны гафу ит! Син – Гафу итүче һәм без Сиңа ялварабыз.

Җирләргә һәм күкләргә Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәте булып килгән, безнең өчен балаларыбыздан да, әти-әниләребездән дә һәм үз-үзебездән дә сөеклерәк, кадерлерәк булган Аллаһының Расүле – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан догаларыбыз, Аллаһы Тәгаләнең сәламе һәм салаваты булсын!

Газиз дин кардәшләрем, иң элек үземне, аннары сезне тәкъвалыкка чакырам. Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен зурлагыз, Аллаһының әмерләренә буйсыныгыз, Аллаһының безгә харам кылган нәрсәләреннән ерак торыгыз, Аллаһы куйган чикләрне бозмагыз!

Барыбыз да белә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне – Мөхәммәд Әмин дип йөрткәннәр, чөнки ул гадел һәм үз сүзендә торучы кеше булган. Әле Ислам дине килгәнче үк, күпчелек кораешлеләр, дин килгәч хәтта Расүлебезгә каршы сугышучылар да, үзләренең байлыкларын Пәйгамбәребезгә саклау өчен калдыра торган булган. Һәм гадел, үз сүзен үтәүче булуы сәбәпле, Расүлебезгә «Әмин» исемен кушканнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне шулай ук «Әс-Сиддыйк» дип тә атаганнар, бу «ышанычлы» дигәнне аңлаткан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күркәм холыклы булуы белән аерылып торганын беләбез. Моңа дәлил итеп, имамӘн-Нәвави җыентыгындагы: «Мин күркәм холыкларны камиллеккә җиткерү өчен җибәрелдем», – дигән хәдисне китерергә мөмкин. Шуңа да Пәйгамбәребезгә карата булган мәхәббәт һәм ышаныч сәбәпле, аны Мөхәммәд Әмин, дип йөртә башлыйлар. «Әмин» дип, алдаламый, явыз гамәл кылмый торган, кешеләрнең күркәмлеген бәяли һәм ярата торган кешене атыйлар.

Пәйгамбәребезнең күркәм холкына тагын бер дәлил итеп, Аллаһының сүзләрен китерик. Раббыбыз:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

**«Сезнең өчен [бигрәк тә] Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм [курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә] Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә күркәм үрнәк бар»,** – дип әйтә.

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:21

Гарәпләрдә шундый гадәт була: әгәр берәр кеше һөҗүм итүче гаскәрне күрсә, тауга менеп, үзенең туганнарын кисәтә торган булган. Бер-

вакыт Пәйгамбәребез дә Сафа тавына менеп, кешеләрне чакыра. Кешеләр җыелгач, ул: «Әгәр мин, бу тау артында безгә һөҗүм итәргә әзерләнгән гаскәр басып тора, дип әйтсәм, сез миңа ышаныр идегезме?» – дип сорый. Җыелган халык: «Һичшиксез, ышанабыз», – дип җавап бирә. Шуннан соң Пәйгамбәребез аларны Ислам диненә чакырып: «Бу дөньяда «Ләә иләәһә илләллааһ» дигән сүздән дә бөегрәк сүз юк», – дип әйтә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әле пәйгамбәрлек килгәнче үк, хәзрәти Хәдичә радыяллаһу ганһәдә сату-алу эшләре белән шөгыльләнә торган була. Бервакыт ул Хәдичә радыяллаһу ганһәнең хезмәтчесе белән Шам шәһәренә сәүдә итәргә китә. Моңа кадәр сәфәргә чыккан кешеләр хуҗаларына аз гына акча белән кайта торган булган, ә Пәйгамбәребез ул малны ике тапкыр арттырып алып кайткан. Аннан тыш, һәр эштә дә гаделлек күрсәткән. Моны хәзрәти Хәдичәнең ярдәмчесе күреп алып, кайткач барысын да хуҗасына сөйләп күрсәтә. Хәдичә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребезнең шундый гадел, җаваплы, ышанычлы кеше булуына куана. Күп тә үтми, алар Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән никах укыталар.

Бүгенге көнгә карасак, күп кеше өчен сүз биреп тә, үтәмәү һәм боларга игътибарсызлык күрсәтү җиңел әйбергә әйләнде. Хәзерге вакытта әманәткә хыянәт итүләр еш очрый, әмма бу кешеләр гөнаһ турында уйлыймы икән?

Безнең мөселманлык телдә генә түгел, ә гамәлебездә булырга тиештер. Без барчасына да үрнәк булып, барысы белән дә тату яшәргә тырышырга тиеш. Аллаһы Тәгалә барыбызның да Пәйгамбәребез үрнәгендә яшәргә тырышуыбызны насыйп итсә иде. Әәмин!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илсур хәзрәт Таһиров,*

*Чирмешән Үзәк мәчетенең икенче имамы*

*21 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Аллаһыны һәм Пәйгамбәребезне ярату

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, безне Үзенең күпме генә санасак та санап бетерә алмаслык сый-хөрмәтләрендә, киң нигъмәтләрендә яшәтүче бердәнбер Раббыбыз, җир һәм күкләрнең Раббысы, гыйбадәткә лаек булган Хак Илаһыбыз Аллаһы Тәгаләгә мең-мең шөкерләребез, барча мактауларыбыз, барча олуглауларыбыз булсын. Раббыбыз Аллаһы безне юктан бар кылды, безне шушы җир өстенә урнаштырды. Бөтен тирәюньне: җирне дә, күкне дә, җир һәм күк арасында булган бар нәрсәне безгә хезмәткә тапшырды. Безнең өчен Аллаһы иртә белән таңнарны аттыра, безнең өчен яңгырлар ява, безнең өчен хайваннар, кошлар, бөҗәкләр, балыклар һәм башка мәхлүкълар яши, безгә хезмәт итә. Аллаһының нигъмәтләрен күреп тә, аңлап та һәм, әлбәттә, шөкер итеп тә бетерә алмыйбыз, шуңа күрә Аллаһы Тәгаләгә тәүбә-истигъфарлар белән кайтабыз. Раббым, безне кичер, безнең рәхмәтсез, ваемсыз булуларыбызны, безнең шушы дөньяга бирелеп, күп вакытта Сиңа шөкер итәргә онытуларыбызны гафу ит! Син – Гафу итүче һәм без Сиңа ялварабыз.

Җирләргә һәм күкләргә Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәте булып килгән, безнең өчен балаларыбыздан да, әти-әниләребездән дә һәм үз-үзебездән дә сөеклерәк, кадерлерәк булган Аллаһының Расүле – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан догаларыбыз, Аллаһы Тәгаләнең сәламе һәм салаваты булсын!

Газиз дин кардәшләрем, иң элек үземне, аннары сезне тәкъвалыкка чакырам. Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен зурлагыз, Аллаһының әмерләренә

буйсыныгыз, Аллаһының безгә харам кылган нәрсәләреннән ерак торыгыз, Аллаһы куйган чикләрне бозмагыз!

Без барыбыз да, Аллаһы Тәгаләне яратабыз, дибез, әмма безнең гамәлләребездә, эшләребездә бу бик аз күренә, чөнки без, Раббыбызны яратабыз, дисәк тә, Аның кушканнарына бик җиңел карыйбыз, намазларны вакытында укымыйбыз, Коръәни Кәримне кулга сирәк алабыз. Аллаһы Тәгаләне яратучы кеше, нинди генә эше булса да, гыйбадәтен онытырга тиеш түгел.

Безнең, Раббыбызны яратабыз, диюебез телдән әйтелә. Әмма Аллаһыны ярату – ул чын күңелдән, ихластан булырга тиеш. Без иң беренче үзебезнең Хуҗабызны, аннары Аның пәйгамбәрен, ә аннары гына әтиәнине яратабыз. Югыйсә, әниләребез безне бу дөньяга тудырды, ашатты, эчертте, киендерде, ләкин моңа карамастан, без барыбер Аллаһы Раббыбызны өстенрәк күреп яратырга тиешбез. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَأَنفِقُوا فِي سَبِيلِ اللَّهِ وَلَا تُلْقُوا بِأَيْدِيكُمْ إِلَى التَّهْلُكَةِ وَأَحْسِنُوا إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ

> **«Аллаһы юлында [малларыгызны мул итеп] сарыф итегез, ләкин [чиктән тыш исрафка керү яки Аллаһы юлында җиһад һәм сарыф итүдән качуыгыз аша] үз кулларыгыз белән [үзегезне] һәлакәткә ташламагыз һәм [бөтен гамәлләрегезне, шул исәптән мохтаҗларны каравыгызны да] ихсан кылыгыз! Һичшиксез, Аллаһы игелек кылучыларны сөя!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:195

Күп кеше, без Аллаһы кушканча яшибез, кушканнарын үтибез, Аны яратабыз, дип әйтә. Ә менә Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ مَن يَرْتَدَّ مِنكُمْ عَن دِينِهِ فَسَوْفَ يَأْتِي اللّهُ بِقَوْمٍ يُحِبُّهُمْ وَيُحِبُّونَهُ أَذِلَّةٍ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ أَعِزَّةٍ عَلَى الْكَافِرِينَ يُجَاهِدُونَ فِي سَبِيلِ اللّهِ وَلاَ يَخَافُونَ لَوْمَةَ لآئِمٍ ذَلِكَ فَضْلُ اللّهِ يُؤْتِيهِ مَن يَشَاء وَاللّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ

**«Ий иман китерүчеләр! Арагыздан кем дә булса [Ислам] диненнән [чыгып, кире кяферлегенә] кайтса, Аллаһы үзләрен сөя, алар да Аны сөя торган, мөэминнәргә карата тыйнак, кяферләргә карата каты торган бер җәмәгать китерер. Алар Аллаһы юлында тырышлык кылырлар һәм бернинди шелтәләүченең дә янауларыннан курыкмаслар. Бу – Аллаһының фазылы, Ул аны теләгәненә бирер. Аллаһы – чиксез Мәрхәмәт һәм Белемнәр иясе, [һәрнәрсәне] Белүче».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:54

Шулай ук Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمِنَ النَّاسِ مَن يَتَّخِذُ مِن دُونِ اللَّهِ أَندَادًا يُحِبُّونَهُمْ كَحُبِّ اللَّهِ وَالَّذِينَ آمَنُوا أَشَدُّ حُبًّا لِّلَّهِ وَلَوْ يَرَى الَّذِينَ ظَلَمُوا إِذْ يَرَوْنَ الْعَذَابَ أَنَّ الْقُوَّةَ لِلَّهِ جَمِيعًا وَأَنَّ اللَّهَ شَدِيدُ الْعَذَابِ

**«[Шулкадәр дәлилләрне күргәннән соң да] Кешеләр арасында Аллаһыдан башкаларны [илаһлыкта Аңа] тиң итеп алучылар бар һәм Аллаһыны сөйгән кебек аларны сөяләр. Иман китерүчеләрнең Аллаһыны сөюләре күпкә артыграк. [Аллаһыга ширек кушкан] Залимнәр [Ахирәттәге мәңгелек] газапны күргән чакта бөтен куәт Аллаһыныкы икәнен, Аллаһының газабы бик каты булганын [потларының аларны коткара алмаячакларын хәзердән үк] белсәләр иде!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:165

Пәйгамбәребез Ислам динендә Аллаһы ризалыгы өчен яратырга, үзеңнең мөселман кардәшеңне үз туганың сыман якын итәргә куша. Моңа дәлил итеп, Коръәни Кәримнән аять китерәбез:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ فَأَصْلِحُوا بَيْنَ أَخَوَيْكُمْ ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ

**«Һичшиксез, мөэминнәр – кардәшләр. Шуңа күрә кардәшләрегезне татулаштырыгыз. [Һәр эштә булганы кебек, дин кардәшләрегезнең араларын якынайтуны да җиңелгә алуда] Аллаһыдан куркыгыз, бәлки, рәхмәт ителерсез».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:10

Пәйгамбәребез: «Мине яратмасагыз, иманыгыз камил дәрәҗәдә булмас», – дигән.

Шулай ук без үзебезнең сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне дә яратырга тиеш. Ул барча кешеләрне Ислам диненә чакырып, үзенең өммәттен булдырды, безгә күп гыйлем биреп калдырды, без моның өчен дә шөкерле булыйк. Пәйгамбәребезнең сөннәтләрен үтәп, ул барган юлдан барырга, Кыямәт көнне аның шәфәгәтен сорап дога кылырга, Расүлебезнең шәфәгатенә омтылырга тиешбез. Раббыбыз Аллаһы Үзенең шушы аятьләрен тормышыбызда кулланып, Аның яраткан бәндәләреннән булуыбызны насыйп вә мөяссәр кылсын.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт

итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илсур хәзрәт Таһиров,*

*Чирмешән Үзәк мәчетенең икенче имамы*

*28 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Изгелек кыл да, суга сал

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык кылып, бүгенге көнгәчә тәрбияләп, ризыкландырып һәм киендереп торучы Аллаһыга барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз, Аллаһының хак Расүле, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы Мөхәммәд бине Габдулла салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез булсын.

Татар халкында шундый бер әйтем бар: «Изгелек кыл да, суга сал». Бу әйтем: яхшылык эшлә дә – оныт, дигәнне аңлата. Чыннан да, еш кына кешеләр синнән ярдәм хакында сорамаган көе ярдәм итүең, синең шәхси, чын күңелдән эшләнгән гамәлең булырга мөмкин. Суга ыргыту төшенчәсе тормышның «мәңгелек елгасы»на ыргыту дигәнне дә аңлатадыр. Яхшы эш югалмас, яхшылык сезгә әйләнеп кайтыр, дигән әйтемне дә күпләребез беләә.

Башка сүзләр белән әйткәндә, яхшылык кылганда, аның өчен рәхмәт көтмичә эшләп, аны шул зур «елга»га салабыз, безнең яхшылык ул «елга»да агым су белән таралып, күп кешеләрне сөендерә. Һәм, әлбәттә, ул яхшылык, без бернәрсә дә көтмәгән мизгелдә дә, без көтмәгән яктан әйләнеп кайтачак.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйтә: «Әлбәттә, Аллаһы һәрнәрсәдә [барлык шартларда да] игелекне (изгелекне, йомшаклыкны) ярата».

Раббыбыз Изге Китабы Коръәндә болай дип әйтә:

إِنْ تُبْدُوا الصَّدَقَاتِ فَنِعِمَّا هِيَ ۖ وَإِنْ تُخْفُوهَا وَتُؤْتُوهَا الْفُقَرَاءَ فَهُوَ خَيْرٌ لَكُمْ ۚ
وَيُكَفِّرُ عَنْكُمْ مِنْ سَيِّئَاتِكُمْ ۗ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ

**«Әгәр садакаларыгызны ачыктан-ачык бирәсез икән, бу бик яхшы. Әмма әгәр моны яшерсәгез һәм аларны [очраган бер сораучыга түгел, чыннан да, ихтыяҗы булган] фәкыйрьләргә [беркемгә дә күрсәтмичә һәм ишеттермичә] бирсәгез, бу сезнең өчен тагы да яхшырак. Ул [Аллаһы Тәгалә биргән садакаларыгыз сәбәпле, бөтен гөнаһларыгызны булмаса да] начар эшләрегездән кайберләрен гафу итәр. Аллаһы сезнең [ачык-яшерен, күренгән-күренмәгән бөтен нәрсәгезне Белүче һәм] ни кылганнарыгыздан хәбәрдар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:271

Бу урында күп еллар элек Алжирда булган гаҗәеп хәлне искә алыйк.

...1994 елда бер авыл кешесенең ундүрт яшьлек кызы авырый. Табиблар аны Алжир шәһәр хастаханәсенә алып барырга киңәш итә. Әлеге кешенең гаиләсе яшәгән авыл шәһәрдән ерак була һәм бу кешенең беркайчан да зур шәһәргә барганы булмый. Ул кызы белән шәһәргә килгәч, шәһәрнең зур һәм шау-шулы булуына гаҗәпләнә. Алар хастаханә эзләп, шәһәр буйлап йөреп арыйлар. Һәм бу әти кеше монда, авылдагы кебек, җәяүләп кенә шәһәр буйлап йөрү мөмкин түгеллеген аңлый, биредә моның өчен машина кирәклегенә төшенә. Бу эштә булышырлык кеше таба алмагач, әти кеше бик борчыла. Ерак юлдан килгәнлектән нык арып, кызының авыр хәлен күреп, бу ир-ат бер эскәмиягә утыра һәм елап җибәрә...

Алар эскәмиядә утырганда, янәшәләренә затлы машина килеп туктый, аннан озын буйлы чибәр егет чыга, аның муенына профессиональ визитка эленгән була. Ул әлеге ир һәм аның кызы янына килеп, аларның проблемасы хакында сорый. Әти кеше күз яшьләрен яшерә алмыйча,

кызының бик авыр хәлдә булуын, аларның хастаханәгә килүләрен, әмма шушы хәлдә калуларын әйтеп күрсәтә. «Шәһәрдә кешеләр күп, әмма барысы да үз эшләре белән мәшгуль», – ди. Яшь ир аңа: «Сезнең медицина документлары бармы? Миңа аларны бирегез. Мин карыйм», – дип тәкъдим итә.

Кызның әтисе егеткә документларны тапшыра, ә бу вакытта егет картны игътибар белән күзәтеп, аңа карап бик гаҗәпләнә, авыр сулап, алар янына утыра. Аннары ул басып, картны маңгаеннан үбә. Бу вакытта аның да күзләре яшьләнә. Әти кеше аннан: «Ий, улым, сиңа нәрсә булды!?» – дип сорый. Яшь ир аңа: «Минем белән барысы да әйбәт, мин сине һәм синең кызыңны кызганам», – дип җавап кайтара. Аннан соң ул: «Әйдәгез минем белән, абый!» – дип, аларны үз машинасына утыртып, хастаханәнең махсусн бүлегенә алып бара. Анда барысын да тиешенчә эшләп, кызга кирәкле операция ясала һәм күпмедер вакыттан соң ул аңына килә.

Кызның әтисе Аллаһы Тәгаләгә бу егетне җибәргәне өчен рәхмәтләрен укый. Дога кылып: «Аллаһы белән ант итәм, бу егетнең игелеге өчен гомерем буе аңа рәхмәтле булып калачакмын», – дип әйтә.

Өч көннән соң кызга операция ясаган табиб, аларның хастаханәдән чыгарылуы һәм алга таба тәрбияләр өчен, өйләренә җибәрелүе турында әйтә. Аларның авылларына кадәр бик зур юл үтәргә кирәк булуын исәптә тотып, аларга ярдәм күрсәткән әлеге егет кызга хәл кергәнче, аларга тагын бер атна үзенең өендә яшәп торырга тәкъдим итә.

Кызның әтисе мондый тәкъдимне кабул итәргә кыенсына һәм ул алар өчен бик күп эш башкарган яшь иргә авыр йөк булмас өчен, үз өйләренә кайтырга теләүләрен әйтә. Әмма яшь ир үз сүзендә нык тора һәм шуңа да кызның әтисе җиде төнгә аның өендә калырга риза була. Яшь ирнең хатыны кызга хезмәт күрсәтә, ул аңа карата мәрхәмәтле була һәм аның атасына карата да игелек, изгелек һәм әдәплелек белән карый. Ул өстәлгә аш-су куеп, барысын да төшке ашка чакыргач, әти кеше аннан ни өчен үзләренә шундый ярдәм күрсәтелүенең, мөгамәлә корылуының сәбәбен сорый.

Егеткә: «Мин сине белмим, син кем буласың?» – дигән сорауны да бирә. Яшь ир: «Абый, хәзер син ризыклардан авыз ит, кичке аштан соң мин сиңа барысын да сөйләячәкмен...» – дип әйтә. Әмма әти кеше: «Йә, Раббым, бу ризык минем тамакка керми. Дөресен ишетмичә, берни ашый алмыйм», – дип әйткәч, яшь ир болай дип сүз башлый: «Абый, хәтереңдә булса, син 1964 елда, бер көнне автобуста барганда миңа биш динар акча биргән идең. Мин – Гали, базардагы эшче Әхмәднең улы булам», – дип әйтә. Карт сөенә-сөенә: «Ий, менә искә төшердем, әйе шул, син Әхмәднең улы. Аллаһы аңа рәхмәт кылсын. Ул безнең авылдан бит», – дип әйтә.

Чыннан да, моннан күп еллар элек кызның әтисе автобуста барганда аның артында унбиш яшьтән өлкәнрәк булмаган ике малай утырып барган иде. Малайларның берсенең әйтүенчә, аңа мәктәпне ташлап китәргә туры киләчәк, чөнки аның әти-әнисенең мәктәп өчен булган барлык кирәк-яракларны һәм кием-салымны сатып алу өчен акчасы юк. Ир-ат ике баланың хәерчелек турында сөйләгәнен ишеткәч, шунда ук кесәсеннән биш динар чыгарып, малайга: «Улым, бу динарны ал», – дип әйтә. Ә ул вакытта бу сумма бик зур була һәм барлык мәктәп кирәк-яракларын да сатып алырга җитә. Малай акчаны алудан баш тарта һәм ир сәбәбен сорагач: «Минем әтием мин бу акчаларны урлаган дип уйлаячак бит», – ди. Ир-ат: «Чүп-чарчы Габделһәди абый миңа бу акчаларны мәктәп кирәк-яракларын сатып алуга бирде», – дип әйт. Әтиең мине бик яхшы белә», – дип әйтә. Малай шатланып, ул биш динарны кабул итә. Шул көннән ир-ат бу малайны да һәм бу хәлне дә онытkan була.

Менә кайчандыр шул акчага рәхмәт укып, аны кабул иткән бу малай аңа хәзер мондый сүзләр әйтә: «Абый, ул малай – мин. Ул вакытта шул биш динар булмаса, мин бүген Алжирның иң зур хастаханәсендә профессор булмас идем. Инде хәзер, мине Аллаһы иң хөрмәтле һөнәр белән рәхмәтләгәч, без очраштык. Без 1964 елда аерылышкан идек һәм менә 1994 елда очраштык. 30 ел узды! Аллаһыга шөкер, Раббым миңа изге гамәл өчен түләү

мөмкинлеген бирде. Абый, сез миңа биргән биш динар мине медицина профессоры итте. Аллаһыга ант итәм, кемдер миңа дөнья хәзинәләренең барысын да бирсә дә, ул көнне мин шул динарлар белән бәхетле булган төсле, хәзер берни белән дә канәгать була алмас идем. Абый, синең миңа карата мәрхәмәтең бик зур, һәм мин Аллаһыга ант итәм, ни генә эшләсәм дә, сиңа бурычымны кайтара алмам. Раббыбыздан сезне бу дөньядагы иң яхшы бүләк һәм киләчәктә зур бүләк белән бүләкләвен сорыйм», – дип әйтә.

Әлеге хәлне Алжирдагы авылда Гали белән янәшә яшәүче шәех сөйләгән. Ул раслаганча, бу дөрес хәл.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да изге гамәлләр кылыр өчен йөрәкләребезгә һәм кулларыбызга көч, мөмкинлек бирсә иде. Яхшылыкларыбызны эшлик тә, аларны суга салыйк. Аллаһы бар эшләрне күреп торучы.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Нуруллин,*

*Югары Ослан районы, Введенский Бистәсе имам-хатыйбы*

*4 нче ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Сәламәтлек — Аллаһы бүләге

Галәмнәрнең Тәрбиячесе булган Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез булсын, җир йөзенә рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде. Әссәләмү галәйкүм, хөрмәтле мөселман кардәшләрем!

Кайвакыт кешеләр: «Табибка бару, тәнгә укол кадату, дару эчү дөресме?» – дип сорый. Әлеге вәгазь шушы сорауларга җавап йөзеннән булыр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әй, адәм балалары, хасталарыгызны дәвалагыз, Аллаһы Тәгалә авыруны яратты икән, аның дәвасын да яратты. Мәгәр бер генә авыруга дәва юктыр, ул авыру – картлыктыр», – дип әйткән. Бу хәдистән күренгәнчә, без һәрбер авыруны дәваларга тиеш булабыз. Һәм һәрбер авыруның дәвасы да бар. Әле бүген дәвалый алмыйлар икән, димәк, фән шул дәрәҗәгә кадәр үсеп җитә алмаган. Галимнәребез алдында шушы авыруларның дәвасын эзләү бурычы бар әле. Нәтиҗә: димәк, авыруны дәвалау да, төрле авыруларга каршы дәва эзләү дә дөрес. Хәдис булгач, димәк, бу сөннәт эш: моны эшләү тиеш була. Һәм тагын шундый бер хәдисне искә алыйк: «Йогышлы авыру булган җиргә бармагыз, барсагыз – аннан чыкмагыз».

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе, бер шәһәргә сәяхәткә чыккач, анда вәба авыруы барын белеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен искә төшерә һәм кире борыла. Шулвакыт аннан: «Син тәкъдиреңнән качасыңмыни?» – дип сорыйлар. Хәзрәти Гомәр

радыяллаһу ганһе: «Тәкъдирем кушканга күрә, мин кире борылам», – дип җавап бирә.

Димәк, берәр җирлектә йогышлы авырулар булса, без аннан сакланырга тиеш икән, чөнки Пәйгамбәребез безне хорафатларга ышанудан тыйды. Шомлану юк, дигән мәгънәдәге хәдис тә бар. Чыннан да, без төрле хорафатларга, ырым-шырымнарга ышанырга тиеш түгел. Әмма бер курку дөрес, ул – йогышлы авырудан курку. «Йогышлы авырудан арысланнан курыккан шикелле куркыгыз», – диелгән.

Тагын бер хәдисне искә төшерик, анда: «Адәм балаларының күбесе үзләренә бирелгән ике нигъмәтне аңламыйлар, алданалар. Бу нигъмәтнең берсе – сәламәтлек, икенчесе – буш вакыт», – диелгән. Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Адәм баласы сәламәтлегенең дә, үзенең таза вакытта эшләгән вакытының да кадерен белми», — дигән. Һәм шулай ук тагын бер хәдис бар: «Картлыгыңнан элек яшьлегеңне ганимәт дип сана, үлемеңнән элек терек булуыңны ганимәт дип сана, хасталыктан алда сәламәтлегеңне ганимәт дип сана. Шөгыльле вакытыңнан элек буш вакытыңны ганимәт, дип сана».

Сәламәтлек – сезгә бирелгән бер бүләк ул, диелә. Ганимәт икән, димәк, син сәламәтлегеңне сакларга тиеш. Тагын бер хәдис бар: «Адәм баласы вафат булганнан соң, аннан иң беренче: вакытыңны кая сарыф иттең, байлыгыңны нинди юллар белән җыйдың, җыйган байлыгыңны нинди урыннарга тоттың, Аллаһы Тәгалә биргән сәламәтлегеңне, гыйлемеңне нинди урыннарга сарыф иттең?» — дип соралыр». Сәламәтлек безгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән олуг бер бүләк икән, без аны сакларга тиеш. Сәламәт тәндә – сәламәт акыл, дигән сүз бар. Димәк, сәламәт яшәү рәвеше, Ул Ислам дине кануннары белән тәңгәл килә. Бер китапта кызыклы статистика китерелә: бүген киң таралган авыруларның күбесе элек мөселманнар арасында булмаган, чөнки алар һәрвакыт тәһарәтле, госелле йөргән, дөрес тукланган, харам кулланмаган. Аллаһы Тәгалә

биргән сәламәтлекне, теләсә нәрсә ашап-эчеп, теләсә нәрсә эшләп, бозыклыкта йөреп, исраф итәбез икән, моның өчен бездән сорау алыначак. Ислам кануннары белән яшәмәсәк, кайбер авыруларның килеп чыгуына үзебез дә сәбәпче булабыз.

Тагын бер хәдистә: «Адәм баласына авыру килмәс, авыру килде икән, ул аның гөнаһларына кәффарәт булыр», – диелгән. Без авырыйбыз икән, димәк, гөнаһларыбыздан чистарынабыз. Һәм менә шушы гөнаһларыбызга кәффарәт булудан туктагач, Аллаһының рөхсәте белән, шифага ирешәбез. Пәйгамбәребез: «Кеше авыруына хас булган шифаны тапса, Аллаһының рәхмәте белән сәламәтлек тә табар», – дигән. Әмма даруның күләме һәм вакыты бар. Димәк, әле без даруны табу гына түгел, аның күләмен дә, кабул итү вакытын да чамаларга тиеш. Шуның өчен безнең табибларыбыз бар. Хәдистә «Табибсыз шәһәрдә, табибсыз авылда тормагыз», диелгән. Димәк, менә бүген дәүләт тарафыннан куелган табиблар безгә хезмәт күрсәтә икән, шифаханәләр бар икән, бу – Аллаһының безгә биргән олуг нигъмәте. Әгәр дәүләт аларны тотмаса, шәригатебезгә муафыйк булсын, дисәк, без үзебез, акча җыешып, берләшеп, табиб тотарга тиеш булабыз. Димәк, табиблы җирдә тору күркәм санала, бу безнең вазифабыз була.

Без табибларга, шифаханәләргә булдыра алган хәтле ярдәм дә итәргә тиешбез, чөнки алар – безне кайгыртучылар. Табиб мөселманмытүгелме, дип сайлап алырга мөмкинлек булмаганда, аның милләтен, динен шөбһәгә алырга, шикләнергә тиеш түгелбез. Безгә Аллаһыга тапшырып, Аннан сорап, бу белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әмма шуны онытмыйк: әгәр без табибка барып, йә булмаса, дарудан файда табып, савыгабыз икән, димәк, бу Аллаһының рәхмәте белән эшләнгән эш!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Җәлил хәзрәт Фазлыев,*
*Балтач районы имам-мөхтәсибе,*
*ТР баш казые*

*11 нче ноябрь вәгазе,*
*рабигыль-ахыр аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Әл-Фатиха сүрәсе турында

Галәмнәрнең Тәрбиячесе булган Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез булсын, җир йөзенә рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде. Әссәләмү галәйкүм, хөрмәтле мөселман кардәшләрем!

Вәгазебез Изге Китабыбызның иң беренче сүрәсе булган «Әл-Фатиха» га багышланачак. Әл-Фатиха сүзе «фәтәхә» фигылыннән ясалган. Фәтәхә «ачарга» дигәнне белдерә. Димәк, «Әл-Фатиха» сүрәсе ул ачучы сүрә. Аның Коръәни Кәримебездә иң беренче булып торуы да юкка гына түгел. Изге Китабыбыз әлеге сүрә белән башлана, ул Коръәнне ачып җибәрә.

«Әл-Фатиха»ның фазыйләте гаҗәеп зур. Аны һәр көнне биш вакыт намазларыбызда берничә тапкыр укуыбыз белән дә бу сүрәнең дәрәҗәсе олуг булуын аңларга була. Аның хакта Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырылган хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намазда «Әл-Фатиха» сүрәсен укымаган кешенең намазы тулы һәм төгәлләнгән булмас», – дип әйткән. Димәк, намазыбыз камил һәм җитеш булсын өчен, «Әл-Фатиха» сүрәсен укырга тиешбез.

«Әл-Фатиха» сүрәсе белән без мәҗлесләребезне башлыйбыз, Коръән укый башлар алдыннан да әлеге сүрә укыла. Моннан тыш «Әл-Фатиха»ның шифа сүрәсе булуын да онытмаска кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әл-Фатиха» сүрәсендә барлык авырулардан шифа бар», – дигән. Икенче бер хәдистә Расүлуллаһ: «Әгәр син авырсаң яки берәр зарың булса, Изге Коръәннең нигезе булган «Әл-Фатиха» сүрәсенә мөрәҗәгать ит», – дип әйткән.

Болай дип риваять ителә: берәүне чаян чаккан һәм Пәйгамбәребезнең сәхабәләреннән булган берәү аңа «Әл-Фатиха» сүрәсен укыган, шуннан соң бу кешедә чагуның әсәре дә калмаган. Моның хакта Пәйгамбәребез белгәч: «Әл-Фатиха» сүрәсенең шифа сүрәсе булып хезмәт итүен син каян белдең?» – дип сораган. Шуның белән «Әл-Фатиха» сүрәсенең дәва китерә торган сүрә икәне дә раслана.

Бу сүрәнең бөеклеген ассызыклап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр үлчәүнең бер ягына «Әл-Фатиха», икенчесенә калган сүрәләрне куйсагыз, «Әл-Фатиха» авыррак булыр».

Әйдәгез, әлеге сүрәнең һәрбер аятенә тукталып үтик. Бу сүрә һәр сүрә алдында да булган кебек:

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

**«Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим»,** ягъни Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы исеме белән, дигән сүзләр белән башлана.

Раббыбыз беренче аять итеп:

الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Барча мактаулар – галәмнәрнең Раббысы [тәрбиячесе] булган Аллаһыга»**, – дип әйтә.

Кем соң Ул Рәхимле Аллаһы? Кем Ул безнең Яратучыбыз? Шушы ук аятьтә Раббыбыз Үзен: «Галәмнәрнең Тәрбиячесе», – дип атый.

Без – Аллаһының мәхлүкълары, барысы өчен дә Аңа рәхмәт, хәмед-сәналәр әйтергә, гомеребез өчен дә, ашау-эчүебез өчен дә, барысы өчен дә Аңа рәхмәтле булырга тиешбез. Бу сүзләрне «Аллага шөкер» дип тә әйтеп була, әмма ул тулысынча бөтен мәгънәне биреп бетерә алмый. «Әлхәмдүлилләһи» дигән сүзләр белән Раббыбызга булган хәмед-сәнане Ул лаек булганча әйтәбез.

Дөреслектә, галәмнәр күп. Галимнәрнең әйтүе буенча, 18 мең галәм бар. Аллаһы Тәгалә шуларның Раббысы, Хуҗасы. Фәрештәләр, җеннәр һәм башка галәмнәр бар. Раббыбыз аларның һәрберсен ризыкландырып тора.

Алга таба дәвам итеп, Раббыбыз:

الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

**«[Дөньяда һәрбер колына мәрхәмәтле булган] Рахмәнгә, [иман китерүчеләргә генә Ахирәттә мәрхәмәтле булган] Рахимгә»**, – дип әйтә.

«Әр-Рахмән» – киң Рәхмәт иясе дигәнне аңлата. Раббыбызның «Әр-Рахмән» исеме барлык мәхлүкъларга да: мөэминнәргә дә, мөэмин булмаучыларга да Рәхмәтле булучы, дигәнне белдерә. Әйе, Аллаһының Рәхмәте барлык нәрсәне чолгап алган. Раббыбызның барлык мәхлүкълары да Аның Рәхмәте белән тереклек итә. Әмма «Әр-Рахим» исеме – Аллаһы Тәгаләнең Кыямәт көнендә мөэминнәргә, ягъни иман китерүчеләргә генә хас булган Рәхмәте ул.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә, әни кеше үз баласына рәхимле булганга караганда да, Үз колларына рәхимлерәк»[1], – дип әйткән.

Алдагы аятьтә Раббыбыз:

مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ

**«Хисап [Кыямәт] Көненең Хуҗасына»,** – дип әйтә.

Әлбәттә, Хисап көне – Кыямәт көне җитәчәк. Һәм барлык мәхлүкълар да шул бөек Көннең Хуҗасы алдында җавап тотачак.

Алдагы аятьтәге:

---

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ

**«[Аллаһы Тәгаләгә итагать иткән коллар:] «[Ий Раббыбыз!] Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз!»** дигән сүзләр безнең тарафтан Раббыбызга дога кылу булып бара. Күз алдына гына китерик, күпме тапкыр без аны намазларыбыз саен кабатлыйбыз. Бу мөрәҗәгать белән бары Аллаһының колы булуыбызны, Аңа гына гыйбадәт кылуыбызны һәм барысын да Аннан гына соравыбызны белдерәбез.

اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ

Бу аятьтә Аллаһыга дога кылуыбызны, мөрәҗәгатебезне дәвам итеп, **«Безне туры юлга күндер»**, – дип әйтәбез.

Нәрсә соң ул туры юл? Ул кемнәр юлы? Бу сорауга җавап алдагы аятьтә килә:

صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ

**«[Синең тарафтан] Нигъмәтләндерелгәннәрнең юлына. Ачуың төшкән һәм [туры юлдан] адашканнарның [юлына] түгел!» [дип әйтәләр]».**

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бары берничә аятьне үз эченә алган шушы кыска сүрәне һәр намазыбызда укуыбызны насыйп кылган. Уйлап карасак, бу сүрә Раббыбызга хәмед-сәналәр әйтүне дә, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең бөек исемнәрен дә, Кыямәт көне булачагы һәм аның Хуҗасы Аллаһы Тәгалә булуын да, безнең туры юл, һидаять сорап дога кылуыбызны да, безгә кадәр булган кешеләрнең адашып, туры юлдан тайпылулары хакында әйтелгәннәрне дә үз эченә алган. Югарыда «Әл-Фатиха»ның шифа сүрәсе булуын да, намазларыбыз камил, тулы булсын өчен аның укылырга тиешлеген дә әйтеп уздык.

Раббыбыз Аллаһы безнең өчен зур нигъмәт булган әлеге сүрәне олуглап, аның кадерен белеп, телләребездән төшермичә, һәр аятенең мәгънәсен аңлап, фикер йөртеп яшәүләребезне насыйп итсә иде. Әәмин.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*18 нче ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Хафизлар – Коръәннең былбыллары

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Сезнең берәр кайчан чын могҗиза күргәнегез бармы? Сез монда утыручыларның чын мәгънәсендә бәхетле кешеләр икәнен белә идегезме? Ник, диярсез, чөнки безнең һәрберебезнең дә бер могҗиза белән күрешкәне бар. Ул – Аллаһының Сүзе Коръәни Кәрим. Бүгенге көндә мәчетләребезнең киштәләрендә булсынмы, өйләребездә югарырак урыннарда булсынмы, Аллаһыга шөкер, ул Китап бар җирдә дә бар. Әмма аңа карап, Коръәнгә булырга тиешле хөрмәт бармы икән бездә? Аллаһы Тәгалә бу дөньяда һәрнәрсәне, һәркемне ниндидер хакларга ия итеп һәм кайбер әдәпләр белән яратты. Коръәннең дә хакы бар. Ул өебездә бар икән, без аны укырга тиеш. Ә Коръәнне укыганда аның үз әдәбе бар. Мәсәлән, аны бары тик тәһарәтле килеш тоту, тәһарәтле килеш уку, укыр алдыннан авызны чайкап алу, матур киемнәр киеп уку, кыйбла тарафына борылу, укыганыңны аңларга тырышу, укыган өлешең турында уйлану һ.б.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне Коръәнне өйрәнергә чакырды. Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Расүлебезнең: «Иң хәерлегез Коръәнне өйрәнеп, аны калганнарга да өйрәткәнегез», – дигән сүзләре китерелә. Димәк, Коръәнне чын күңеленнән Аллаһы ризалыгы өчен өйрәнгән һәм калган кешеләргә дә

өйрәткән кешеләр иң күркәм, иң яхшы кешеләр рәтенә керә икән. Безнең барыбызны да әниләребез, яхшы кеше бул, дип әйтеп үстерә. Җәмгыятьтә бу кеше яхшы, бу кеше начар дигән сүзләр белән кешеләрне бәялиләр. Динебездә яхшыны, яманны үлчәргә ярдәм иткән әйбер – ул шәригатебез. Менә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә үлчәү өчен бер билге бирә дә инде: иң яхшыларыгыз – Коръәнне өйрәнүчеләр, дип әйтә. Әмма таякның ике башы бар бит, җәмәгать. Алайса Коръәнне укымаган, аны өйрәнмәгән кешеләр кемнәр соң? Шуның турында уйлансак иде, чөнки яхшы кешеләрнең иң яхшыларына гына Коръән нигъмәте ачыла, ул истә кала ала. Без бүгенге вәгазебездә нәкъ менә Коръәнне ятлау турында сөйләшербез дә.

Аллаһыга шөкер, Татарстаныбызда мәдрәсәләр саны арткannan-арта бар. Һәр районда диярлек мәгърифәт үзәкләре, мәдрәсәләр ачылып тора. Һәм дин нигезләре белән беррәттән, Коръән ятлау буенча да дәресләр каралган. Коръәнне яттан белүчеләрне икенче төрле, Коръәннең былбыллары, дип тә әйтәләр бит. Чыннан да, Коръәнне өйрәнүчеләрне тыңларга рәхәт, Аллаһы Тәгалә аларга бәрәкәт бирә. Аллаһыга шөкер, Пәйгамбәребездән башлап, бүгенге көнгә кадәр һәр дәвердә Коръәнне ятлаучылар булган. Динебездә аларны Коръән-хафизлар дип атыйлар. Инде күбегез моны, авыр хезмәт, кеше гомеренең күп вакыты шуңа китәдер, дип уйлап куйгандыр. Әмма Аллаһы Тәгалә бу эштә җиңеллек бирде:

إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

**«Һичшиксез, [алар инкяр иткән] Коръәнне Без иңдердек һәм Без [бүтән китапларыбыз арасыннан] аны [гына үзгәртелү, югалудан] саклыйбыз».**

«Әл-Хиҗр / Хиҗер», 15:9

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримне Үзе үк югалтудан, үзгәрүдән саклавын әйтте. Шуңа күрә кем дә кем чын, ихлас күңеленнән Коръәнне ят-

ларга алына икән, Раббыбыз ул кешегә юлларын ачачак, җиңеллекләрен бирәчәк. Шулай ук Коръәндә:

الر ۚ كِتَابٌ أَنزَلْنَاهُ إِلَيْكَ لِتُخْرِجَ النَّاسَ مِنَ الظُّلُمَاتِ إِلَى النُّورِ بِإِذْنِ رَبِّهِمْ إِلَىٰ صِرَاطِ الْعَزِيزِ الْحَمِيدِ ﴿١﴾

**«Әлиф ләәәм раа. Раббыларының рөхсәте белән кешеләрне караңгылыклардан Нурга – [Бөек] Җиңелмәс һәм Мактауга лаеклының юлына – чыгаруың өчен сиңа иңдерелгән [бик бөек] бер китап»,** – дип әйтелгән.

«Ибраһим», 14:1

Шушы бөек китап, кешене үзеннән-үзе нурга этәрә, аның тормышында яктылыклар күбәя башлый. Коръән буенча яшәүче дә, аны Аллаһы ризалыгы өчен ятлаган кеше дә, шушы лаеклылар юлында булыр, Аллаһы боерса.

Хафизлар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытыннан бирле килә, дип әйттек. Яраткан Пәйгамбәребез вакытында ук андый кешеләр булган, ул безнең яраткан сәхабәләребез: Гали бине Әбү Талиб, Госман бине Гаффан, Үбәй бине Кәгъб, Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһүм һ.б.

Ий, монда утыручы кардәшләрем, инде Аллаһы Тәгалә безгә дә шушы нигъмәткә ирешүне насыйп итсә иде.

Коръәнне ятлауның авыр түгеллеген аңладык. Ә бит Коръән белән күбрәк булган саен аның әҗере дә күп икәнен онытмасак иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Коръән укыгыз, чөнки ул үзен укыганнар өчен Кыямәт көнендә шәфәгать кылачак», – дип, яки: «Кыямәт көнендә Коръәнне һәм аның нигезендә гамәл кылучыларны китерәчәкләр, ә алда «Сыер» һәм «Гыймран гаиләсе» сүрәләре барачак, һәм алар үзләре буенча яшәгән кешеләр файдасына (дәлилләр

табып) барачак», – дип әйтеп калдырган.

Инде хафизлыкка этәрә торган тагын бер хәдис, чыннан да, күпләребезнең күңелендә бу эшкә тотынуда очкын барлыкка китерер. Әбү Сәгыйд Әл-Ходри радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «(Кыямәт көнендә) Җәннәткә кергәндә Коръән белүчегә: «Укы һәм югары күтәрел…» – дип әйтелер. Ул (яттан өйрәнгән) соңгы аятен укыганчы һәр укылган аяте саен (җәннәттә) бер дәрәҗәгә күтәрелер», – дип әйткән.

Күрәбезме, Аллаһы Тәгалә Үзенең китабын олуглаган кешеләрне ничек итеп олуглый. Раббым барыбызга да шушы юлга басуны, безгә дә акрынлап-акрынлап шушы хафизлар сафында булуны насыйп итсә иде.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, без дә бүгеннән Коръән ятлый башлый алабыз. Истә калдыру дәрәҗәбез төрле булганга, ысуллар да төрле:

1) бер битне башыннан ахырына кадәр укып чыгып ятлау;

2) бер-бер аятьләп ятлау;

3) бер битне берничә кисәккә бүлеп ятлау;

4) кәгазьгә, тактага язып ятлау (кемнеңдер хәтере язып ятлаганда яхшырак эшли ала);

5) аудиофайллар тыңлый-тыңлый ятлау.

Хәтеребез начар дип, акланулар эзләмик. Барыбыз да моннан чыккannнан соң, яки эштән соң өенә юлны хәтерли бит. Димәк, хәтеребез бар, Аллаһыга шөкер. Бүгенге көндә хафиз булып җитлеккән мөселманнарның кайберләренең хәтерләре бары тик Коръәннең яртысын ятлагач кына ачылып киткән. Сабырлык белән алга гына барырга кирәк.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы*

*25 нче ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Фикерләүчеләр өчен аятьләр бар

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез ирешсә иде. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Хөрмәтле мөселманнар! Раббыбыз безләрне изге Коръәндә бик күп җирләрдә фикерләргә чакыра, Үзенең нигъмәтләренә күз салырга куша, мәхлүкъларына игътибар итәргә өнди. Коръәни Кәримнең бик күп урыннарында мондый аятьләрне очратырга туры килә, мәсәлән:

كَذَٰلِكَ نُفَصِّلُ الْآيَاتِ لِقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ

**«Фикер йөрткән кешеләр өчен Без аятьләребезне әнә шулай тәфсилләп аңлатабыз»;**

«Юныс», 10:24

إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ

**«Фикерли белгән кешеләр өчен монда, һичшиксез, билгеләр бар».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:3

Монда нинди хикмәт бар? Кеше үзенең тән төзелешенә, аның ни дәрәҗәдә камил икәнлегенә караса, яисә көн белән төннең алмашуына игътибар итсә, һәрнәрсәнең үз урынында, вакытында булуы хакында уй-

ланса, Аллаһының чиксез хикмәтенә төшенә ала.

Фикерли белү хаклыкны күрергә өйрәтә, кешедә аек фикер тәрбияли. Шул рәвешле кеше бик күп ялгышлыклардан, хаталардан үзен саклап кала ала. Искә алсак, тарихыбызда фикерләмәгән дә, уйланмаган да күпме кавемнәр булган. Мәсәлән, Муса гәләйһиссәламнең кавеме генә дә, ул юкта алтын сыерга табына башлый. Фикерләмәгәч, яннарында Һуд пәйгамбәр булу да, аның үгете дә аларга булышмый.

Икенче яктан алсак, адәм балалары өчен Аллаһының нигъмәтләрен күрә белү, ә иң мөһиме аны «Аллаһының нигъмәтләре бит бу» дип таный белү – ул үзе бер бүләк. Күпме кеше сукыр вә саңгырау булып яши. Тирә-юнеңә карап, Раббыңның чиксез Кодрәтен күрү, Аны Кодрәтле, Бөек, Рәхимле һәм Шәфкатьле итеп искә алу, Аны онытмау, үзенә күрә бер зикер итү ул. Ә зикер итү – гамәл-гыйбадәт ул, аның өчен кеше әҗер-савапка да ирешә.

Аллаһыны таныган берәү: «Эх, яшьлегем белән бер сөйләшеп булса иде!» – дип әйткән ди. Аннан: «Ни турында сөйләшмәкче буласың?» – дип сорагач, «Мин аңа картлык нишләтә икәнлеген хәбәр итәр идем», – дигән.

Чыннан да, кешеләр сәламәтлек кадерен – авырганда, яшьлекнең кадерен – картайгач, буш вакытның кадерен – мәшгуль булгач аңлый.

Фикерләү, әлбәттә, файдалы, тик ни турында фикерләргә икәнлекне дә белергә кирәк.

Бер хәдистә болай дип китерелә: «Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Кешеләр Аллаһы турында фикерләп утыра иделәр. Шул вакытны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Аллаһы турында фикерләмәгез, Аның мәхлүкъләры хакында фикерләгез, чөнки сез тиешенчә фикерли алмассыз (ягъни ялгыш, хаталы фикерләр юлыннан китүегез ихтимал)».

Пәйгамбәребезнең тормыш юлына күз салсак, сәхабәләребез үрнәген алсак, аларның хәтта гади генә бер нәрсәдә дә бик зур хикмәт

һәм гыйбрәт күрә белүләрен аңларбыз.

Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе бервакытны Әт-Тур сүрәсен укып утырган, һәм:

إِنَّ عَذَابَ رَبِّكَ لَوَاقِعٌ ﴿٧﴾

**«Һичшиксез, синең Раббыңның газабы җитәчәк»**, – дигән аятькә тукталгач, бик каты елаган, хәтта авырып киткән һәм башка сәхабәләр аның хәлен белеп, аны зиярат кылганнар.

«Әт-Тур / Тур тавы», 52:7

Фузайл бине Гыяз бик хикмәтле һәм галим кеше була. Ләкин аңа кадәр ул талаучы, караваннарны яулап алучы иде. Бервакытны баскыстан менеп барганда, тәрәзәдән Коръән укылганын ишетә. Һәм анда:

أَلَمْ يَأْنِ لِلَّذِينَ آمَنُوا أَن تَخْشَعَ قُلُوبُهُمْ لِذِكْرِ اللَّهِ وَمَا نَزَلَ مِنَ الْحَقِّ وَلَا يَكُونُوا كَالَّذِينَ أُوتُوا الْكِتَابَ مِن قَبْلُ فَطَالَ عَلَيْهِمُ الْأَمَدُ فَقَسَتْ قُلُوبُهُمْ ۖ وَكَثِيرٌ مِّنْهُمْ فَاسِقُونَ ﴿١٦﴾

**«Иман китерүчеләрнең Аллаһыны искә алганда һәм [Коръән аятьләреннән] иңгән хакка карата күңелләре йомшаруының һәм элек [Тәүрат һәм Инҗил кебек] китап бирелгән кешеләр кебек булмауларының вакыты җитмәдеме? Югыйсә аларга вакыт озын булып тоелды, һәм күңелләрен катырды. Аларның күбесе [үз китапларын да читкә ташлаган һәм дин чикләреннән ашкан] фасикъ кешеләр»**, – дигән сүзләр яңгырый.

«Әл-Хәдид / Тимер», 57:16

Ул бу сүзләргә игътибар итмичә генә үз эшен дәвам итә ала иде, ләкин Фузайл бине Гыяз туктый, кире төшә. Һәм шулай уйланып кайтып барганда, авылы кырыенда караван туктаган була. Шунда ике кеше

бәхәсләшә икән: берсе, юлны дәвам итик, ди, икенчесе, туктап торыйк, чөнки Фузайл бине Гыяз безне таларга мөмкин, ди. Фузайл бине Гыяз бу сүзләрне ишеткәч: «Юлыгызны дәвам итегез, Фузайл башка тимәс!» ди. Шул вакыйгалардан соң Фузайл бине Гыяз үзе дә ислам динен кабул итә, һәм тиздән бик зур галим була.

Раббыбыз вәгазебездән файдаланырга насыйп итсен, безләргә аек фикер, фикерләү сәләте биреп, хәләлне харамнән, хак юлны ялгыш юлдан аерып яшәргә насыйп әйләсен.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*ТР МДНнең Зәкят фонды хезмәткәре*

*2 нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Җәмәгать белән намаз уку

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Әлеге вәгазьдә җәмәгать белән намаз укуның биш фазыйләтен искә төшереп китәрбез.

Намаз – ул динебезнең биш нигезенең берсе, Аллаһы Тәгаләнең безгә бирелгән рәхмәте, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Исра вә Мигъраҗ вакытында бүләк ителгән зур бәхетебез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы бүләкне алып төште һәм үзе дә аны кабул итеп, намаз укыды. Шулай итеп, безгә – мөселманнарга намаз уку фарыз булды. Темабызга килгәндә, ул – җәмәгать белән намаз укуга багышлана. Сүз ике-өч кеше берләшеп, күмәкләшеп намаз уку хакында булыр.

Җәмәгать белән намаз укуның беренче фазыйләтен карап үтик. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ялгызың гына намаз укуга караганда, җәмәгать белән намаз укуның дәрәҗәсе 27 мәртәбә күбрәк»[1], – дип әйтеп калдырган. Расүлебез хәдистә «дәрәҗә» дигән сүзне куллана. Тормышта, чыннан да, һәрберебез дәрәҗәгә кызыга. Хәтта ки балалар бакчасындагы сабыйларның да тизрәк мәктәпкә керәселәре килә. Ник шулай соң, дигән сорауга, алар: «Монда безгә бик

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

авыр: ашаталар, аннан соң йоклаталар, уйнаталар һәм аннан соң кабат йоклаталар», – дип җавап кайтара. Мәктәптәге бала тагын да зуррак дәрәҗәгә ирешергә – югары уку йортына керергә тели, анда укыганының эшкә барасы килә... Инде эшли башлагач та кеше карьера ясап, югары дәрәҗәләргә менәргә тели. Һәр кешенең күңелендә «мәртәбә», «дәрәҗә», «югарырак» кебек сүзләр аерым урынны тотканга, Пәйгамбәребез шушы сүзне кулланды да инде, һәм, безне җәмәгать белән намаз укысын өчен, шушындый матур сүзләр белән чакырды. Шулай итеп, беренче фазыйләт: җәмәгать белән укылган намаз ялгыз укылган намаздан 27 тапкырга югарырак, дәрәҗәлерәк.

Икенче фазыйләте Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәте белән бәйле. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ике кешенең бергә кылган намазы ялгыз гына укылган намаздан яхшырак. Ә өч кешенең бергә укыган намазы ике генә кеше укыган намаздан яхшырак. Һәм Аллаһы Тәгалә кешеләр күбрәк булганны күбрәк ярата»[1], – дип әйтә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җәмәгать белән намаз укырга мәхәббәт, ярату сүзе аша чакыра, кызыктыра. Ә Аллаһы Тәгалә безне яратса, бу үзе зур дәрәҗә була.

Өченче фазыйләт – бердәмлек. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җәмәгать белән намаз укуга бик тә игътибарлы булыгыз. Дөреслектә, көтүдән аерылган сарыкны бүре ашар»[2], – дип әйтә. Әлбәттә, бу кисәтү сүзләре генә. Өйдә намаз укысагыз, сез яшәгән җиденче каттагы фатирга бүре менми, әмма мин монда татар халкының мәкален исегезгә төшерәм: «Бүленгәнне бүре ашар, аерылганны аю ашар», – дип яңгырый ул. Бу урында без шәйтан сүзен куллана алыр идек. Әгәр дә кеше ялгыз калса, бердәмлектән тайпылса, җәмәгатьтән аерылса, шәйтан аны бик тиз бутап җибәрергә мөмкин. Шуңа да Пәйгамбәребез салләллаһу

---

1 Имамнар Әбү Давыд, Ән-Нәсаи хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әбү Давыдның хәдисләр җыентыгыннан.

галәйһи вә сәлләм безгә шәйтан вәсвәсәсенә эләкмәскә, җәмәгать белән бергә булырга, бердәм булырга, намазларны бергә укырга, берберләребезгә нәсыйхәтләр биреп, туры юлны саклап калырга чакырды.

Дүртенче фазыйләткә күчәбез. Ул – гаиләбезне саклау, гаиләдә өлфәт, мәхәббәт барлыкка килү. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

حافِظوا عَلَى الصَّلَواتِ وَالصَّلاةِ الوُسطىٰ

**«[Фарыз] Намазларны һәм [алар арасындагы] урта намазны дәвам итегез».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:238

Коръәнне тәфсир кылучы кайбер галимнәр аятьтә килгән «хәәфизу» дигән өлешне, ягъни «намазларыгызны саклагыз, дәвам итегез» дигәнне: «Гаиләгез белән: ягъни ир-атлар хатыннарыгыз, хатын-кызлар ирләрегез белән, әти-әни балаларыгыз белән намазларыгызны сакласагыз, Аллаһы Тәгалә сезнең гаиләгезне дә саклап калыр», – дип тәфсир кыла. Бу мәчеттә дә җәмәгать белән намаз укый алабыз, табигатьтә булганда, намаз вакыты керде икән, анда да җәмәгать белән укый алабыз, өйләребездә дә гаиләбез белән укый алабыз, дигән сүз. Инде гаиләбез белән намаз укыган чакта, Аллаһы Тәгалә ир белән хатын арасына өлфәт, мәхәббәт, хөрмәт, бәхет бирер, аларны саклар, иншәАллаһ.

Бишенче фазыйләт: җәмәгать белән намаз уку мөселманнарның арасын ныгыта, дуслаштыра, мөселманнар бер-берсен хөрмәт итә башлый. Бер мәчеттә булган хәлне сөйләп үтик. Биш вакыт намаз, гает намазлары, атна саен була торган җомга намазы һ.б. намазлар да гел бергә укылгач, кардәшләр үзара таныша, дуслаша, хәл-әхвәлләрне сорап тора башлый. Искә алган мәчеттә дә шулай була: кардәшләр берберләренең хәлләрен белеп тора, авыр вакытта ярдәм итешә, шат-

лыкларны бүлешә, бергә куану башлаган. Һәм нәтиҗәдә, мәчеттә шундый тәҗрибә барлыкка килгән: мәчеткә йөрүчеләр вафат булган кардәшләренең исемнәрен язып алып, җомга намазын укыгач, тәсбихләр тарткач, Коръән укып, шушы кешеләр өчен исемнәрен атап дога кылу гадәтен барлыкка китергән. Бу гамәл бердәмлек, җәмәгать булып яшәү дип атала. Исән вакытта дустанә мөнәсәбәттә булу һәм бакыйлыкка күчкән мәрхүм-мәрхүмәләрне дә догадан ташламау бу.

Шушы биш фазыйләт, әлбәттә, дуслык, кардәшлек белән бәйле. Сезнең кайберәүләрдән, минем дусларым юк, кебек сүзләрне ишеткәнегез бардыр. Шуңа да сезгә моның белән бәйле бер кыйсса сөйлим: бер җирлектә яшәүче аксакалның бик күп дуслары була. Моңа бөтен кеше шакката торган иде. Бер-берләренә: «Бу аксакал ничек итеп барысы белән дә дус булып яши икән?» – дигән сораулар бирәләр. Кайбер кешенең – бер, бик сирәкләрнең ике-өч дусты була, ә бу кеше барысы белән дә дустанә мөнәсәбәттә яши. Көннәрдән бер көнне бер егет кыюланып, шушы кеше янына барып:

– Әссәләмү галәйкүм, хөрмәтле абый! Сезгә бер сорау бар иде: сезнең дусларыгыз бик күп һәм сез барысы белән дә дус булып яшисез. Бу хикмәткә ничек ирештегез? – дип сорый.

Аксакал бабай елмаеп кына:

– Улым, минем бакчам бар, һәм мин бакчамдагы һәр үсемлеккә су сибәм. Су сибәргә авыр түгел, әмма мин алардан бернәрсә дә көтмәсәм дә, араларындагы гөлләр чәчәк ата. Ә миңа бу бик ошый, – дип әйтә.

Шуның белән риваять тәмам, хөрмәтле мөселманнар. Хикмәте нәрсәдә соң? Әлбәттә, бакчада үскән бөтен үләнгә дә су кирәк, ләкин барысы да чәчәк атмый. Һәр үләнгә су сипкән кебек, бу тормышта да җәмәгать белән дуслашып, җәмгыятькә файда китерә алабыз. Рамазан аен гына алыйк: мәчетләребездә ифтарлар үткәндә күпме шәкертләр, мохтаҗ кешеләр туклана. Югарыда искә алынган мисалда да чәчәк ату

дигән өлешне рәхмәт әйтү дип аңларга кирәк. Әлбәттә, күбесе рәхмәт тә әйтми, әмма араларында әйтүчеләре дә бар бит. Әдәп-әхлаклы кеше, әлбәттә, рәхмәтле була, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем рәхмәтле булмый, аңа да рәхмәтле булмаслар»[1], – дип әйткән. Ягъни Аллаһы Тәгалә дә аңа карата рәхимле булмас, дигән сүз бу. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен алырга теләүчеләр, кешеләрдән рәхмәт алырга тырышсын, яки җәмгыятькә хезмәт итсен. Корбан чалабыз икән, мескеннәргә, ятимнәргә, фәкыйрьләргә, ялгызларга өләшәбез. Араларында ихластан рәхмәт укып калучылар да шактый була.

Мөхтәрәм дин кардәшләребез, бу дәресләрдән хикмәт шунда: җәмәгать белән намаз укуның бу дөньяда да, Ахирәттә дә әҗер-саваплары бик зур. Бергә-бергә изгелекләрне күбрәк кылып була, җәмгыятькә дә файданы бергә булганда гына күбрәк китерә алабыз һ.б. Ярдәм итүне әллә кайдан ерактан эзлисе юк, бәлки безнең якын тирәбездә, үз мәхәлләбездә дә хәлләр мөшкелдер? Шуңа күрә үз мәхәлләңә йөрү, ярдәмне алардан башлау хәерле. Җәмәгать белән бергә булу, бергәләшеп намаз уку кешеләргә карата рәхмәтле булырга өйрәтә, Аллаһының рәхмәтенә, ике дөнья бәхетенә, шатлыгына, рәхмәтенә ирешергә бер этәргеч булып тора. Аллаһы Тәгалә безне рәхмәтеннән ташламасын иде. Әмин!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт

[1] Имам Әл-Бохариның хәдисләр җыентыгыннан.

итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм Бакиров,*

*Казанның «Гадел» мәчете имам-хатыйбы*

*9 нчы декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Нәфел намазларны укуның әһәмияте

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәна, мактауларыбыз, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның әһеленә, гаиләсенә, пакь булган нәселенә һәм сәхабәләренә сәламнәребез һәм салават-шәрифләребез ирешсен.

Аллаһы Тәгалә безгә – мөэмин-мөселманнарга бер кыйммәтле, кадерле һәм файдасын санап бетермәслек дәрәҗәдә булган бүләк ясады, ул да булса – иман. Кайбер кешедә: «Ни өчен иман шуның хәтле кадерле соң?» – дигән сорау туарга мөмкин. Һәм, чыннан да, әлеге сорауга җавап буларак нәрсә әйтә алабыз? Җавабыбыз шул булыр: иман – адәм баласының киләчәк, мәңгелек тормышын билгели торган бер төшенчә булганга күрә, бик тә кадерле. Ягъни кеше бу дөньядан иманлы хәлдә китсә, бу Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең Рәхмәтенә ирешкәнлекнең бер күрсәткече булып тора һәм ул мәңгелек тормышта Аллаһы Тәгаләнең җәннәтенә ирешкән дигәнне аңлыйбыз, чөнки җәннәт бары тик иман әһеленә генә тиештер.

Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ يُدْخِلُ الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ ۚ إِنَّ اللَّهَ يَفْعَلُ مَا يُرِيدُ ﴿١٤﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы иман китергән һәм изге гамәлләр кылганнарны [агачлары һәм сарайлары] асларыннан елгалар акан җәннәтләргә кертәчәк. Аллаһы [иманлыларга әҗер, инкяр**

**итүчеләргә газап мәсьәләсендә] теләгән һәрнәрсәне [комачау күрмичә] кыла».**

«Әл-Хаҗ», 22:14

Иман төшенчәсен һәрбер мөэмин-мөселман сакларга, күз нуры кебек кадерләп торырга тиеш. Җил исеп шәмне сүндергән кебек, шулай ук көферлек җиле дә исеп, иман нурын сүндерә ала, шуңа күрә без иман төшенчәсен саклар өчен, тиешле чараларын күрергә тиеш булырбыз. Нинди чаралар ул, иманыбызны нәрсә саклый соң, дигәндә, беренче булып намазны искә алабыз. Намаз – Ислам диненең икенче баганасы, мөэмин-мөселманның бер билгесе булып тора.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә биш вакыт намазны пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә, ягъни безгә фарыз кылды. Коръәни Кәримдә моны раслый торган аять бар:

إِنَّ الصَّلَاةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَّوْقُوتًا

**«Һичшиксез, намаз кешеләргә вакыты билгеләнеп фарыз кылынган».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:103

Бу аяте-кәримәдән аңлавыбызча, намаз – Аллаһы Тәгаләнең әмере һәм, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләгә иман китергән кеше Раббысының әмеренә буйсынып, аны тизрәк башкарырга ашыга, чөнки намаз, безне юктан бар кылучы, ризыкландыручы, безгә бу дөньяда бар нәрсәне бирүче, һәр яктан да безне тәрбия кылучы, галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә шөкрана кылыр өчен, рәхмәтебезне белдерер өчен бирелгән бер бүләк. Ул бүләкне безгә бирүче – Раббыбыз Аллаһы.

Шулай ук шөкрана һәм рәхмәтне белдерүдән тыш, мөэмин-мөселманнар өчен намазның файдасы бихисап, ягъни санап бетергесез дәрәҗәдә. Шул файдаларның берсе турында Расүли Әкрам салләллаһу

галәйһи вә сәлләм: «Зур гөнаһлардан сакланганда биш вакыт намаз һәм җомга намазы икенче җомгага кадәр араларында булган кечкенә гөнаһларның гафу ителүенә сәбәпче булырлар», – дип әйткән.

Ягъни биш вакыт намазыбызны җиренә җиткереп башкарсак, Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәгән булырбыз, Аллаһының рәхмәтенә ирешербез һәм шул вакытта кече гөнаһларыбызның гафу ителүенә бер адым ясаган булырбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен бу бик шатлыклы хәбәр, чөнки гөнаһлардан ничек кенә тыелсак та, кимчелекләрдән ерагайсак та, без барыбер хаталанырга, үзебез дә шуны сизмичә, гөнаһка керешергә мөмкин. Ләкин Аллаһының хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз укучыларга шатлыклы хәбәр җиткерә: биш вакыт намаз укучы һәм җомга һәм гает намазларында катнашучыларның кече гөнаһлары гафу ителә. Бу хәбәр мөэмин-мөселманнарга намазларын җиренә җиткереп башкару өчен, шулай ук бер этәргеч тә булып тора, чөнки берәр акыллы кешегә бер эш кушып та, аның хезмәт хакын ике, өч яисә дүрт тапкыр арттырыбрак бирәм дисәң, һичшиксез, ул кеше үзенең эшен тагын да яхшырак эшләргә тырышачак, тагын да бирелеп эшли башлаячак, намазларыбыз белән дә шулай ук булырга тиеш, безгә Аллаһы Тәгаләнең бу нигъмәтен дөрес итеп кулланырга кирәк.

Һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең, сәхабәләрнең намазга карата булган мөнәсәбәте шулай ук игътибарга лаеклы. Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм ничек намаз укыган соң, дигән сорауга, шундый җавап бирә алабыз: Аллаһының Расүле төнге намазларны озак укыганга күрә, аяклары шешәр дәрәҗәгә җитә иде. Һәм бу сүзләр нәфел намазлары хакында. Бу аңлатудан без шундый нәтиҗә ясый алабыз: пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа намазларын хакыйкый рәвештә, Аллаһы Тәгалә кушканча хошугълык белән укыган һәм безгә үрнәк күрсәтеп калдырган.

Намазны нинди рәвештә укырга дигәндә, Аллаһы хәбибенең безгә калдырган тагын бер киңәшен искә төшерергә кирәк: Җәбраил галәйһиссәлам Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ихсанның нәрсә икәнен сорагач, ул: «Гыйбадәт кылганда, намаз укыганда, Аллаһы Тәгаләне күргән төсле укыгыз, алай ук булдыра алмассыз, Аллаһы Тәгалә сезне күргән төсле укыгыз», – ди. Ягъни бирелеп, ни эшләгәнеңне аңлап, үзеңнең галәмнәрнең Раббысы, Тәрбиячесе Аллаһы Тәгалә каршында булганыңны истән чыгармыйча намаз уку дигәнне аңлата бу. Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Намаз – ул мөэмин-мөселманның мигъраҗы», – дигән хәбәрен дә истә тотсак яхшы булыр.

Үзен мөэмин-мөселман дип санаган кеше, биш вакыт намазын төгәл үти башлаганнан соң, үзенең игътибарын нәфел намазларына да юнәлтергә тиеш булыр, чөнки бу да пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте. Нәфел намазлар – ул адәм баласының Аллаһы Тәгаләгә карата булган мөнәсәбәтенең күрсәткече дә булып тора. Эшеннән тыш, үзенең өстендәге вазифаларын үтәгәннән соң буш вакытын, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын гына өмет итеп, гафләттә уздырмыйча, кешеләргә зарар китермичә, нәфел гыйбадәткә багышлаган кеше Раббысының рәхмәтенә ирешер, фарыз намазларының кимчелекләрен каплар өчен бер адым ясаган булып саналыр. Даими рәвештә нәфел намазы укыса, Аллаһы Тәгалә сөйгән гамәл башкарган булыр, чөнки Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән килгән бер хәдистә: «Аллаһы Тәгаләнең сөйгән гамәле – кечкенә генә булса да, ләкин даими рәвештә эшләнгән изгелек», – диелгән.

Нәфел намазларның төрлесе бар: тәһәҗҗөд намазы, хаҗәт намазы, доха намазы, әүвәбин намазы, һ.б. Мәсәлән, доха намазы тән сәламәтлегенә шөкер итү өчен укыла, дип әйтсәк тә була. Доха намазы махсус шуның өчен билгеләнгән. Расүлуллаһ: «Иртә җитү белән сезнең

һәрберегез һәр буын өчен садака бирергә тиеш: Аллаһыны һәр данлау – садака, Аллаһыны һәр мактау – садака, «Ләә иләәһә илләллаһ», ягъни Аллаһыдан башка илаһ юк, дип әйтү – садака, Аллаһыны һәр бөекләү – садака, яхшылыкка чакыру – садака, начарлыктан тыю – садака. Ләкин боларның барысын да доха намазы алыштыра», – дигән. Күрәбез ки, нинди саваплы һәм файдалы намаз икән ул доха намазы! Ләкин мөэмин-мөселман нәфел намазларын укып, фарыз намазларына зарар китерергә тиеш түгел. Фарыз дигән төшенчә тиешле дигәнне аңлата, аны үтәсәк, саваплы булабыз һәм өстебездәге вазифабызны башкарган булып саналабыз, үтәмәсәк гөнаһлы һәм бурычлы булып калабыз. Нәфел дигән төшенчә өстәмә, ягъни үз теләгебез белән башкарылган гамәл-гыйбадәт, үтибез икән, савапка ирешергә мөмкин, үтәмибез икән – гөнаһысы юк. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә фарыз гамәл-гыйбадәтләребезне җиренә җиткереп үтәп, нәфелләрне дә даими рәвештә башкарып, Үзенең ризалыгына ирешүне насыйп итсен.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илназ хәзрәт Габдуллин,*

*«Болгар» мәчете имамы*

*16 нчы декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# «Яшәр өчен ашыйм»

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәна, мактауларыбыз, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның әһеленә, гаиләсенә, пакъ булган нәселенә һәм сәхабәләренә сәламнәребез һәм салават-шәрифләребез ирешсен.

Мөселман кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә безгә тагын бер җомганы күрергә насыйп итте, һәм шушы җомга вәгазендә бераз гына булса да ашау-эчү әдәпләре турында сөйләшеп үтәрбез.

Гади генә әйткәндә, машинага йөрер өчен бензин, лампочкага кабынып, яктылык бирсен өчен электр, кеше исән булсын өчен су, һава, ризык кирәк. Көненә өч тапкыр әти-әниләргә дә шалтыратмаска мөмкинбез, көненә өч тапкыр кулга Коръән алып, Аллаһының сүзләрен дә укымаска мөмкинбез. Әмма көненә өч тапкыр вакыт табып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм «иң начар савыт» дип әйтеп калдырган «савытны» тутырырга тырышабыз. Әле ул гына да түгел, ул өч тукталыш арасында кыска гына булган тагын берничә тукталыш бар: чәй эчеп алу, өстәл яныннан үтеп киткәндә авызга берәр нәрсә кабып алу, кибет яныннан, йә кафе кебек берәр җирдән узып барганда, авыз тик тормасын әле, дип берәр тәмле нәрсә алып ашау – инде болары турында әйтеп тә торасы юктыр. Әйе, монда начар әйбер юк. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ كُلُوا مِمَّا فِي الْأَرْضِ حَلَالًا طَيِّبًا وَلَا تَتَّبِعُوا خُطُوَاتِ الشَّيْطَانِ ۚ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُّبِينٌ ﴿١٦٨﴾

**«Ий кешеләр! Җирдә хәләл, [бөтен шик-шөбһәдән] пакь булганнардан ашагыз. Шәйтанның эзләреннән бармагыз, чөнки ул [шәйтан] – сезнең ап-ачык дошманыгыз»**, – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:168

Шулай ук Коръәндә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُلُوا مِن طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ وَاشْكُرُوا لِلَّهِ إِن كُنتُمْ إِيَّاهُ تَعْبُدُونَ ﴿١٧٢﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Без сезне ризыкландырган [хәләл һәм] пакь нәрсәләрне ашагыз һәм, әгәр инде [Аллаһының бөтен нигъмәтләрнең иясе булганына ышанып] Аңа гына гыйбадәт кыласыз икән, [сезгә шулкадәр хәләл ризык биргәне өчен] Аллаһыга шөкер кылыгыз»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:172

Беренче аятьтә Аллаһы Тәгалә барлык кешеләргә мөрәҗәгать итә. Раббыбыз Әр-Рахмән һәм Әр-Рахим – Рәхимле һәм Шәфкатьле, мөселман булганына да, булмаганына да, яхшы кешегә дә, тискәресенә дә: «хәләл, [бөтен шик-шөбһәдән] пакь булганнардан ашагыз», дигән шарт куеп, җирдәге барлык нигъмәтләрне кулланырга мөмкинлек бирә. Беренчедән, ризыгыбыз хәләл, чиста һәм кешегә җитәрлек күләмдә булырга тиеш. Хәләл ризык турында әйткәндә, хайван чалу рәвеше дә, ризыкны табу ысулы да керә. Ягъни, ризыгыбыз шәригатебез кушканча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәтеп калдырганча булырга, чиста, ягъни тәнебезгә, акылыбызга зарар салмый торган, үләксә булмаган һ.б. шартларга туры килгән ризык булырга тиеш. Һәм әлбәттә, Изге Китабыбызда шәйтанның мәкерле юлларына, ятмәләренә эләкмәскә кушыла. Чыннан да, ризык культы элек тә булган, хәзер дә яшәп килә. ИншәАллаһ, бу хакта алдарак тукталып үтәрбез.

Икенче аятьтә Аллаһы Тәгалә мөселманнарга мөрәҗәгать итеп, мөэмин кешеләрнең ризыкка карата булган мөнәсәбәтләрен ачыклый. Беренчедән, шулай ук, бары тик хәләл, чиста, пакь булган ризыкларны гына кулланырга, икенчедән, шәйтан ятьмәләреннән ерак торуга Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү дә өстәлә. «Аңа гына гыйбадәт кыласыз икән, [сезгә шулкадәр хәләл ризык биргәне өчен] Аллаһыга шөкер кылыгыз». Ризык, гыйбадәт, шөкер итү – болар барысы да бик якын торган әйберләр. Элек-электән әби-бабайларыбыз бер-беренә ашар өчен яшисеңме, әллә яшәр өчен ашыйсыңмы дип сорау бирәләр иде. Кызганыч, андый дәвер юкка чыгып бара шул. Ә бит кешеләр дә, җеннәр дә гыйбадәт кылыр өчен яратылган булса, димәк, безнең кылган барлык башка гамәлләрбез, ягъни эш булсын, ашау булсын, ял итү һ.б. гыйбадәт кылырга булыша торган ярдәмлекләр генә булып кала.

Ризыкның нинди булуы, нинди юллар белән табылуы турыдан-туры безнең гыйбадәткә дә тәэсир ясый. Аятьтә килгән чиста, пакь ризыклар хакында без Пәйгамбәребезнең сөннәтеннән дә белә алабыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тузанга баткан, чәчләре тузынып беткән, ерак вакыт сәфәрдә булган бер кешене искә алып: «Ул кулларын күтәреп: «Йә, Раббым, йә, Раббым!» – дип кабатлый, әмма аның ризыгы харам, эчемлеге харам, өстенә кигән киеме дә харам, харам белән ашатылган булган, аңа ничек итеп җавап кайтарылсын соң?» – дип әйтә.

Өстәл янына көненә ничә тапкыр кунакка киләбез әле? Әйе, санап бетергесез! Ә күпме ашыйбыз? Ахырдан ябыгып бетергесез! Кадерле җәмәгать, безнең ризык безгә бу дөньяда яшәр өчен, гыйбадәт кылыр өчен, һәм, әлбәттә, кайвакыт күңелне күрер өчен дә кирәк була. Аллаһы Тәгалә безгә бу дөньяда ит белән суны гына барлыкка китермәгән бит: төрле-төрле җимешләре дә, яшелчәләре дә бар. Ашарга яраклы хайваннарның да төрләре бик күп. Ә савыт-саба? Безгә беркем дә ризыкларыбызны төрләндерүне, аларны матур-матур савытларда ашауны тыймый. Безгә

исраф тыела, гыйбадәтебезгә зыян китерә торган ризык тыела! Хикмәтен аңласак, барысын да шәригать кысаларында эшләргә була.

Икенче мәсьәлә – ризыкның күләме. Кадерле җәмәгать, өйдә бер кеше булса да кайвакыт бер кәстрүл аш пешә, ике кеше булса да шулай ук. Ул артык калганнан соң икенче көнгә бу ризык кичәге дип, анысын хайваннарга, кошларга дибез дә, икенче төрле ризык пешерергә тотынабыз. Әмма Җәбир исемле сәхабә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Бер кешенең ашый торган ризыгы – ике кешегә, ике кешенең ризыгы дүрт кешегә, ә дүрт кешенең ризыгы сигез кешегә җитә», – дип әйткән сүзләрен җиткерә. Ә без бүген, гафу итегез, сигез кешелек ризыкны дүрт кеше ашыйбыз. Ризык тулы ашказаны белән намаз уку ай-һай кыен шул. Шуңа да гыйбадәт кылырга хәл булсын, көч булсын өчен ашаганны онытмасак иде.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре бервакыт: «Ий, Пәйгамбәребез, без ашыйбыз, әмма туклану хисен тоймыйбыз», – дип әйттеләр. Пәйгамбәребез: «Сез аерым-аерым ашыйсыздыр?» – дип сорады. Сәхабәләр: «Әйе», – дип җавап кайтарды. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Алайса бергә җыелып ашагыз, Аллаһыны зикер итегез. Шулвакыт сезнең өчен бу ризык бәрәкәтле булыр», – дип әйтә. Шуңа да гаилә белән, дуслар белән бергә җыелып ашауда бәрәкәт бар. Менә шунда, бер кешенең ризыгы ике кешегә җитә, дигән хәдисне дә куллана алабыз: ашказаны да рәхмәтле була, без дә чиктән чыкмыйбыз.

Ашказаны безгә түгел, без ашказанына хуҗа булыйк. Аллаһының ризалыгын өмет итеп, гыйбадәткә, яшәргә, эшләр алып барырга җитәрлек күләмдә тукланыйк. Шул вакытта без гыйбадәт өчен генә ашаган булмабыз, ашавыбыз да үзе бер гыйбадәт булыр!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*23 декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Васыятьнамә һәм мирас

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Бүгенге вәгазь Исламда мирас бүлеп бирү мәсьәләсенә кагылачак. Аллаһы Тәгалә Үзенә генә хас хикмәт белән кеше вафат булгач, аның милкен варислары арасында дөрес итеп бүлеп биргән. Барлык бу кагыйдәләрне Коръәннең Ән-Ниса (Хатыннар) сүрәсеннән белә алабыз. Кызганычка, динсезлек чорында без шәригать буенча милек бүлүне тулысынча диярлек оныттык. Совет елларында барлыкка килгән мирас бүлү кануны бу өлкәдә тулысынча шәригать хөкемнәрен алыштырды. Мөселман илендә яшәмәгәнлектән, безгә Аллаһының кануннарын үзебезнең васыятьнамәләрдә язарга кирәк булачак. Ә хәзер аятьләрнең эчтәлегенә күз салыйк:

يُوصِيكُمُ اللَّهُ فِي أَوْلاَدِكُمْ لِلذَّكَرِ مِثْلُ حَظِّ الأُنْثَيَيْنِ

**«Аллаһы сезгә балаларыгыз хакында [шушы хөкемнәрне әмер һәм] васыять итә ки, ир балага ике кыз бала өлеше [бирелә]».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:11

Ислам диненең дошманнары бу хөкемне хатын-кызларның хокукларын бозу, аларга карата гаделсезлек кылу итеп кабул итә. Һәм шуңа да

бу урында тукталып китү дөрес булыр. Нигә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә милекне хатын-кызга, ир-атка караганда, ике тапкыр кимрәк бүлеп бирә?

Беренчедән, Аллаһы Тәгалә гаиләне барлык кирәк-яраклар белән тәэмин итү вазифасын ир-атка йөкләгән. Моннан ир-атның акча эшләргә һәм аны гаиләгә алып кайтып бирергә тиешлеге аңлашыла. Шәригать буенча хатын-кыз зур керемнәргә ия булса да, аның өстенә гаиләне тәэмин итү бурычы йөкләнмәгән. Әгәр хатын-кызның аерым бизнесы бар яки ул мөстәкыйль рәвештә акча эшли икән, ул бу акчаларны ничек тели, шулай куллана ала. Гаиләне тәэмин итү аның вазифасына керми. Әмма әгәр ир-атның гаиләне тәэмин итәр өчен керемнәре җитеп бетми икән, хатын-кыз мәрхәмәтлелек һәм кайгыртучанлык белдереп, гаиләне тәэмин итүдә иренә матди яктан ярдәм күрсәтә ала. Моның өчен аңа Аллаһы Тәгалә алдында аерым әҗер-савап әзерләнәчәк. Һәм шуңа да кабатлап әйтәм, гаиләне тәэмин итү – ул ир-ат бурычы һәм шул сәбәпле ул, хатын-кызларга караганда, акчага күбрәк мохтаҗ.

Икенчедән, өйләнер алдыннан кияү кәләшкә мәһәр бирергә тиеш. Бу – хатын-кызның ир-атка үзен тулысынча тапшыруы өчен хак. Моннан соң хатын-кыз аерыла калса, ул кияүгә чыкканчы беренче вакытта бу акча аның өчен гарантия булып торачак. Шуңа да мәһәрнең күләме җитди һәм сизелерлек булырга тиеш. Моны исәптә тотып, күп кенә мөселман илләрендә бик югары мәһәр күләме куела. Бүгенге көндә күп кенә гарәп илләрендә бер тапкыр аерылган хатынның яңадан кияүгә чыгуы мөмкин хәл түгел дәрәҗәсендә. Шуңа да мәһәргә бәяләр күтәрелә. Һәм ир кеше өйләнер алдыннан: «Бу кызга өйләнергә кирәкме икән?» – дип, җитди итеп уйланырга тиеш, чөнки аннары башка мәсьәлә туарга мөмкин: «Әгәр мин аның белән аерылсам, яңадан өйләнер өчен мәһәр җыя алачакмынмы?» Мәһәрнең зур булуы – уйланып бетерелмәгән никахлардан һәм кирәкмәгән аерылулардан тыя торган фактор ул. Шуңа да мәһәрне ир-ар түләргә тиеш булгач, аларның милекләре дә күбрәк булырга тиеш.

Бу ике төп сәбәпне исәптә тотып, Аллаһы Тәгалә ир балаларга, кыз балаларга караганда, өлешне ике тапкыр күбрәк биргән.

Аятьне дәвам итеп, Раббыбыз болай ди:

فَإِن كُنَّ نِسَاءً فَوقَ اثْنَتَيْنِ فَلَهُنَّ ثُلُثَا مَا تَرَكَ وَإِن كَانَتْ وَاحِدَةً فَلَهَا النِّصْفُ

**«Әгәр алар [мәрхүмнән калган балалар] икедән артык сандагы кызлар булса, ул калдырганнарының [мирасның] өчтән ике өлеше – аларга. Әгәр ул [кыз бала] берәү генә булса, аңа [калган малның] яртысы [тиешле]»;**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:11

وَلأَبَوَيْهِ لِكُلِّ وَاحِدٍ مِنْهُمَا السُّدُسُ مِمَّا تَرَكَ إِنْ كَانَ لَهُ وَلَدٌ

**«Әгәр аның [мәрхүмнең] баласы булса, калдырганнарыннан [мирастан] ата-анасының һәрберсенә – алтыдан бер өлеш».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:11

Ягъни ата-аналар үзләренең өчтән берен алгач, калган өлеш, югарыда искә алынган кагыйдә буенча (ир бала өлеше кыз баланыкыннан ике тапкыр артыграк) балалар арасында бүленә. Әгәр аның бары тик кызлары гына булса, алар һәм ата-анасының икесе дә үзләренә тиешлесен алганнан соң, калган өлешне гасба кагыйдәсе буенча мәрхүмнең әтисе үзенә ала. Ә бу мәрхүмнең бер генә кызы булганда яки аның әнисе булмаган очракта гына шулай эшләнә, монда алдан ук әти кеше алтыдан бер өлешне генә ала.

فَإِن لَّمْ يَكُن لَّهُ وَلَدٌ وَوَرِثَهُ أَبَوَاهُ فَلأُمِّهِ الثُّلُثُ

**«Әгәр аның баласы булмаса һәм варислары анасы белән атасы гына булса, анасына [мирас малының] өчтән бер [өлеше төшә]».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:11

Калган өлеше гасба кагыйдәсе буенча мәрхүмнең әтисенә була.

فَإِنْ كَانَ لَهُ إِخْوَةٌ فَلأُمِّهِ السُّدُسُ

**«Әгәр аның [ир яки кыз, ата-ана бер яки башка] туганнары булса, анасына алтыдан бер [өлеш төшә]».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:11

Калганнары милекне бүлү кагыйдәләре буенча, әтисе һәм ир туганнары арасында бүленә.

مِن بَعْدِ وَصِيَةٍ يُوصِي بِهَا أَوْ دَيْنٍ

**«[Бөтен бу өлешләр] Аның [мәрхүмнең] калдырган васыятеннән [аның шартлары үтәлгәннән] соң яки бурыч түләнгәннән соң [бүлгәләнә]».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:11

Ягъни милекне искә алынган нормалар буенча бүлә башлаганчы, мәрхүмнең барлык бурычларын түләп бетерү һәм аның васыятен үтәү мөһим.

Васыять мәсьәләсенә аерым тукталып китик. Сәхабәләрнең берсе Пәйгамбәребездән: «Варис булмаучыга милекнең кайсы өлешен васыять итәргә мөмкин?» – дип сораган. Моңа Пәйгамбәребез: «Өчтән берен, әмма монысы да күп», – дип әйткән. Бу шуны аңлата: әгәр без варис булмаучыга милкебезне васыять итәргә теләсәк, ул бурычларны түләп бетергәннән соң калган милекнең өчтән береннән күбрәк булмаска тиеш.

Шуңа да беренче эш итеп, мәрхүмнең бурычлары булуы хакында китерелгән язмача дәлил белән, аның бурычларының түләнеп бетүе

мөһим.

آبَاؤُكُمْ وَأَبْنَاؤُكُمْ لاَ تَدْرُونَ أَيُّهُمْ أَقْرَبُ لَكُمْ نَفْعاً فَرِيضَةً مِنَ اللَّهِ ۗ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلِيماً حَكِيماً

**«Аталарыгыз һәм улларыгызның кайсысы [дөньяда һәм Ахирәттә] файда җәһәтеннән сезгә якынрак булганын белә алмыйсыз. [Бу хөкемнәр сезгә] Аллаһыдан фарыз буларак [билгеләнгән]. [Сез иртәгә кемнән файда күрәчәгегезне белүдән гаҗиз булганда] Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче һәм Хикмәт иясе».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:11

Югарыда әйтелгәннәрдән билгеле булганча, бу тәртипләрнең үтәлүе мәҗбүри, ягъни алар безгә фарыз дәрәҗәсендә йөкләнгән.

Әгәр укылган аятьнең мәгънәсен тулысынча ачсак, без эзлекле рәвештә түбәндәге эшләрне башкарырга тиеш:

1. Мәрхүмнең барлык бурычларын түләп бетерү.

2. Аның васыяте буенча варис булмаучыларга өлеш чыгару, әмма бу өлеш мәрхүмнең бурычларын түләгәннән соң калганның өчтән береннән артмаска тиеш.

3. Бу ике гамәлдән соң калган милекне мирас милке дип атарга була.

4. Әгәр мәрхүмнең балалары булса, аның әти-әнисенең һәрберсенә милекнең алтыдан бере бирелә.

5. Ата-анага өлеш бүлеп бирелгәннән соң, калган милек балалар арасында түбәндәгечә бүленә:

а) әгәр аның бары тик малайлары гына бар икән, калган 2/3 яки 5/6 өлешләр алар арасында тигез итеп бүленә.

б) әгәр уллары да, кызлары да бар икән, калган өлеш, малайлар кызларга караганда ике тапкыр күбрәк алачак, дигән шарт белән бүленә.

в) әгәр аның ике һәм аннан да күбрәк кызлары бар икән, алар тигез итеп барлык милекнең өчтән икесен бүлә. Әгәр алардан тыш этиләре дә исән икән, үзенең тиешле алтыдан бер өлешеннән тыш, калган алтыдан бер өлешне дә ала.

6. Әгәр аның бер генә кызы булса, ул милекнең яртысын гына ала. Мәрхүмнең эти-әниләре арасында өчтән бер өлешне бүлгәннән соң, гасба кагыйдәсе белән эти кеше калган өлешне алып бетерә.

7. Әгәр үлгән кешенең балалары да, ир туганнары да булмаса, әнисе милекнең өчтән бер өлешен ала, калган өлеше этисенә кала.

8. Әгәр үлгән кешенең балалары юк, әмма ир туганнары бар икән, әнисенә алтыдан бер өлеше була, ә калганы гасба буенча этисе һәм ир туганнары арасында тигез итеп бүленә.

9. Әгәр югарыда искә алынган кешеләрнең берәрсе булмаса, милек якын туганнар арасында бүленә.

Моның белән мирас алу кагыйдәсе төгәлләнми. Сүрәнең 12 нче аятендә ир белән хатын арасында мирас бүлү һәм мираска кагылышлы башка сораулар карала. Әмма бүген сөйләшкән темабыз күләмле булганга күрә, бу мәсьәләләр турында сөйләшеп бетерүне киләсе вәгазьләргә калдырыйк, иншәАллаһ. Әйе, кагыйдәләр җиңел түгел, әмма без исем кушуны, мәетне юып, җирләүне белгән кебек, бу кагыйдәләрне дә белергә тиеш. Кызганычка, шәригать буенча мирас бүлү мәсьәләсендә, тулысынча башкарып чыктык, дип һәркем мактана алмый.

Йомгаклап, Аллаһы Тәгаләнең әлеге сүзләрен китерик:

وَمَن لَّم يَحْكُمْ بِمَا أَنزَلَ اللهُ فَأُولَئِكَ هُمُ الْفَاسِقُونَ

**«Кем дә кем Аллаһы иңдергән нәрсәләр белән хөкем итмәсә, алар – [биргән карарларында Аллаһының шәригатеннән чыккан] гөнаһкярлар»;**

«Әл-Маидә / Табын», 5:47

وَمَن لَّم يَحْكُمْ بِمَا أَنزَلَ اللهُ فَأُولَـئِكَ هُمُ الظَّالِمُونَ

**«Кем дә кем Аллаһы иңдергән [кыйсас кебек хөкемнәр] белән хөкем итмәсә, алар – залимнәр».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:45

وَمَن لَّم يَحْكُمْ بِمَا أَنزَلَ اللهُ فَأُولَـئِكَ هُمُ الْكَافِرُونَ

**«Кем дә кем Аллаһы иңдергән [кагыйдәләрнең дөреслеген белә торып, аларны чынга алмыйча, алар] белән хөкем итмәсә, алар – имансызлар».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:44

Өч урында Аллаһы Тәгалә Үз кануннары буенча яшәмәүчеләрне башта гөнаһкяр, аннары залим, ә аннары иң куркынычы – имансыз, дип атый.

Һәм шуңа күрә Аллаһы Тәгалә безгә мирас канунын мәҗбүри кылгач, без аны тиешенчә үтәргә тиеш. Ә шәригатебез кушканча башкарып чыгар өчен, бу нечкәлекләрне васыятьнамәләребездә искә алырга туры киләчәк. Безнең илдә Аллаһының язганнарын васыятьнамәгә нигезләнеп кенә үтәргә мөмкин. Кызганычка, безнең башка юлыбыз юк. Аллаһы Тәгаләдән бу вәгазьнең файдалы булуын һәм аны тормышка кертеп җибәрә алуыбызны сорыйм.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Җиһаншин,*

*Габдрахим Утыз Имәни исемендәге*

*Ал Таң мәчете имам-хатыйбы*

*30 нчы декабрь вәгазе,*
*җөмәдәл-ахыр аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Хәерле әҗәл бирсәң иде

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Бүген без сезнең белән сөйләшеп үтәсе мәсьәлә үлем хакында булыр. Аның әчесе-төчесе, тормышыбыздагы урыны, үлемгә Ислам диненең мөнәсәбәте, үлемнең Ислам дине аша карашыбызны формалаштыруы турында сөйләшербез.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм Раббыбыз Аллаһы үлем хакында уйландыра торган, әмма без игътибар бирмәгән мәгълүматлар әйтә. Мәсәлән, Коръәни Кәримдә үлем «мәхлүкъ» дип китерелә, ягъни үлем кешеләр кебек үк, мәхлүкъ икән. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ٱلَّذِي خَلَقَ ٱلْمَوْتَ وَٱلْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا ۚ وَهُوَ ٱلْعَزِيزُ ٱلْغَفُورُ ﴿٢﴾

**«Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты [сезнең кылачакларыгыз хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне**

**бирәчәк]. Ул – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:2

Раббыбыз кайсыбызның гамәлләре күркәмрәк булуын сынар өчен, шушы ике әйберне бар кылган. Әгәр дә гарәп телендә ике әйбер бергә килә икән, беренче итеп аларның өстенрәге искә алына. Үлем мөселман кешесе өчен бик кирәкле мизгел булып тора, чөнки ул Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә тулысынча кайту мизгеле. Без намаз да укыйбыз, ураза да тотабыз, әмма Аллаһыга тулысынча итагать итәбезме? Юк! Ә менә үлем мизгеле килгәннән соң, без тулысынча Аллаһы Тәгаләгә генә буйсынырга мәҗбүр булабыз. Кешегә үлем килгәндә аның «Бу тормышка мәңгегә килдем», дигән уйлары да, нәфес котырынулары да юкка чыга, аларга, гомумән, урын калмый. Чыннан да, күп кенә фәлсәфәчеләрнең, кызганыч, әмма хәтта кайбер мөселманнарның да бу дөньяда мәңгегә каласылары килә. Алар гел ниндидер могҗиза көтә, сихри бер дару эчеп, гомерләрен мәңгелек итмәкче булалар. Әмма хәтта ки Кыяматкә кадәр яшәгән кешенең дә, ул көн җиткәч, җаны алыныр. Муса галәйһиссәламне искә алыгыз. Аңа, кара үгезнең йон бөртекләре кадәр гомер яши аласың, диелгәч, ул: «Бөртекләрнең саны бармы, алар чиклеме?» – дип сорады. Инде Раббыбыз аларның чикле икәнен белгерткәч, Муса галәйһиссәлам: «Күпме язылган, шуларына риза булам», – дип, 120 яшен тутырып бу дөньядан китеп барды.

Әлбәттә, Раббыбыз мәңгелек мәсьәләсенә ноктаны Коръәни Кәримдә үк куя:

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ

**«Һәр җан иясе үлемне татыячак».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:35

Без һәрберебез дә үлемне татучылардан булып торабыз. Шулай булгач, без моңа ничек әзерләнә алабыз соң? Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә күп киңәшләрен калдырган. Беренчедән, ул Ахирәт тормышын бу дөньяга караганда күбрәк яратырга киңәш иткән. Мәсәлән, кеше үзенең бу дөньяга артык бирелүеннән курка, ди. Әмма әгәр ул Аллаһы Тәгалә йөкләгән биш вакыт намазны үтәп барса, дөнья белән мавыгуы артыкка китмәячәк, Аллаһы боерса. Без, нәфесебез теләмәсә дә, иртәнге намазга уянабыз. Барып тәһарәт алабыз, намазыбызны укыйбыз... Уянмасак, йоклап калсак нәрсә була? Дөрес, ул очракта да намазыбыз өстебездән төшми. Торгач та, барыбер барып тәһарәт алабыз, укымыйча калдырган намазыбызны укыйбыз, һәм шулай итеп, нәфесебез белән көрәшәбез. Ә сез иртә белән торганнан соң нәфеснең иң яратмаган эше нәрсә булуын белә идегезме? Ул – аяк юу. Ә без камил тәһарәт алып, намазга басабыз, нәфесебезгә каршы барабыз. Ә аннан соң, күп кеше төшке аш ашарга чапканда, без нәрсә эшлибез? Без төшке ашыбызны тиз генә ашыйбыз да, өйлә намазына басабыз. Икенде белән дә, ахшам белән дә шулай ук. Кеше, дөньясына бирелеп, башы белән эшкә чумганда, намаз вакыты җитә һәм ул намаз безнең нәфесне тәрбияли. Тәһарәт алганда аякларыбызны юабыз һәм шуның белән нәфеснең аягына сугабыз, намазларыбызны укыйбыз һәм нәфеснең авызына туфрак сибәбез.

Ураза гыйбадәте вакытында да без нәфесебез белән көрәшәбез. Аллаһы Тәгалә Рамазан аенда бер ай ураза тоту шарты белән, 11 ай буе безгә тәүлекнең теләсә кайсы вакытында хәләл ризыкларны ашауны рөхсәт иткән. Рамазанда без бер ай хәләл ризыктан да тыелып торабыз. Шулай ук Рамазанда ураза тотарлык сәламәтлек тә булырга тиеш. Шуңа да без Рамазан аена сәламәтлегебезне саклап, аны кадерләп торыйк һәм Рамазанда бер ай уразабызны тотыйк. Шулвакыт безнең нәфесебез дә тәрбияләнер. Ә тәрбияле нәфесне Раббыбыз Аллаһы Тәгалә дә ярата,

яраткан нәфесенә Раббыбыз йомшак, күркәм үлем дә бүләк итә.

Пәйгамбәребезнең тагын бер киңәше: ул үлемне ярату. Үлемне ярату ни дигән сүз соң? Үлемне ярату – бу дөньяда яшәгәндә камил рәвештә Ахирәт тормышың өчен гамәлләр кылу ул. Кеше үлемнән соң булган тормышын ярата икән, ул бу дөньяда булдыра алганча күбрәк торырга тырыша, чөнки күбрәк торган саен, күбрәк намаз укый, Рамазан ае уразасын тота, зәкятен түли, булдыра алса – хаҗга бара, Аллаһыны зикер итә, нәфесен тәрбияли... Ахирәткә әзерләнү – дөньяда вакытта нәфесеңне тәрбияләү инде.

Беребез дә үлемнең хакыйкатен аңламый, чөнки аны аңлар өчен аның аша үтәргә кирәк. Ә бу дөньяда андый кеше булган – ул Ильяс галәйһиссәлам. Ильяс пәйгамбәр үлем турында күп вәгазьләр сөйли торган иде. Бервакыт ул Раббыбыздан үлемне күрсәтүен сорагач, Аллаһы Тәгалә аңа бу дөньяда ук үлүне һәм кабаттан терелүне насыйп итә. Инде үлемнән соң кабат бу дөньяга кайткач, ул: «Мин вәгазьдә сөйләгәннәремнең бик кечкенә булуын аңладым, ә чын-чынлап үлемне тату ул, гомумән, икенче икән», – дип әйтә.

Шуңа күрә, кадерле җәмәгать, өстебездә булган фарызлар, вәҗибләр берсе дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә болай гына йөкләнмәгән. Азган нәфесебезне тәрбияләү, Ахирәткә әзерлек шушы әйберләр аша бара. Шуңа да бу дөньяда иң камил рәвештә барыбызга да үлемгә әзерләнергә насыйп булса иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин,*

*Коддус мәчете имам-хатыйбы*

*6 нчы гыйнвар вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Киләчәккә план кору, үткәннәргә нәтиҗә ясау

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Адәм баласы кадерен белми торган ике нигъмәт бар. Ул – буш вакыт һәм сәламәтлек»[1], – дигән. Чыннан да, без еш кына безгә әманәт булып бирелгән сәламәтлегебезнең кадерен белеп бетермибез, ә буш вакытны, гомумән дә, санга сукмыйбыз. Үзебез һаман вакыт җитми, бер атна бер көн кебек үтә, дип сөйләнсәк тә, вакытыбызга карата тиешле игътибарны күрсәтмибез.

Вакыт – ул савыттан ага торган су кебек. Су савыттан агып беткәч кенә без аның юклыгын күреп алырга мөмкин. Гомер дә шулай ук, олы кеше: «Гомер үтте», – дип әйткәндә, яшьләр бу сүзләрнең мәгънәсен тулысынча аңлап бетерми.

Кеше гомере сәгатьләрдән, көннәрдән, атналардан, айлардан, еллардан тора. Һәр ел үткән саен без тормышыбызның яңа битен ачабыз, олыгаябыз, яшебез арта. Әмма китап битен ачкан сыман, тормыш китабыбызның яңа битен ачу белән, ябылган битләргә карап, дөрес нәтиҗә ясый алсак иде. Бәлки үткән елыбыздан гыйбрәт алырга кирәк

1 Имам Әл-Бохари, имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

булып та, без җитди карамаган вакыйгалар булгандыр? Бәлки шөкер әйтәсе урында, рәхмәтсез булганбыздыр, ә бәлки хакларын үтәргә тиеш булган кешеләребез алдында бурычыбыз калгандыр? Бәлки без уйлап та карамаган, ә Галәмнәрнең Раббысы алдында гөнаһ булып язылган сүзләр әйтелгән, гамәлләр кылынгандыр?

Быел 2023 елга аяк бастык. Югарыда әйтелгәннәр хакында уйланып, 2022 елда булган вакыйгаларны күз алдыннан үткәрә, аларга карап дөрес нәтиҗә чыгара алсак иде, чөнки яңа елга керү – киләчәккә план кору һәм үткәннәргә нәтиҗә чыгару ул. Кеше бу нәтиҗәне яңа елга кергәч кенә түгел, ә һәр яшәгән көненең киче җиткәч ясый алса иде, чөнки ул әллә нинди акчалар түләсә дә, әллә нинди зур мөмкинлекләре булса да, үткән көнен кайтарып алу аның ихтыярында түгел. Кеше эшли алган бердәнбер әйбер – ул дөрес итеп нәтиҗәләр ясый белү. Тугры хәлиф Гомәр радыяллаһу ганһе: «Сезгә хисап кылынганчы, үз-үзегезгә хисап кылыгыз. Гамәлләрегез үлчәнгәнче, үзегез гамәлләрегезне үлчәгез», – дип әйткән.

Әлхәмдүлилләһи, тагын бер ел яшәдек, яңа елларга кердек. Шуңа да һәр көнебезне мәгънәле, файдалы итеп уздыра алсак иде. Көн үтсенгә генә яшәп, безгә бирелгән зур мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмасак иде. Ә мөмкинлекләр барлык кешегә дә бер төрле бирелә. Исән-сау кеше өчен кояш чыга, яңа көн туа, башкаларга бирелгән 24 сәгать аңа да бүләк ителә һәм аның бу көнне кичәнге көнгә караганда да яхшырак, файдалырак, мәгънәлерәк итеп уздырыр өчен, изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, Раббысына якынаер өчен мөмкинлеге бар. Кешедән бу мөмкинлекне күрә белү һәм дөрес итеп куллану гына таләп ителә. Бөек галим, табигыйн Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи: «Ий адәм баласы! Син – ул синең көннәрең. Һәм көн үткән саен синең бер өлешең китә», – дип әйткән.

Һәр яңа көн безгә мондый сүзләр белән мөрәҗәгать итә икән: «Ий Адәм баласы! Мин – яңа көн һәм мин синең гамәлләреңнең шаһиты. Мине файда белән үткәр, чөнки әгәр мин китсәм, Кыямәт көненә кадәр

беркайчан да кайтмаячакмын».

Әйе, безнең көннәребез, вакытыбыз, минутларыбыз Раббыбыз тарафыннан безгә бирелгән әманәт булып тора. Һәм Кыямәт көнендә без алар өчен җавап тотачакбыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көнендә адәм баласыннан: гомере һәм аны ничек уздыруы, гыйлеме һәм аның белән ничек гамәл кылуы, байлыгы һәм аны каян табуы, нәрсәгә сарыф кылуы, тәне һәм аны нәрсәгә файдалануы хакында соралмыйча, аяклары урыныннан кузгалмас»[1], – дип әйткән.

Яңа елга аяк басу – үткәннәргә нәтиҗә ясау, киләчәккә планнар кору ул, дидек. Нәтиҗә ясаганда Раббыбызга биргән нигъмәтләре өчен шөкер әйтергә, белеп һәм белми кылган хата-кимчелекләребез өчен тәүбә-истигъфар сорарга онытмасак идек. Чыннан да, хатам бардыр, дип, Раббыбызга тәүбә кылу һәм биргән нигъмәтләргә, әлхәмдүлилләһ, дип, шөкер сүзләрен әйтү безнең ике дөнья тормышыбыз өчен дә мөһим. Шөкер әйтү, Раббыбызга рәхмәтле булу хакында Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип әйтә:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ۖ

**«Әгәр шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә [нигъмәтләрне тагын да] арттырачакмын».**

«Ибраһим», 14:7

Ә гөнаһларыбызны искә төшереп, аларга тәүбә кылу хакында Коръәндә:

إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ

**«Һичшиксез, Аллаһы тәүбә итүчеләрне һәм тәмам чистарынучыларны сөя»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:222

1 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен риваять иткән: «Әгәр кеше теле белән тәүбә кылудан (истигъфар) туктамаса, Аллаһы Тәгалә аңа теләсә нинди авыр хәлдән дә чыгу юлын күрсәтер, һәртөрле күңелсезлектән азат итәр һәм көтмәгән җирдән ризыкландырыр».

Шулай булгач, үткән хата-кимчелекләребезне искә алып тәүбә-истигъфар кылу, үз-үзебез алдында хисап тоту, фикерләп, үткән тормышыбыздан дәрес алу – ул үткәннәргә нәтиҗә ясау була. Ә инде киләчәккә план коруга килгәндә, һәрберебез дә Раббыбыз биргән гомерне файдалы һәм мәгънәле итеп үткәрергә теләгәнгә күрә, телебездә һәрдаим Раббыбыздан һәр башлаган эшләребезне хәерле кылуы, ярдәменнән, рәхмәтеннән аермавы өчен дога кылсак иде. Пәйгамбәребез өйрәткән күркәм дога беркайчан да телебездән төшмәсен:

رَبَّنَا آتِنَا فِى الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِى الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

Укылышы: «Раббәнәә әәтинәә фид-дүнйәә хәсәнәтән вә фил-әәхырати хәсәнәтән вә кыйнәә гәҙәәбән-нәәр. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин».

Мәгънәсе: «Йә Раббым! Безгә дөньяда да, Ахирәттә дә изге хәлләрне насыйп ит. Шулай ук безне җәһәннәм газабыннан сакла! Әй Рәхмәтле Аллаһы! Бөтен нәрсә Синең рәхмәтеңдә».

Һәр эшебездә Яратучыбызга хәмед-сәналәребезне әйтеп, рәхмәтле, шөкерле булып, тәвәккәл итеп яшик. Һәм һәрвакытта да Аллаһы Тәгаләнең:

وَمَا تَشَاءُونَ إِلَّا أَن يَشَاءَ اللَّهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ ﴿٢٩﴾

**«...галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы теләмәсә, сез тели алмаячаксыз»,** – дигән сүзләрен истә тотыйк.

«Әт-Тәквир / Төрү», 81:29

Раббыбыз теләсә, Аның рәхмәте белән безнең дә теләкләребез тормышка ашар, башкарырга теләгән планнарыбыз да үтәлер, әмма моңа Раббыбызның ризалыгы кирәк. Шуңа да киләчәк көннәребезгә планнар корганда Раббыбыздан хәерлесен сорап, Аңа ихлас күңелдән тәвәккәл итеп мөрәҗәгать итик, киләчәк көннәребезне күбрәк изге гамәлләр кылырга, якыннарыбызга, безнең ярдәмгә мохтаҗ булучыларга ярдәм итәргә омтылып яшик. Аллаһы Тәгалә һәр яңа елыбызны үткәннәргә нәтиҗә ясап, киләчәккә изге ният-максатларны билгеләп каршы алырга насыйп кылса иде, Үзенең киң Рәхмәте белән безнең гомеребезне дә файдалы һәм бәрәкәтле итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Хозур редакциясе*

# Үрнәк затлар

# Рабига Әл-Гадәвиянең тәкъвалыгы

Без Ислам диненең башлангыч чорларында танылган суфи шәехләр хакында күп ишеттек, алар хакындагы гыйлемнәр бүгенге көнгә кадәр безне гаҗәпкә калдыра. Әмма мондый кешеләр арасында тәкъвалыклары, камиллекләре һәм изге гамәлләр кылулары белән генә түгел, ә кайбер шәехләрдән дә өстенрәк булулары белән аерылып торган хатын-кызлар яшәгәнлеген билгеләп үтми мөмкин түгел. Әлеге бөек хатын-кызларның берсе – Рабига Әл-Гадәвия.

## Хәзрәти Рабиганың балачагы һәм яшьлеге

Хәзрәти Рабига Басра шәһәрендә, ярлы гаиләдә дөньяга килә. Ул дүртенче бала булып туган булуы мәгълүм, шуңа да аңа Рабига исеме бирелгән (сүзгә-сүз тәрҗемәсе – «дүртенче»).

Фәрид Әд-Дин Гаттар аның хакында болай дип язган: «Рабига төнлә дөньяга килде. Аның әти-әнисенең хәтта яктырткычлары да юк иде. Рабиганың әтисе шулхәтле тәкъва кеше иде, хәтта ул берьюлы кешеләрдән бернәрсә дә сорамаска вәгъдә биргән була. Хатыны аңа яктырткыч һәм бераз май бирүләрен сорап, күршеләргә мөрәҗәгать итәргә куша. Әмма ул чыгып китә дә, ишек артында бераз торып, кабат әйләнеп керә һәм хатынына: «Барлык күршеләр дә йоклый, мин сорар кеше тапмадым», – дип әйтә. Шуннан соң ул ятып тора һәм беразга йоклап китә. Рабиганың әтисе төшендә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күрә, ул аңа: «Күңелсезләнмә, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә сиңа игелекле бала җибәрә, ул бөек әүлия булачак, ә аның шәфәгате минем өммәтемнең 70 мең кешесенә насыйп булачак», – дип әйтә. Моннан соң пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа Басраның әмиренә акча сорап мөрәҗәгать итәргә куша. Әмирнең ярлыларга ярдәм итүе – вәгъдәсен

бозган өчен кәффарәт була. Бу хатта Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип язарга әмер итә: «Әмирнең исенә төшер: һәр төндә ул миңа – 100, ә җомгага каршы төндә 400 салават әйтә. Бу җомгада ул әлеге гадәтенә салкын карады, шуңа да, моның кәффарәте итеп, сиңа 100 динар бирсен», – ди. Рабиганың әтисе уянгач, үзенең күргән төшен язып куя да, аның хакта әмиргә хәбәр итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзе хакында искә алуына куанган әмир Рабиганың әтисенә 400 динар бирергә куша».

Риваятьләр буенча, әти-әнисенең үлеменнән соң, әле бала вакытында ук, хәзрәти Рабига коллыкка сатып җибәрелгән. Һәм аңа кечкенәдән авыр эштә тир түгәргә туры килгән. Көндез ул ураза тоткан һәм өй эшләрен эшләгән, ә төннәрен берөзлексез гыйбадәттә булган. Берьюлы төнлә уянган хуҗасы аны сәҗдә кылган халәттә күргән, бу вакытта хәзрәти Рабига: «Ий Аллаһым! Син Минем йөрәгемнең бары Сиңа гына омтылганын беләсең. Мин үземне тулысынча Синең әмерләреңә багышларга теләр идем, әмма Синең теләгең белән, мин Синең мәхлүкъларыңның берсе булган кешенең кул астында, шуңа да мин Сиңа хезмәт итүдә соңарам, гәрчә бер генә сәгатемне дә юкка үткәрәсем килмәсә дә», – дип Аллаһыга мөрәҗәгать иткән.

Хуҗа кеше бу хәлгә гаҗәп калган һәм, мондый тәкъва хатын-кызны коллыкта тотарга хакым юк, дип карар кылган. Иртән ул аны азат иткән. Моннан соң хәзрәти Рабига зөһедлеккә (аскетлык ред.) бирелеп, тулысынча үзен гыйбадәтләр һәм изге гамәлләр кылуга багышлаган. Ул һәр тәүлек саен меңәр рәкәгать намаз укый торган булган.

Берьюлы аңа Басра хакиме – Мөхәммәд бине Сөләйман Әл-Хашими өйләнергә теләвен белдергән, әмма хәзрәти Рабига: «Сез хәтта барлык байлыкларыгызны миңа тапшырсагыз да, мин бер мизгелгә генә дә Аллаһыдан аерылып, сезгә юнәлә алмыйм», – дип, аның тәкъдимен кире каккан.

## Хәзрәти Рабиганың гыйбадәте һәм тәкъвалыгы

Хәзрәти Рабига көне-төне гыйбадәттә булган, бары тик кояш чыгар алдыннан гына үзенә бераз ял итеп алуны рөхсәт иткән.

Ибне Әл-Җәүзинең «Сыйфат әс-сафват» китабында бервакытны хәзрәти Рабиганың хәлен белергә килгән Габдулла бине Гайсәнең сөйләве искә алына, ул: «Мин Рабиганың өенә кергәч, аның йөзе һәрдаим елаганга күрә нур белә балкыганына игътибар иттем», – дигән.

Аның көчле тәкъвалыгы хакында башка китапларда да искә алына. Ул Аллаһыдан оялып, кырык ел буена бер тапкыр да башын да күтәрмәгән.

Рабига Әл-Гадәвия үзе дә аның вәгазьләренә йөргән, аның замандашы булган Хәсән Әл-Басри хәзрәти Рабиганың яшәү рәвешен тасвирлаганда аның өендә бер урыны ватылган су сала торган кувшин гына булуы турында хәбәр иткән. Аның мендәре урынына кирпеч булган, ә гыйбадәтне хәзрәти Рабига салам ише нәрсәдән үрелгән келәмдә кылган. Аның өендә болардан башка берни дә булмаган. Бүләкләр кабул итүдән хәзрәти Рабига баш тарта һәм «Минем дөньяга ихтыяҗым юк», – дип әйтә торган булган.

## Хәзрәти Рабига турында риваятьләр

Бервакыт аның янына ике олуг шәех килгән. Тамаклары ачыккан бу кешеләрнең Рабиганың өендә аларга бары хәләл ризык кына тәкъдим ителәчәгендә шикләре булмаган. Алар кереп утыргач, хәзрәти Рабига алар каршына ике күмәч куйган, әмма бу вакытта аның ишегенә ике ярлы кеше шакыган һәм хәзрәти Рабига ул күмәчләрнең икесен дә аларга биреп чыгарган. Кунаклар бу хәлгә гаҗәпләнгән, әмма дәшмәүләрен дәвам иткәннәр. Бераздан ишеккә кабат шакыганнар. Хезмәтче кыз унсигез кайнар күмәч салынган кәрзин алып килгән, әмма шәехләрне шаккаттырып, хәзрәти Рабига аңа кәрзинне кире биргән һәм, монда ниндидер

хата бар, дип аны чыгарып җибәргән. Күпмедер вакыттан соң хезмәтче кыз яңадан әйләнеп кайткан һәм бу юлы аның кәрзинендә егерме күмәч булган. Хәзрәти Рабига бу күчтәнәчне кабул итеп алган һәм кунакларга тәкъдим иткән. Кунакларның аннан бу гамәле хакында кызыксынуына ул болай дип җавап биргән: «Мин шундый мәртәбәле кешеләргә ике күмәч тәкъдим итәргә оялдым һәм шуңа күрә аларны ярлы кешегә биреп: «Йә Аллаһым! Син биргән садакаларыбызны ун тапкыр арттырып кайтаруны вәгъдә кылдың. Мин садака итеп ике күмәч бирдем, миңа ун тапкыр арттырып кайтарсаң иде», – дип дога кылдым. Хезмәтче кыз миңа унсигез күмәч алып килгәч, мин монда хата бар дип уйладым, чөнки мин егерме күмәч алырга тиеш идем. Шуңа да үземнең сораганым китерелгәнгә кадәр, аларны кайтарып бирдем».

Шул рәвешле Рабига Әл-Гадәвия гомерен Аллаһыга хезмәт итүгә, гамәл-гыйбадәткә багышлаган тәкъва иясе булып яшәгән.

Хәзрәти Рабига олы яшькә кадәр яшәгән дип риваять ителә. Вафат булу вакыты турында фикер каршылыгы бар: йә ул 135/753, йә 180/796, йә 185/801 елларда бакыйлыкка күчкән.

*Гөлназ Ситдикова*

# Шәхесләребез

# Исеме һәм хезмәте онытылмас Фаиз хәзрәт

*«Гыйлемне бишектән алып ләхеткә чаклы өйрәнегез»*

*хәдис.*

Аллаһыга шөкер, без бүген динебез өчен бар мөмкинлекләр ачылган, рәхәтләнеп мәдрәсәләрдә дини һәм дөньяви белем алып, мәчетләрдә моңлы азан тавышы тыңлап, намаз укып, вәгазь белән җаныбызны, әхлагыбызны нурландырып һәм баетып, дин кардәшләребез белән аралашып була торган заманда яшибез. Динебезнең болай алга китүендә дәүләтебезнең дә, җитәкчеләребезнең дә, күренекле дин әһелләребезнең дә һәм, әлбәттә, имам-хатыйб, муллаларыбызның да өлеше бик зур. Бу чылбырда бер генә өлеш өзелеп китсә дә, кем дә булса мәсьәләгә битараф караса, динебезнең, милләтебезнең, телебезнең киләчәгенә зыян килергә мөмкин. Шуңа күрә бу изге юлда хезмәт куйган һәм куючы дин кардәшләребезгә илебездәге һәр мөселман кешесе рәхмәтледер дип уйлыйм.

Бу уңайдан без – Ядегәр авылы халкы аеруча да бәхетле. Ни өчен дисезме? Чөнки безнең авылыбыз җирлегендә туган һәм яшәгән, нәкъ менә халыкның дини вә гыйлемле булуын кайгыртып, рухи яктан бай җан азыгы белән туендырып торган, һәр кешенең күңеленә ачкыч таба, аларның киләчәген күрә белгән һәм кайгыртып калдырган имам-хатыйбыбыз Фаиз хәзрәтебез бар. Фаиз абый 2013 елның 22 нче ноябрендә бакыйлыкка күчсә дә, аның хакта «Иде» дип әйтергә тел әйләнми, чөнки хәзрәтебез бүген дә безнең арада яшидер кебек тоела. Аңлаганыгызча, сөйлисе сүзем Йосыф (Миннемулла) улы Фаиз хәзрәт хакында барачак.

Фаиз абый 1942 елның 28 нче августында Ядегәр авылының күп балалы укытучы гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Араларында аралашучан, күп белергә теләве, белемгә хирыслыгы белән аерылып тора ул. Башлангыч һәм урта белемне үз авылларында алгач, тимерче

һөнәрен үзләштереп, 26 ел буе авылыбызның трактор һәм машина паркында тимерчелектә эшли. Төп эшеннән тыш, Фаиз абыйның бик оста итеп чардуганнар ясавын (ул вакытта хәзерге кебек заказ биреп кенә ясату мөмкинлеге юк иде), аннан бер дә кеше өзелмәвен әле дә хәтерлим. Аның лаеклы ялга чыгу вакыты авылыбызга газ кертү чорына туры килде, һәм ул яшьтәшләре Мансур абый, Миннехан абыйлар белән бергәләп халыкны газлы итеп йөрделәр. Нәкъ менә шушы вакытларда динебезгә игътибар арта башлады да инде, динебезгә карата мондый уңай үзгәреш безне дә читләтеп үтмәде. Авылыбыз халкы 1991 елларда үз мәчете булу бәхетенә иреште. Менә шушы урында, авылыбызның мәчетле, халкының дини яктан белемле булуында зур роль уйнаган шәхесләр Габделхак ага Каюмов, аның җәмәгате Наҗия апа турында әйтми китсәм, дөрес булмас. Ә аларга бу эштә ярдәм һәм теләктәшлек итүчеләр район, Ядегәр җирле үзидарәсе, күмәк хуҗалыгы белән беррәттән, Фаиз абый, Мансур абый, Миннехан абыйлар булды дисәм, беркемне дә үпкәләтмәм дип уйлыйм.

Мәчет төзеп кенә эш бетми, әле бит аның гөрләп эшләп торуы, мәчеткә йөрүчесе дә кирәк. Озак еллар Габделхак абый, җәмәгате Наҗия апа белән язын, көзен, кышын, яңгыр дими, кар дими, Ядегәргә дин сабаклары укытырга йөрделәр. Авылыбыз халкы аларны бүген дә хәер-догасы белән искә ала.

Фаиз абый нәкъ менә шул елларны дин юлына кереп китте дә инде. Моңарчы да ул җаны-тәне белән дин юлында булгандыр дип уйлыйм. Һәркемгә мәгълүм булганча, кешенең кайчан да булса, бу фани дөнья белән саубуллашу вакыты җитә, һәр мөселман кешесе соңгы юлга үзен дини йолалар буенча, җиренә җиткереп, матур итеп озатуларын тели. Бу җаваплы эшне һәркем башкарып чыга ала микән? Ә менә Фаиз абый… Ул бу эшләрне зур җаваплылык, чиста-пөхтә итеп башкаруы белән аерылып тора иде. Кемнең кем булуына карамастан, ул һәркемгә бертигез хөрмәт һәм илтифат күрсәтә иде. Үлем-җитем булса, аларны юу, кәфенләү, ләхет

алу кебек зур эшләргә авыл халкы гел аңа мөрәҗәгать итә, Фаиз абый исә бу эшләрне шул вакыттагы хәзрәтебез Фәйзрахман ага белән чын күңелдән, бер дә авырсынмыйча, тартынмыйча эшли иде. Ул гына да түгел, күп кешеләрнең соңгы юлга Фаиз абый озатуын сорап, васыять әйтеп калдыруларын да беләм. Ә олыгая барган Фәйзрахман ага җай белән генә Фаиз абыйны үз урынына әзерләгән икән. Өлкән хәзрәтебез дөнья куйгач, авылыбыз халкы һич икеләнмичә мулла итеп Фаиз хәзрәтне билгеләде, һәм һич тә ялгышмады.

Фаиз абый авылыбызның мулласы гына түгел, берничә авылга имам-хатыйб та булып торды: күрше авылларның муллалары да (хәтта аннан олыраклары да) аңа киңәш сорап килә, яки, киресенчә, аңа үзенең киңәше белән ярдәм итә. Хәзрәтебез мулла булып торган чорда башкарган күпкырлы эшчәнлеге күпләрнең игътибарына лаек дип уйлыйм. Аларның кайсысын гына алып карасаң да, барысы да иң кирәклесе кебек тоела. Хәзер үткәннәргә әйләнеп карыйсың да, исең-акылың китә, олы яшьтә булуына карамастан, ул барысына да өлгергән, барысын да оештырган, барысын да булдырган...

Фаиз абыйның иң зур эшләренең берсе – авыл халкын дингә, мәчеткә тарту булгандыр. Ул мәчетебездә муллалык итә башлаган чорда динебез өчен зур мөмкинлекләр ачыла башласа да, бу халыкның диннән хәйран гына ерагайган, читләшкән вакыты иде. Яшьләр дөнья куа, ә олыларның әлегә мәчеткә әллә ни исләре китеп тормый. Әле дә хәтердә: алар – авылның биш-алты карты – Әсхәт абый, Гамбәр абый, Мансур абый, Миннехан абый, Рушан абыйлар – ел әйләнәсендә беркайчан да биш вакыт намазны калдырмадылар. Авылыбыз өстендә һәрдаим биш вакыт намазга чакырып, моңлы азан тавышы яңгырап торды.

Шулай бер сөйләшеп утырганда, Фаиз абый: «Минә остазым Габделхак абый белән сөйләштем әле. Борчуларым белән уртаклаштым. Халык мәчеткә йөрми бит, дим. Остазым миңа болай диде: «Фаиз, син

үзең сайлаган юлдан тайчанма, кыйблаңны туры тот, биш вакыт азан тавышын яңгыратырга онытма. Ул барыбер халык йөрәгенә үтеп керер», – дип әйтте...», – дигән иде. Габделхак абыйның сүзләре фәрештәләрнең «әәмин» дигән сәгатенә туры килде ахрысы, Фаиз хәзрәтнең дә тырышулары бушка китмәде, халык әкренләп мәчеткә тартыла башлады. Баштарак җомга намазына гына җыелсалар, тора-бара авылдашларыбызның күбесе көндәлек намазны да мәчеткә килеп укый башлады. Аеруча куандырганы – яшьләрнең дингә тартылуы иде. Әлбәттә, бу – Фаиз абыйның хезмәт җимеше. Ул халык белән аралашуга, аның белән эшләүгә аерым игътибар бирә иде. Җомга намазларында, җәмәгать белән җыелган вакытларда, авылдашларыбызның төрле уңайдан Коръән укыту, берәр бәйрәм мәҗлесләренә багышланган чараларны Фаиз ага һәрвакыт үзенең үтемле вәгазьләре белән башлап җибәрә. Аннан үзенә генә хас моңлы мәкам белән укыган Коръән тавышы яңгырый иде. Күпләрегезне хәзрәтебезнең дини белеме кызыксындырадыр. Юк, Фаиз абый Ислам университетларын тәмамлаган муллалардан түгел. Ләкин ул гомере буе үзенең белемен күтәрү өстендә эшләгән, һәм дөньяви, һәм дини белеме белән күпләрне сокландырырлык шәхес булды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең «Гыйлемне бишектән алып ләхеткә чаклы өйрәнегез», – дигән хәдисе нәкъ менә аның турында әйтелгән кебек.

Әйтеп үткәнемчә, башлангыч дини белемне ул остазы Габделхак агадан алган, соңрак Кукмара мәдрәсәсендә дәвам иткән, һәм тәкъдим иткән бер генә мөмкинлектән дә баш тартмыйча (Казан шәһәрендә дин белгечләре өчен оештырган курслар булсынмы яки башкалар), гомере буе белем эстәгән кеше. Алай гына да түгел, аның белемгә хирыслыгы шулкадәр көчле иде ки, ул хәтта халкыбыз үткәргән аш-мәҗлесләрендә садака итеп дини китаплар, календарьлар, төрле брошюралар өләшә иде. Шушы урында, форсаттан файдаланып, тагын бер шәхесне искә алып китим әле. Ул да булса, Габделхак абыйның энесе – Заһит абый. Заһит абый

чыгышы белән Ядегәр авылы кешесе, бүгенге көндә Казан шәһәрендә гомер кичерә. Фаиз абый Заһит абый белән һәрвакыт элемтәдә тора, алдан хәбәр итеп, үзенең киләсен әйтә, һәм алар Заһит абый белән очрашып, бергәләп, Казан буйлап сәяхәткә чыгып китәләр. Заһит абый, һич иренмичә, аны дини китаплар сатыла торган төрле кибетләргә, билгеле мәчет, мәдрәсәләргә алып бара, һәм алар халык өчен кызыклы һәм кирәк булган дини характердагы һәр төрле китап, календарь, китапчыклар туплап йөриләр. Шулай итеп, Фаиз хәзрәт атнаның теләсә кайсы көнендә Казанга чыгып китеп, сумкаларын тутырып төргәк-төргәк китаплар алып кайтыр иде. Бу изге юлда хәзрәтебезне ярдәмегездән ташламаган өчен, сезгә дә рәхмәт, Заһит абый!

Әле бит шуның өстенә, авылдашларыбызның күзен ачасы, белемле итәсе, намаз укытасы, Коръән өйрәтәсе дә килә. Шуңа күрә дә, озак та үтми Фаиз абый мәчеттә өлкәннәр һәм балалар өчен дини дәресләр оештырып җибәрә. Ислам университетын тәмамлап кайткан югары белемле абыстаебыз Сәмиева Разия апалар, һәрьяктан (шул исәптән дини яктан да) активлыгы белән күпләргә үрнәк булырлык Әсхәдуллина Вәсилә апалар бу эштә аңа зур ярдәмчеләр, аның белән иңгә-иң куеп эшләүчеләр булдылар. Фаиз хәзрәт хезмәттәшләре белән уртак тел табып, балаларны үсендереп, аларның күңеленә ачкыч табып, яратып эшли белде, алга таба да уку өчен аларга юл күрсәтте. Шулай булмаса, алар кул астында укып, белем алган күп кенә авылдашларыбыз үзләренең белемнәрен Кукмара мәдрәсәсендә дәвам иттермәсләр иде. Һәр уку елы ахырында мәчетебездә бәйрәмнәр – ярышлар, Сабантуйлар, мөселман лагерьлары оештыру, шәкертләрне төрле җирләргә – Кукмара, Арча, Казаннарга экскурсияләргә алып бару, һәм, хезмәтенә күрә хөрмәтен күрсәтеп, ел буе балаларны укыткан укытучыларга бүләкләр тапшыру да, бу эштә зур роль уйнагандыр.

Бу урында Фаиз аганың тагын бер зур эшен искә алмасам, дөрес булмастыр. Ул авыл халкын динле һәм мәчетле иткән, Фаиз аганың гына түгел,

күпләребезнең остазы булган Габделхак абыйның исемен мәңгеләштерү. Фаиз аганың тынгысыз җан булуы, остазларын онытмавы, кешеләрнең яхшылыгын күрә белүе сәбәпле, мәчетебез бүгенге көндә шушы бөек шәхеснең – Габделхак абый исемен йөртә. Бу зур эшне башкарып чыгу өчен күпме көч сарыф ителгәнен Фаиз абый үзе генә белгәндер.

Муллаларның, җирле үзидарәнең тагын бер игътибарга лаек эшчәнлеге – ул да булса, зиратларны карап, чистартып, тәртиптә тоту. Бу нисбәттән дә, Фаиз ага күпләргә үрнәк булып торырлык муллаларның берсе булды. Ул бу эшкә яз көне җирләр кипшүгә тотына, көз җитеп, кар төшмичә туктамый иде. Әлбәттә, монда Фаиз аганың искиткеч оештыру сәләте, җитәкчеләр белән уртак тел табып, транспорт һәм башка мәшәкатьләрне көйләве – аның ни дәрәҗәдә оста дипломат булуын да күрсәтә. Ул бу эшне җайлап, бөтен нечкәлекләрен уйлап эшли: халык белән киңәшеп, көнен билгели, бу турыда пичәтләп авыл буенча берничә җиргә игълан ябыштырып чыга, әйтеп үткәнемчә, җитәкчеләр белән сөйләшеп, кирәкле транспортын да таба иде. Шулай итеп, яздан көзгәчә зиратыбызда берничә тапкыр өмә оештырыла: зиратыбыз чүп-чардан арындырыла, карт агачлар киселә, чардуганнар, ташлар тәртипкә китерелә, җәй көннәрендә үләннәр чабыла. Шуңа да мәчетебез генә түгел, зиратыбыз да нурга күмелеп утыра. Анда кайчан гына аяк басма, өлкәннәребез, кайткан кунаклар рәхәтләнеп зыярат кылып китә.

Күпләрегездә, ә бүгенге көндә бу мәчет ни хәлдә, дигән сорау туар. Халык мәчеткә йөриме? Дини белем бирү дәвам итәме? Әлбәттә, әйе! Менә болары инде – Фаиз аганың хезмәт җимешләре. Бүгенге көндә мәчетебездә муллалык вазыйфаларын Фаиз хәзрәтнең шәкерте Гаяз Сабирҗанов дәвам итә. һәм әйтергә кирәк, остазының йөзенә кызыллык китерми, бу эшне зур җаваплылык белән җиренә җиткереп башкара. Фаиз абый башлаган һәр эш тә бүгенге көндә бик күркәм итеп дәвам ителә. Ул гына да түгел, күптән түгел мәчетебездә Габделхак абыйның улы Зөфәр

абый ярдәме белән бик зур төзекләндерү эшләре башкарылды, һәм иң куандырганы – авылыбыз халкы мәдрәсәле булды. Хәзер бу турыда зур горурлык белән әйтергә була – Фаиз абыйны без генә түгел, киләчәк буыннар да онытмас. Ни өчен дисезме? Чөнки мәдрәсәбез безнең күңелләрдә җуелмас эз калдырган Фаиз хәзрәт исемен йөртә. Җомга көннәрендә генә түгел, көн дә мәчетебездә халкыбыз җыелып намаз укый, балаларыбыз мәдрәсәдә белем ала, зиратыбыз да нур сибеп тора.

Моннан тыш, Бөек Җиңүнең 75-еллыгына шундый эш башкарылды: Фаиз абый тарафыннан тутыкмый торган тимергә чукып язылган Ядегәр авылыннан Бөек Ватан сугышына китеп, кабат әйләнеп кайта алмаганнарның исемлеген Зөфәр улы Рөстәм белән гранит такталарга күчереп, шунда онытылган исемнәрне өстәп, «Алар җиңү алып кайттылар» дип язып, яңа истәлек стенды булдырылды. Һәм әлеге такталарны мәчет диварына элеп куярга булдылар. Мәчеткә керүче һәркем тактадагы исемлектән үзенең һәлак булган туганнарын табып, дога кылып яисә кылдырып чыгарлар дип ышанабыз.

Үткәне барның – киләчәге бар, дигән халкыбыз. Фаиз абый, Сез бүген безнең белән горурлана аласыз, Сезнең изге эшегез бүген дәвам итә, һәм киләчәк буыннар да Сезне онытмас, динебезнең киләчәге нурлы булыр.

*Сөнгатуллина Рузилә*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# Июнь-июль-сентябрь

## 2022 елда Татарстаннан 810 мөселман хаҗ кылды

Изге сәфәргә дин кардәшләр Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән бергә барды. Быел хаҗ сәфәрен кылу Рәсәй мөселманнары өчен 2020 елда пандемия башланганнан бирле беренче мөмкинлек булды. Ул Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның 2021 елда «Рәсәй – ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең күчмә утырышы кысаларында куйган тырышлыклары нәтиҗәсендә килеп чыкты: мәйданчыкларның берсендә Президент Согуд Гарәбстаны хаҗ һәм гомрә эшләре буенча министр урынбасары Габделфәттах бине Сөләйман Машат белән очрашу вакытында Рәсәй мөселманнары өчен быел гомрә һәм хаҗ кылу мөмкинлекләрен ачуны сорап мөрәҗәгать иткәннән соң, мәсьәлә уңай хәл ителде. «Спутник V» вакцинасын Согуд Гарәбстаны таныды һәм әлеге вакцинаны ясаткан Рәсәй мөселманнарына гомрә кылу, ә аннан хаҗ кылу мөмкинлеге дә бирелде.

## Казанда Җәмигъ мәчет эскизын эшләү буенча халыкара конкурста җиңүчеләрне игълан иттеләр

Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көнендә (8 июльдә), Корбан бәйрәме алдыннан, Казан Ратушасында Казан Җәмигъ мәчете һәм аның янәшәсендәге территориянең эскиз проектын эшләү буенча ачык халыкара бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләделәр. Алар 6 июльдә жюрига үз проектларын тәкъдим иткән иде. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ачык халыкара конкурсның жюри утырышында Мәккәдән торып катнашты.

Ике этапта узган бәйгегә 8 илдән 40тан артык гариза кабул ителде. Бәйге нәтиҗәләре буенча, беренче урынны «Гинзбург Архитектс» архитектура-реставрация бюросы һәм шәхси эшмәкәр Айвар Саттаров бүлеште. Икенче урынны «Сретенские Архитектурные Мастерские» ҖЧҖ (Мәскәү, Рәсәй) һәм HASSA архитектура-инженерлык төзелеше (Истанбул, Төркия) яулады. Өченче урынны OSTA ҖЧҖ (Казан, Рәсәй) алды. Моннан тыш, КДАТУның 3 нче курс студенты Артем Сидоров Татарстан Президенты һәм Рәсәй Төзелеш министры кулыннан махсус бүләккә лаек булды. Һәр катнашучыга Татарстан Президентының Рәхмәт хаты тапшырылды.

Конкурс 2022 нче елның 1 нче апрелендә, ягъни изге Рамазан аена бер көн кала игълан ителгән иде. Җәмигъ мәчете нигезенә беренче таш салу тантанасы 20 нче майда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар кысаларында узды.

## Татарстанда Корбан бәйрәме билгеләнеп узды

Татарстанда зурлап Корбан гаете узды. Югары дәрәҗәге әзерлек һәм оештыру нәтиҗәсендә, олуг бәйрәм мөселманнарга гына түгел, республиканың барлык күпмилләтле халкына да чын шатлык бүләк итте. Шәкертләр һәм өлкәннәр, инвалидлар һәм йортсызлар, ятимнәр һәм ялгыз аналар, күпбалалы һәм аз керемле гаиләләргә – Корбан бәйрәмен түземсезлек белән көтеп алучыларга – милләтенә һәм диненә карамастан, корбан итләре тапшырылды.

2022 елда республикабызда Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре күзәтчелегендә корбан чалу гамәлен башкару өчен 40-ка якын махсус мәйданчык, шул исәптән Казанда 17 мәйданчык оештырылды. Республикада шушы мәйданчыкларда барлыгы 13 396 баш мал чалынды, шуның 49ы – мөгезле эре терлек. Шул исәптән, Казанның үзендә 5735 баш хайван корбанга чалынды.

Татарстан районнары һәм шәһәрләре арасында алдынгы булып Яр Чаллы мөхтәсибәте тора: бирედә 1300 сарык корбанга чалынды. Аннан соң Әлмәт, Яшел Үзән, Чистай мөхтәсибәтләре килә – аларда 1200 шәр баш сарык. Казанда иң күп мал чалган урыннар булып, «Казан нуры» (2088 сарык), «Рамазан» (651 сарык) һәм «Ризван» (450 сарык) мәчетләре тора.

Болардан тыш, Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды социаль акция кысаларында халыкның мохтаҗ катламнарына тарату өчен өстәп тагын 250 сарык чалды. Корбан гаете көннәрендә «Зәкят» хәйрия фонды 300-ләп мохтаҗ, аз керемле һәм күп балалы гаиләләргә, инвалидларга, ятимнәргә, ялгыз гомер итүче олы яшьтәге кешеләргә корбан ите таратты. Алдагы еллардан аермалы буларак, быел «Зәкят» хәйрия фонды корбан итенең бер өлешен суыткычларга саклауга куеп, аны ел дәвамында төрле хәйрия ашларында мохтаҗларны ашату өчен файдалана. Шул рәвешчә, быел Нәзарәтнең «Зәкят» фонды 3,5 тонна корбан итен мохтаҗларга таратты һәм социаль проектларга җибәрде.

## Яңа Чишмәнең Акъяр авылында яңа мәчет ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 17 нче көнендә (16 нчы июльдә), Яңа чишмә районының Акъяр авылында яңа мәчет ачылу тантанасы узды. Яңа мәчеткә «Хәйдәр» исеме бирелде. Авыл үзәгендәге яңа ике катлы гыйбадәт йорты акъярларның бердәм тырышлыгы, шул исәптән бу авылда туып үскән ТР Дәүләт Советы депутаты, «Татэнергосбыт» АҖ директоры Рифнур Сөләйманов ярдәме белән 11 ай эчендә сафка басты. Яңа мәчет 150 кешегә исәпләнгән. Беренче катта – ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханә, ашханә урын алган, икенче катта – уку сыйныфы, фарыз залы һәм имам бүлмәсе урнашкан. Гыйбадәт йорты янәшәсендә балалар өчен мәйданчык эшләнгән, агачлар утыртылган. Бүгенге көндә Яңа чишмә мөхтәсибәтендә 12 мәчет эшли.

## Бөрбашта «1100 еллык» уңаеннан XV Рәсәйкүләм мөселман балалар Сабан туе үтте

Зөлхиҗҗә аеның 18 нче көнендә (17 нче июльдә), Балтач районы Бөрбаш авылында XV Рәсәйкүләм мөселман балалар Сабан туе узды. Әлеге күркәм чара быел унбишенче тапкыр Балтач районы имам-мөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның тырышлыгы белән оештырылды. Биш меңнән артык кешене – бишектәге сабыйдан алып, өлкән яшьтәге абый-апаларны бер мәйданга җыеп китергән Сабантуй Татарстанда Корбан бәйрәме уңаеннан үтә торган гаилә бәйрәмнәренең дә иң зурысы булды. Әлеге дини һәм милли чара үсеп килүче яшь буында татар халык гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләүне максат итеп куйды. Сабантуй балаларның Коръән һәм догалар укулары, мөнәҗәт әйтүләр, шигырьләр белән үрелеп барды. Бәйрәм барган вакытта күпләгән аттракционнар, уен заллары, сәүдә нокталары, хәләл аш-су, туклану урыннары эшләде. Барлык кунаклар һәм катнашучылар милли баш киеменнән – ир-атлар түбәтәйдән, хатын-кызлар яулыктан булды.

## «Минбар» журналында Камил хәзрәт Сәмигуллинның фәнни мәкаләсе дөнья күрде

Абруйлы «Минбар» ислам журналында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның «Җәһәннәмнең мәңгелеге мәсьәләсенә сөнни дин галимнәренең карашы» дигән яңа фәнни мәкаләсе дөнья күрде. Мәкалә бүгенге көндә актуаль булган дини проблемага, аерым алганда, тәмугның чиксезлеге турындагы мәсьәләгә багышлана. Мәкаләдә дин галимнәренең, шул исәптән, Рәсәйдә эшчәнлек алып баручыларының да, бу темага багышланган аерым чыганакларына күзәтү тәкъдим ителә. Шулай ук сөнниләр тоткан исламның җәһәннәм һәм андагы җәзаның чиксезлеге мәсьәләсенә карата теологик характердагы кайбер аңлатмалар бирелә.

## Болгарда XIV Бөтенрәсәй мөселман яшьләре форумы узды

Болгарда 23-31 нче июль көннәрендә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган XIV Бөтенрәсәй мөселман яшьләре форумы узды. Җыенны оештыручылар – ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм күрсәтү фонды. Форумда Казахстан һәм Мисыр кебек чит илләрдән, Татарстаннан, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсеннән, Оренбург, Екатеринбург, Тубыл һәм Чабаксардан, Кемерово, Пенза, Чиләбе өлкәләреннән, Самара, Новосибирск, Волгоград, Ижау, Пермь, Уфа, Чиләбе, Первоуральск һәм башка шәһәрләрдән 200 гә якын егет һәм кыз катнашты.

Җыен программасы 3 төрле чаралардан – тарихи, дини һәм проектлау өлешләреннән торды. Барлык лекцияләр, практикумнар, мастер-класслар, квестлар, экскурсияләр Рәсәйдә Ислам тарихы турындагы белемнәрне киңәйтүгә һәм тирәнәйтүгә, яшьләрнең шәхси, иҗади, рухи-әхлакый үсеше өчен кирәкле шартлар тудыруга юнәлтелгән иде. Форумда катнашучылар үзләренең Рәсәй өммәте ихтыяҗларын исәпкә алып эшләгән социаль башлангычларын тәкъдим итте.

Атна дәвамында белгечләр карамагына 100гә якын социаль башлангыч тәкъдим ителде. Алар арасында: интернет, кино, мәгърифәтчелек, инфраструктура, экология, спорт, хәйриячелек белән бәйле булган, шулай ук хатын-кызлар, балалар һәм яшьләр, шәхси үсеш өчен атап эшләнгән проектлар бар. Алар арасыннан 17 иң яхшы проект сайлап алынды. Шулардан 3 иң яхшы идея сайлап алынып, акчалата премиягә – проектны гамәлгә ашыру өчен башлангыч капиталга лаек булды.

## Алабугада «1100 еллык» уңаеннан «Туган батыр» I Бөтенрәсәй турниры үтте

22-24 нче июль көннәрендә Татарстанда беренче тапкыр җәядән ату буенча «Туган батыр» Рәсәйкүләм турниры узды. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган турнир меңьеллык тарихка ия Алабуга шәһәрендә оештырылды. Җәядән ату буенча Алабуга шәһәрендә оештырылган турнирда катнашу өчен Дагыстан, Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан, Әстерхан, Самара өлкәсеннән, Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләреннән, Татарстанның район-шәһәрләреннән килделәр. Көн дәвамында барлыгы 65 кеше уктан атып ярышты. Турнирны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Алабуга шәһәре һәм Алабуга районы мөхтәсибәте, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы хакимияте, Казан шәһәренең «Туган авылым» милли комплексы, Башкортстан Республикасының «Мәргән уксы» атка утырып ату һәм традицион җәядән атуны үстерү буенча автоном коммерцияле булмаган оешмасы; «МАКСАТ» ир-атлар спорт клубы, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Татарстан Республикасының җәядән ату федерациясе оештырды.

## Казанның мохтаҗ гаиләләре азык-төлек белән тәэмин ителде

Зөлхиҗҗә аеның 29 нчы көнендә (28 июльдә), Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды 50 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек җыелмалары таратты. Хәйрия фондыннан әлеге ярдәмне бер ялгызы балалар үстерүче аналар, күп балалы гаиләләр, ялгыз пенсионерлар, авыру мохтаҗлар, инвалид бала тәрбияләүчеләр алды. Азык-төлек җыелмасында он, ярмалар, көнбагыш мае, шикәр, тушенка, макарон һәм чәй бар. Фонд тарафыннан

азык-төлек җыелмалары дин кардәшләребез биргән садакалар, битараф булмаган кешеләрнең матди ярдәме белән әзерләнде. 2022 елның 7 ае эчендә мохтаҗларга барлыгы 952 шундый җыелма таратылды.

## Югары Ослан район үзәк хастаханәсендә намаз уку бүлмәсе ачылды

Июль аенда Югары Ослан район үзәк хастаханәсендә намаз уку бүлмәсе эшли башлады. Бүгенге көндә Татарстан Республикасының барлык район хастаханәләрендә дә диярлек намаз уку бүлмәләре бар. Моннан тыш, намаз уку өчен 2 бүлмә Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсендә (Чаллы) эшли. Казанда зур медицина учреждениеләрендә шулай ук намаз бүлмәләре бар, болар – МКДЦ, РКБ, ДРКБ, Республика клиник онкология диспансеры, 7 нче поликлиника.

## Арчада Г.Тукай исемендәге рухи-мәгърифәт үзәге ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 30 нчы көнендә (29 нчы июльдә), Арча мөхтәсибәтендә республика күләмендә зур тарихи вакыйга булды – Габдулла Тукай исемендәге рухи-мәгърифәт үзәге үз ишекләрен ачты. Әлеге зур чара Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы кысаларында үтте.

Габдулла Тукай исемендәге рухи-мәгърифәт үзәге, 2021 нче елның 21 июнендә нигез салынып, бер ел эчендә сафка басты. Өч катлы үзәктә өч уку классы, бер конференц-зал, шулай ук ашханә, китапханә, ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханәләр урын алган, бинаның гомуми мәйданы – 800 квадрат метр. Үзәк заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән. Рухи-мәгърифәт үзәгенә килеп, берьюлы 80 кеше белем өсти ала.

## Мөфти «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе коллективына яңа директор урынбасарын тәкъдим итте

Мөхәррам аеның 4 нче көнендә (2 нче августта) Татарстан мөфтие, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директоры Камил хәзрәт Сәмигуллин уку йортында барлык укытучылар катнашында киңәшмә уздырды. Көн тәртибендәге төп сораулар арасында яңа уку елын оештыру, студентлар өчен төзелгән яңа тулай торакны һәм корпусны эшләтеп җибәрү, агымдагы кабул итү кампаниясенең барышы һ.б. каралды. Мәдрәсә директорының уку-укыту буенча урынбасары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин әлеге мәсьәләләр буенча чыгыш ясады, ә укытучылар аларны тормышка ашыру өчен үзләренең тәкъдимнәрен җиткерде. Җыелыш кысаларында мәдрәсә директорының яңа урынбасары тәкъдим ителде. Әлеге вазифаны Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның күренекле имамы Рөстәм хәзрәт Хәйруллинга тапшырды. Моннан тыш, Камил хәзрәт кадрлар әзерләүнең сыйфатын күтәрү өчен яңа укытучылар җәлеп ителәчәген дә хәбәр итте.

## «Ватаным Татарстан» һәм Диния Нәзарәте «Безнең авыл имамы» бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләде

Мөхәррам аеның 14 нче көнендә (12 нче августта), Казанда «Безнең авыл имамы» бәйгесенә тантаналы рәвештә йомгак ясалды. Әлеге бәйге 2022 нче елның март аенда «Ватаным Татарстан» газетасы тарафыннан Татарстан мөфтияте белән берлектә игълан ителгән иде. Ул Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланды. Бәйге барышында «Ватаным Татарстан» газетасында җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында кырыкка якын язма дөнья күрде. Хатларның күпчелеге – Буа, Мамадыш, Арча, Питрәч районнары укучыларыннан. Бәйгедә җиңүчеләрне Татарстан мөфтиятенең берен-

че урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов бүләкләде. Бәйге нәтиҗәләре буенча Татарстанның Диния нәзарәтенең махсус премиясенә Буа районыннан Иске Суыксу авылы имамы Линур хәзрәт Сабирҗанов турында язган Әлфинур Йосыпова лаек булды. Җиңүчеләрнең барысына да Татарстан мөфтияте Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүгә 1100 еллык уңаеннан бастырып чыгарган Коръәннең репринт «Казан басмасы» бүләк ителде, акчалата премия бирелде.

## Әлмәт шәһәре мөхтәсибәте «Мусаллә» хәйрия акциясен башлап җибәрде

Әлмәт шәһәре мөхтәсибәте «Мусаллә» хәйрия акциясен башлап җибәрде. Әлеге проект, дин кардәшләребезнең ихтыяҗларыннан чыгып, намаз уку бүлмәләрен ачуга юнәлдерелгән. Намаз уку бүлмәләренә ихтыяҗ булган урыннар халыктан сораштыру үткәреп билгеләнде. Намаз бүлмәләрен ачуда хәйриячеләр һәм оешмалар бик зур ярдәм күрсәтә. Әлмәт мөхтәсибәте «Әнсар» хәйрия фонды белән хезмәттәшлектә Татарстан нефтенең 60 еллыгы исемендәге шәһәр паркында намаз уку бүлмәсен ачты.  Юлчылар һәм җирле халык «Заходи» кием-салым кибете җитәкчелеге биргән урында да («Находка» кибете бинасында) намаз укый ала. Автовокзал янында намаз уку бүлмәсен булдыру өчен әзерлек алып барыла.

## «Хозур» нәшрияты рус телендә әдәп һәм әхлак буенча зур күләмле хезмәт бастырып чыгарды

Татарстан мөфтиятенең «Хозур» нәшрият йорты Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәтенә багышланган күләмле уку әсбабын әзерләп бастырды. Ул –  олуг галим Сайид Ализадэның «Ширгател Ислам. Ислам әхлагы һәм әдәбе» («Шир‘атуль Ислам. Ахляк и ада-

бы Ислама») исемле китабы. Биредә Коръәни Кәрим һәм Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәте буенча яшәргә омтылган, камиллек юлына талпынган, үзендә Раббыбызга карата эчкерсез ярату хисләрен, тәкъвалык, ихласлылык, сабырлык һәм башка күркәм сыйфатларны тәрбияләргә теләүче мөэмин кешесенә кирәкле булган барлык тәртипләр һәм кагыйдәләр тәфсилләп тасвирланган.

## Арча мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Мөхәррам аеның 16 нчы көнендә (14 нче августта), Арча районы Яңа Ашыт авылында яңа мәчет ачылды. Күркәм вакыйгада катнашучыларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән аның мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров сәламләде һәм мөселман кешесе тормышында мәчетләрнең әһәмияте, аларны кадерләү хакында вәгазь-нәсыйхәтләрен җиткерде.

Мәчеткә Әлминә исеме бирелде. Әлминә Нигъмәтҗанова – шушы авылда 20 елдан артык абыстай булып хезмәт иткән, халыкка дин нигезләрен җиткергән шәхесләрнең берсе. Мәчетнең имамы – Мәгърүф хәзрәт Рәүпов. Кырык кеше сыйдырылышлы гыйбадәт йортында ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханә, барлык уку кирәк-яраклары бар. Бина җылыту һәм электр энергиясе белән тәэмин итү системасына тоташтырылган. Киләчәктә әлеге мәчеттә Арча шәһәре Г.Тукай исемендәге рухи-мәгърифәт үзәге мөгаллимнәренең дәресләр алып баруы көтелә. Бүгенге көндә Арча мөхтәсибәтендә 93 мәчет исәпләнә.

## Кукмара мөхтәсибәтендә төбәкара V Мәчкәрә укулары узды

Мөхәррам аеның 19 нчы көнендә (17 нче августта), Кукмара районында «V Мәчкәрә укулары» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды.

Әлеге чара Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан Диния Нәзарәтенең Кукмара мөхтәсибәте һәм Кукмара районы Башкарма комитеты тарафыннан оештырылды. Фәнни җыенга дин әһелләре, күренекле галимнәр, төбәк тарихын өйрәнүчеләр, фән һәм җәмәгать эшлеклеләре, милли мирас, мәдәният, татар дин гыйлеме фикере үсеше белән кызыксынучы шәхесләр, каләм ияләре, хәйриячеләр, шәкертләр килде.

Җыен башланганчы, кунаклар өчен төбәкнең үзенчәлекләре һәм ташъязма мәдәни мирасы белән таныштыру чаралары, экскурсияләр оештырылды: бай тарихи дини мираска ия булган Мәчкәрә авылының иске зиратында саклана торган кабер ташларын, төзекләндерү эшләре башланган Мәчкәрә авылының борынгы Беренче Җәмигъ мәчетен күрсәттеләр. Аннан соң алар Кукмара шәһәренең Туеш микрорайонындагы мәчете каршындагы «Һидәят» рухи-тәрбия үзәген ачуда катнашты.

Төштән соң Кукмара мәдәният йортында конференциянең пленар утырышы узды. Быел «Мәчкәрә укулары» «Мәчкәрә авылы: тарих һәм яңарыш проблемалары» дигән темага багышланды. Җыен нәтиҗәләре буенча резолюция кабул ителде. Анда яшь буынга динебезнең әхлакый принципларын, бай тарихыбызны җиткерү, мәдәни һәм рухи мирасыбызны саклап калу юнәлешендә тәкъдимнәр урын алган.

## Татарстан Милли китапханәсендә «Туган Батыр» китабын тәкъдим иттеләр

Мөхәррам аеның 20 нче көнендә (18 нче августта), Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Туган Батыр» китабы тәкъдим ителде. Әлеге проект «Туган авылым» милли-туристлык комплексы җитәкчеләренең берсе, танылган мөселман меценаты Радик Абдрахманов һәм Татарстан Республикасы мөфтие, ТР мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллинның уртак башлангычы, китапның

авторы – танылган язучы Зөлфәт Хәким. Китапны алар тәкъдим итте дә инде. «Туган Батыр» – балалар һәм яшьләр арасында татар батыры образын торгызу һәм популярлаштыру буенча чараларны гамәлгә ашыра торган бренд. Бу юнәлештә беренче адым – образның концепциясен һәм аның брендын эшләү булды. Татар батырын сәнгать әсәрләрендә күрсәтү өчен, тарих, халык авыз иҗаты, әдәбият, бренд тудыру буенча белгечләр җәлеп ителде. Концепция милли геройга хас иң кыйммәтле сыйфатлар чагылыш тапкан татар мәкальләренә, әкиятләренә һәм бәетләренә үткәрелгән контент-анализ нәтиҗәләре буенча булдырылган. Проектның максаты: үз халкының игелекле, көчле рухлы сакчысы һәм улы – батыр образын торгызу һәм популярлаштыру; яшьләрне милли гореф-гадәтләргә тарту, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү, гаилә традицияләрен, туган телне һәм мәдәниятне саклап калу.

## Чүпрәледә XV Мунчәли укулары узды

Мөхәррам аеның 22 нче көнендә (20 нче августта), Чүпрәле мөхтәсибәтенең Мунчәли авылында унбишенче тапкыр «Мунчәли укулары» дини фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде. Дини җыен, милли гореф-гадәтләребезне саклау ниятеннән, Татарстан мөфтияте, Бөтендөнья татар конгрессы теләктәшлегендә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел, Мунчәли авылы мәчетенә нигез салынуга 25 ел тулуны билгеләп үтү чаралары кысаларында оештырылды. Мунчәли мәчете каршында узган тантаналы ачылышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашып, Чүпрәле районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илмир Измайловка «Бердәмлек» медален тапшырды.

«Мунчәли укулары» кысаларында районкүләм шәкертләр бәйрәме – «Гыйлемпиада» оештырылды. Коръән уку, азан әйтү, вәгазь сөйләү буенча бәйгеләр, викториналар, Сабан туенда уйнала торган уеннар, балалар арасында милли көрәш ярышлары үтте.

## Арча районы Казанка авылында яңа мәчет ачылды

Мөхәррам аеның 22 нче көнендә (20 нче августта), Арча районы Казанка авылында тантаналы рәвештә яңа мәчет үз ишекләрен ачты. Әлеге чарада Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Арча районы имам-мөхтәсибе Әмир хәзрәт Миңнемуллин, Арча районы Башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Гатиятов, район оешмалары җитәкчеләре, авыл халкы, имамнар катнашты. Казанка авылында бары 20 йорт кына булса да, мәчет авылдашлар һәм кайткан кунаклар өчен күптән көтеп алынган сөенечле вакыйга булды.

Тантанада катнашучыларны Равил хәзрәт Зөфәров Татарстан мөфтие исеменнән сәламләде, вәгазь, үгет-нәсыйхәт сүзләрен җиткерде, мәчет төзүдә зур хезмәт куючыларга рәхмәт хатлары тапшырды. Аннары өйлә намазы алдыннан тәкбирләр әйтелде, дога кылынды.

Казанка авылында мәчет моннан 20 ел элек төзелә башлаган иде һәм ул тулысынча быел сафка басты. Яңа мәчеттә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәт алу, намаз уку, дини дәресләр һәм ифтарлар үткәрү өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган, ул бер катлы, подвалы бар. Гомуми мәйданы – 88,5 квадрат метр. Мәчеткә ремонт ясалганда ук биредә барлык намазлар да укылды. Мәчет янына янкорма төзелде: анда котельная һәм ике тәһарәтханә урын алды. Цоколь катында дин нигезләре буенча дәресләр, ифтарлар һәм башка чаралар үткәрү мөмкинлеге тудырылды.

## Нәзарәттә Морат Рәмзинең мәшһүр тәфсире хәзерге татар әдәби теленә күчерелә

Диния Нәзарәтендә абруйлы татар дин галиме, мәгърифәтче Морат Рәмзинең бөек хезмәте – Коръән тәфсире иске татар теленнән хәзерге татар әдәби теленә күчерелә башлады. Күләме 700 биттән артып киткән әлеге

хезмәтне 1927-30 елларда Морат Рәмзи Кытайның Чугучак шәһәрендә яшәгән вакытында язган.

Кулдан иске имлә белән язылган текстны хәзерге татар теленә кириллицага күчерү эшен Нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлеге белгече Нурислам хәзрәт Вәлиулла башкара. Иң башта хезмәт оригинал телендә иске татар язуыннан кирилл шрифтына күчерелә, аннан соң әзер текстны хәзерге татар теленә авыштыру эше алып барылачак. Мәшһүр тәфсирне тәрҗемә итү татар дини мирасын һәм татар теленең үзенчәлекләрен, татар халкының Коръәнне тәрҗемә итү традицияләрен бөек ядкәр мисалында яңа яктан өйрәнергә мөмкинлек бирәчәк.

## Татарстан мөфтиятендә 100 дән артык укучыга букчалар һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырылды

Мөхәррам аеның 28 нче көнендә (26 августта), Белем көне алдыннан Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин аз керемле һәм күп балалы гаиләләрдән булган мәктәп укучылары белән очрашты. Мөфти аларга портфельләр һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырды. Очрашу Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» республика акциясе кысаларында узды. Быел бөтен республикадан 100 укучы Белем көненә бүләкле булды. Мәктәп букчасына, гадәттәгечә, канцтоварлар, дәфтәрләр, хезмәт дәресләре, рәсем сәнгате өчен җыелмалар һ.б. салынган.

## Мөфти Казан Глобаль яшьләр саммитында 1100 еллык мирасы турында сөйләде

Сафәр аеның 1 нче көнендә (28 августта), Казан Ратушасында Казан Глобаль яшьләр саммитының «Мәдәниятара диалог һәм яшьләр өчен

мөмкинлекләр тигезлеге» дип исемләнгән панель сессиясе узды. Сессия эшен мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Коръән укып ачып җибәрде һәм башкалабызга килгән чит ил кунакларын сәламләде. сессиядә татар халкының рухи мирасы темасын күтәрде һәм саммит кунакларын Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы кысаларында тормышка ашырыла торган төп проектлар белән таныштырды.

Казан Глобаль яшьләр саммиты 27-30 август көннәрендә узды. Анда Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең яшьләр эшләре һәм спорт министрлары, Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчеләре, генераль консуллары, яшьләр оешмалары лидерлары, яшьләр сәясәте белән шөгыльләнүче халыкара оешмалар вәкилләре, яшь эшмәкәрләр һәм фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре һ.б. – барлыгы 60тан артык илдән килгән кунаклар катнашты. Саммит яшьләр миграциясе, эшкуарлык, иминлек һәм яшьләрнең менталь сәламәтлеге, яшьләрнең санлы технологияләрне куллану тенденцияләре, социаль лифтлар һәм бертигез мөмкинлекләр тудыру кебек 5 төп теманы күтәрде.

## Нәзарәтнең Голәмәләр шурасы «Ак Барс» банкы белән берлектә «Мөселманнар өчен банк карталары» проектын эшләде

Нәзарәтнең Голәмәләр шурасы «Ак Барс» банкы белән берлектә «Мөселманнар өчен банк карталары» проектын эшләде һәм раслады. Шәригать нормаларына туры килгән дебет картасы эчтәлеге буенча – банкның стандарт карталы продуктларына якын. Ислам нормалары нигезендә, картаның шактый өстенлекләре бар: счеттагы акчага процентлар исәпләнми; клиентларның акчалары аерым счетларда саклана; әлеге счетлардагы акчалар шәригать тарафыннан тыелган эшчәнлекне финанслауга файдаланылмый. Карталар казино һәм теләсә нинди уен һәм лотерея бизнесы хезмәтләре; исерткеч һәм тәмәке сатучы махсус кибетләрдә

товар алу өчен каралмаган, шул ук вакытта әлеге чикләүләр продукция сатучы универсаль кибетләргә кагылмый. Бу карта белән барларда һәм төнге клубларда түләп булмый, ләкин чикләүләр рестораннар һәм кафе-ларга кагылмый.

## Рөстәм Миңнеханов һәм Минтимер Шәймиев «Мөхәммәдиянең» яңа тулай торагын һәм бинасын күреп китте

Сафәр аеның 3 нче көнендә (30 августта), Татарстанда Республика көне билгеләп үтелгәндә, Диния Нәзарәте резиденциясенә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев килеп китте. Алар белән бергә РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры Ирек Фәйзуллин, Казан мэры Илсур Метшин һәм ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров та бар иде. Мәртәбәле кунакларны Татарстан мөфтие, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директоры Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин һәм Ришат хәзрәт Хәмидуллин, шулай ук мәдрәсә директоры урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм Зөлфәт хәзрәт Габдуллин каршылады.

Нәзарәткә килү сәбәбе булып «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең яңа биналары — административ корпусын һәм тулай торагын төзү эшләре тәмамлану торды. Биналар «ТР мөселманнарының Диния Нәзарәте резиденциясе» бердәм территориаль комплексын булдыру проекты кысаларында төзелде. Эшләр 2021 елның май аенда башланган иде һәм быел мәдрәсәнең 140-еллыгы уңаеннан Республика көне һәм яңа уку елы башлануга тәмамланды. Җитәкчеләр яңа биналар белән танышып чыкты, башкарылган эшләрне уңай бәяләде һәм мәдрәсәгә эшчәнлекне алып баруда уңышлар теләде.

## Әлмәт шәһәрендә яңа мәчет ачылды

Сафәр аеның 4 нче көнендә (31 августта), Әлмәт шәһәренең Агропоселок бистәсендә тантаналы рәвештә «Нурлы» мәчете ачылды. Чараны Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәрев ачып җибәрде.  Ул, әлмәтлеләрне мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләп, Аллаһы Тәгалә йортлары – мәчетләрнең җәмгыятьтәге әһәмиятенә тукталды. 270 кв.метрлы ике катлы мәчет 100 кешегә исәпләнгән. Цоколь өлеше дә булган бинада ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен 3 тәһарәтханә, дини дәресләр өчен уку сыйныфлары, фарз заллар, никах уку һәм исем кушу өчен бүлмәләр, имам бүлмәсе бар. Мәчеттә Рамазан аенда ифтарлар уза, газы, суы кергән, электр энергиясе белән тәэмин ителгән, канализация системасы ясалган.

## Татарстан мөфтие мөселман яшьләре һәм волонтерлары белән очрашты

Сафәр аеның 7 нче көнендә (3 сентябрьдә), Казанда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөселман яшьләре һәм волонтерлары белән очрашты. Чарага Диния Нәзарәтенең күпсанлы социаль башлангычларында катнашучылар, Татарстанның төрле почмакларыннан егетләр һәм кызлар , мәдрәсә шәкертләре, яшь белгечләр җыелды.  Очрашу Камил хәзрәтнең яшьлек турындагы вәгазеннән башланды, «Голүмүл Коръән» («Коръән турында фән») темасы буенча лекция белән дәвам итте һәм «сорау-җавап» белән тәмамланды. «Иң бөек проектлар яшь чакта башкарыла яки башланып җибәрелә!» — диде Камил хәзрәт һәм яшьлекнең Аллаһы Тәгаләдән саваплар җыю өчен иң уңай һәм бәрәкәтле чор икәнен билгеләп үтте. Мөфти белән очрашудан соң егетләр һәм кызлар, волонтерлар оешкан төстә ямьле табигать почмагына традицион квестка җыелып китте.

## Казанда хәдисләр буенча ачык лекцияләр «Сахих әл-Бохари» китабы буенча дәвам итте

Сафәр аеның 11 нче көнендә (7 сентябрьдә) Казанның тарихи «Зәңгәр» мәчетендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләренә багышланган ачык лекцияләрнең яңа циклы старт алды. 2021 елда Галимҗан Баруди төзегән сайланма хәдисләр җыентыгы буенча дәресләр курсыннан башланган лекцияләр хәзер «Сахих әл-Бохари» китабы буенча, рус теленә тәрҗемәдә, кыскартылган «Зубдат» версиясе буенча дәвам итте.«Зубдат» версиясендәге хәдисләр җыентыгы иң уңышлы кыскартылган версияләренең берсе булып тора, аны XIX гасырда яшәгән дагыстанлы мөселман галиме Гомәр Дияветдин әд-Дагыстани төзегән. Анда пәйгамбәребезнең салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 хәдисе тупланган. Хәдисләр буенча ачык лекцияләрне Казанның хәдисләр галиме, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең шәригать мәсьәләләре бүлеге белгече Нурислам хәзрәт Вәлиулла укый. Ул һәр дәрестә – 10 хәдискә аңлатма, тыңлаучыларның сорауларына җавап бирә.

## Казанда аншлаг  белән «Ибн Фадлан» фильмы премьерасы узды

Сафәр аеның 11 нче көнендә (7 сентябрьдә) Казанда яңа «Синема 5» кинотеатрында «Ибн Фадлан» фильмы премьерасы узды. Картина XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең ачышы буларак игълан ителде. Премьераны карарга теләүчеләр бик күп булу сәбәпле, «Ибн Фадлан» фильмы тагын бер залда күрсәтелде. «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмы «Россия – ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме заказы буенча Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифе фонды ярдәме белән Диния Нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан төшерелде. Фильмны караганнан соң, «Синема 5» кинотеатрында

фильмны төшерүчеләр белән иҗади очрашу булды. Татарстан мөфтие урынбасары, Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, фильмның генераль продюсеры, кинокартинаның документаль өлеше буенча режиссер Айназ Мөхәммәтҗанов, нәфис постановкалар буенча режиссер Рәмис Нәҗмиев һәм баш рольне башкаручы, Тинчурин театры актеры Зөлфәт Закиров тарихи фильм төшерүнең үзенчәлекләре турында сөйләде. Эксперт буларак, ТР Кинематографистлар берлеге рәисе, күпсанлы кинофильмнар режиссеры Илдар Ягъфәров та үзенең югары бәясен бирде. Халык соравы буенча, 10 сентябрьдә фильм «Синема 5» кинотеатрында тагын өч залда күрсәтелде. Фильмны тамаша кылырга теләүчеләр шулкадәр күп иде, заллар шыгрым тулы булды. XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестивале нәтиҗәләре буенча картина «Вакыйганың тарихи әһәмиятен гәүдәләндергән өчен» дипломына лаек булды.

## Казанда XI Якупов укулары узды

Бүген, сафәр аеның 12 нче көнендә (8 сентябрьдә), Россия ислам институтында «XI Якупов укулары» узды. Укулар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 140-еллыгы, Идел буе Болгар дәүләтендә Исламны кабул итүнең 1100-еллыгы кысаларында Татарстан мөфтияте, Россия ислам институты, Казан ислам университеты һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тарафыннан оештырылды. Конференция ел саен танылган татар мәгърифәтчесе, галим һәм дин эшлеклесе, Вәлиулла хәзрәт Якуповның (1963-2012) бай рухи-дини һәм интеллектуаль мирасының асылына төшенү максатыннан үткәрелә. Конференцияне читтән торып РИИның YouTube-тагы рәсми аккаунтында да карарга мөмкин иде. Якупов укуларында Татарстан мөфтие, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директоры Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады. Ул, Вәлиулла Якуповның «Мөхәммәдия»не халыкка кайтарып яңадан эшләтеп җибәрүгә күп тырышлыкларын исәпкә алып, аны мәдрәсәнең икенче атасы дип атады. «Мөхәммәдиянең» соңгы бер

ел эчендә күп уңай үзгәрешләр кичерүен дә искә алды, шунда ук татар дини зыялыларын тәрбияләүдә төп шартның яңа биналар һәм техник мөмкинлекләрдә түгеллеген, иң беренче чиратта мәдрәсәнең гыйльми эчтәлеге мөһим булуын искәртте. Чарада «Таян Аллаһка» бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы да булды. «Таян Аллаһка» бөтенроссия әдәби бәйгесенә 2010 елда Вәлиулла Якупов тарафыннан нигез салынган иде. Бәйгене Татарстан мөфтияте Россия ислам институты һәм «Идел» журналы белән берлектә татарлар арасында талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатыннан үткәрә. Конкурсның быелгы өстенлекле темасы Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы булды һәм өч номинациядә үтте: шигърият, чәчмә әсәр һәм публицистика.

## РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 1 курс шәкертләренә бушлай дәреслекләр бирде

Сафәр аеның 13 нче көнендә (9 сентябрьдә), Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе җитәкчелеге шәкертләр белән очрашты. Очрашуда Татарстан мөфтие, мәдрәсә директоры Камил хәзрәт Сәмигуллин, РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов, ассоциациянең башкарма директоры Рөстәм Вәлиев, мәдрәсә директоры урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм Зөлфәт хәзрәт Габдуллин, Диния нәзарәтенең фән һәм мәгариф бүлеге башлыгы Гаяз Әхмәтшин, шулай ук Киров өлкәсе мөфтие Зөфәр хәзрәт Галиуллин катнашты.

Очрашуга җыелуның төп сәбәбе – Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укучы 1 курс шәкертләренә РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең Хәйрия фонды матди ярдәменә сатып алынган дәреслекләрен тапшыру иде. РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциаци-

ясе биргән сәдака хисабына 100 шәкерт өчен 5 төрле китаптан торган дәреслекләр комплектлары бастырылды. Әлеге дәреслекләр гарәп телен өйрәнү буенча уку әсбапларыннан гыйбарәт. Комплектта нәһү, сарыф, китәбә (язу), кыйраә (уку), тәгъбир (диалог) предметларыннан китаплар урын алган. «Мөхәммәдия» шәкертләрен дәреслекләр белән тәэмин итү мөселман эшмәкәрләре өчен күркәм гадәткә әйләнде: былтыр да алар 1 курста укучы 70 шәкерт өчен китаплар һәм кабинетларга урнаштыру өчен җиһазлар да сатып алган иде.

## Татарстанда гошер җыю кампаниясе башланды

Татарстан Республикасында Диния Нәзарәте башлангычы белән гадәттәгечә гошер сәдакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе старт алды. Шуңа бәйле рәвештә, мөфтият 2022 елның 24 сентябрен Татарстанда Гошер көне дип игълан итте.

Гошер көне Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә. Һәр елдагыча, мөхтәсибәтләрдәге мәчетләр гошер сәдакасы итеп җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул итә. Казанда гошерне Нәзарәт карамагындагы «Зәкят» хәйрия фонды кабул итә һәм аз керемле, мохтаҗ кешеләргә тарата.

Татарстанда традицион рәвештә гошер сәдакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе вакытында 2017 елда – 160 тонна, 2018 елда – 600 тонна, 2019 елда – 1109,5, 2020 елда – 1000 тоннага якын, 2021 елда 577,33 тонна гошер сәдакалары җыеп таратылды.

# Тарих

# Харбин шәһәрендә Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы билгеләп үтелгән

## Болгарларның Ислам динен кабул итүләре хөрмәтенә Кытайда ачылган мәчет



*Харбин мәчетендәге беренче җомга намазы. 1937 елның 8 нче октябре Фото Ерак Шәрыкта чыккан «Милли Байрак» гәҗитеннән алынды*

Быел Рәсәй мөселманнары зур вакыйга билгеләп үтә: моннан 1100 ел элек Идел болгарлары – бүгенге заман татарларының ата-бабалары Ислам динен үз дәүләтләренең рәсми дине итеп таныган. Шушы вакыйгадан файдаланып, Кытайда болгарларның Ислам динен кабул итүе хөрмәтенә төзелгән борынгы мәчет хакында сөйләп үтик.

1922 елда болгар бабаларыбыз Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгын билгеләп үткәндә, кызганычка, атеистик большевистлык режимы сәбәпле, Рәсәйдә бу зур датаны тиешенчә уздыру мөмкин түгел иде. Шуңа күрә 1922 елда Ерак Көнчыгыштагы татар иммиграциясенең үзәге булган Харбин шәһәре бу чараны уздыруны үз өстенә алган.

1922 елда татарлар монда онытылмаслык зур бәйрәм ясаган, шулай ук махсус юбилей альбомы чыгарганнар. Катнашучылар тарафыннан истәлекле дата хөрмәтенә Харбинда бөтен Ерак Көнчыгышның асылташы булачак мәчет төзү карары кабул ителгән.

Ул вакытта татарларның Харбинда мәчетләре булса да, ул зур булмаган. Яңа мәчет шәһәрнең бизәге булыр һәм шулай ук «Болгарларның Ислам динен кабул итүенә 1000 ел» исемен алыр дип көтелгән. Әмма, әлбәттә, мондый зур төзү эшләре шактый чыгымнар таләп иткән. Харбинның татар җәмәгатьчелегендә андый акчалар булмаган. Моннан тыш, Рәсәйдәге революция, ә аның артыннан башланган Гражданнар сугышы сәбәпле, күп гаиләләрнең матди ягы какшаган.

Әмма моңа карамастан, халык мәчет төзү һәм бу истәлекле вакыйганы тарихка кертеп калдыру карарын кабул иткән. 1923 елда төзелеш эшләре башланган. Матди ярдәмне Харбин һәм Маньчжуриянең калган шәһәрләреннән булган татарлар гына түгел, ә Япония һәм Корея татар диаспорасы вәкилләре дә күрсәткән.

1923 елда Артиллерия урамында (хәзерге Тунцзянцзе урамы), иске мәчет урынында (беренче агач мәчет татарлар тарафыннан 1901–1906 елларда төзелгән була) таш мәчет төзелә башлый. 1924 елда мәчетнең төп эшләре тәмамлана һәм 1924 елның 27 нче июлендә манарага тантаналы рәвештә ярымай урнаштырыла. Әмма 1926 елда Харбин шәһәренең төзүне үз кул астына алган имамы – Гыйниятулла Салихмәт (Салихмәтов) вафат була. Күп еллар дәвамында ул Харбинның гына түгел, ә бөтен Ерак Көнчыгыш татар җәмәгатьчелегенең рухи лидеры булып тора.

Аның үлеменнән соң төзелеш эшләре акрыная, мәчет җыелган садака акчалары белән генә төзелә башлый. Төзелешкә шулай ук Кытайның 1929 елда СССР белән, ә 1931 елда Япония белән булган хәрби конфликтлары комачау итә. Моның өстенә 1932 елда Харбинда зур су басу була. Татарларның барысы да диярлек Сунгари елгасы янында




*Мәчет бинасындагы язу тактасы*
*Чыганак: google.com*

яшәгәнлектән, бөтен нәрсә, шул исәптән төзелә торган мәчет тә зыян күрә.

Ерак Көнчыгыш татарлары килеп туган авырлыкларга карамастан, төзү эшләрен төгәлләргә карар кылган. Харбинның яңа имамы Мөнир хәзрәт Хәсибулла өстәмә акчалар туплау өчен, Ерак Көнчыгышның (Кытай, Япония һәм Корея) барлык татар диаспораларын йөреп чыга.

Нәтиҗәдә, барысы да төзелеш эшләре тәмамлануын теләгәнгә күрә, зур суммада акча җыела. Һәм 1937 елда төзү эшләре яңадан башлап җибәрелә. 1937 елның 8 нче октябрендә мәчет тантаналы рәвештә ачыла һәм анда беренче җомга намазы уздырыла.

Бу мәчет ике катлы була. Беренче каты ирләр өчен, икенчесе хатын-кызлар өчен каралган. Мәчетне төзегәндә татарлар Болгар архитектура стиленең үзенчәлекләрен исәпкә алырга тырышкан. Мәчетнең эче матур минбәр һәм купшы келәмнәр белән игътибарны җәлеп иткән. Рамазан ае вакытында ярымай неон уты белән яктыртылган.

Мәчет шәһәрнең барлык почмакларыннан күренгән һәм Ерак Көнчыгышта татарларның горурлыгы булып торган. Бу мәчет Болгарда

Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы хөрмәтенә төзелгәнгә күрә, халыкта аны «меңъеллык мәчете» дип атый башлаганнар.



*Харбин мәчете*
*Чыганак: google.com*

1945 елның 20 нче августында Совет гаскәрләре Харбинны ала. Бу татар диаспорасы әгъзаларының репрессиягә эләгүләренә китерә. Җәмәгать һәм мәчет төзелеше эшчәнлеге белән бәйле булган күп документлар юкка чыгарыла.

1945 елның апрель аенда Кытайның халык-азатлык армиясе гаскәрләре шәһәрне ала. 1953 елда мәчет бинасы хакимият тарафыннан Кытай халык армиясенә бушлай тапшырыла. Бу вакытта Харбин шәһәре татар диаспорасының исән-имин калган өлеше Төркиягә һәм Америка Кушма Штатларына күченеп киткән була. Соңрак диаспора дәвамчыларының әгъзалары, мәчетне җирле мөселманнарга кайтарып бирүләрен сорап, вакыт-вакыт Кытай хакимиятенә мөрәҗәгать итә.

Хәзер мәчет бинасы төзекләндерү эшләренә мохтаҗ. 2018 елда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Кытайда булды. Башкаласы Харбин булган Хэйлунцзян провинциясе делегатлары белән очрашу вакытында ул аның губернаторы Ван Вэньтаога борынгы мәчетне төзекләндерү эшләрендә ярдәм итү һәм төзүчеләр хакында мәгълүмат язылган мемориаль такта урнаштыру үтенече белән мөрәҗәгать итте.

Хәзерге вакытта мәчет бинасының алгы ягына бу мәчетнең төрек мәчете икәнен белдергән язу тактасы эленгән, гәрчә ул мәчет нәкъ менә татарлар тарафыннан төзелсә дә.

# Гарәп географлары һәм сәяхәтчеләре Болгар хакында

*Кызганычка, Болгар җирләре һәм дәүләте хакында безгә аз мәгълүмат килеп ирешкән. Болгар дәүләте хакында иң тәфсилле тасвирлама калдыручы кеше – ул Ибне Фадлан – Багдад хәлифе Әл-Мөкътәдирнең сәркатибе, аның тарафыннан Болгар җирләренә җибәрелгән илче.*



*Чыганак: shutterstock.com*

Бу илчелек Болгарга 922 елда килә. Һәм нәкъ менә әлеге ел болгарларның Ислам динен рәсми рәвештә кабул итү елы дип санала. Ибне Фадланның язулары буенча, болгарларның бер өлеше инде бу вакытта Ислам динендә булган.

X гасырда яшәгән гарәп географы һәм сәяхәтчесе Ибне ХәукальӘн-Нәсиби болай дип билгеләп үткән: «Болгар күп биләмәләре булмаган кечкенә шәһәр. Ул көймәләр туктый торган урын булганга күрә дә танылган иде… әмма ул талауларга дучар булган».

Болгар дәүләтенең көчсезләнүе бу җирләргә рус походларының килүе белән бәйле була. Ә менә Зәкәрия бине Мөхәммәд Әл-Казвини (1283 елда вафат була) сүзләренчә, бер яктан, Болгар шәһәре зур дәүләтнең башкаласы булган, ә икенче яктан – әһәмиятле сәүдә шәһәре булып хезмәт иткән.

Болгар дәүләте халкының күбесе игенчелек белән шөгыльләнгән. X гасырның гарәп галиме, географ Ибне Рөстә болай дип язган: «Болгарлар – игенчелек белән шөгыльләнүче халык, алар: бодай, арпа, тары бөртекле ашлыгыннан икмәк әзерли».

Русь кнәзьлегендә иген уңмаган елларда болгарларның аларга икмәк җибәреп, җирле халыкны ачлыктан коткарып калганы билгеле.

Гарәп чыганаклары буенча X гасырда болгарларда ярымкүчмә яшәү рәвеше өстенлек иткән. Кышкы вакытта алар өйләрдә яшәгән, ә язын һәм җәен кырларга чыгып, анда тирмәләрдә торган. Әмма бу терлек үрчетү өчен җәйге көтүлекләргә күчеп китү булмаган, ә кыр эшләре, игенчелек өчен кучену булган.

Инде XII гасырда танылган гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид Әл-Гарнәти Әл-Әндалусинең язмаларында болгарларның ярымкүчмә яшәү рәвешеннән тулысынча утрак тормышка күчүләрен күрәбез.

Утрак тормыш рәвешенә күчүдә зур рольне ислам дине уйнаган.

Ибне Рөстә: «Аларның күпчелеге ислам динен тота, һәм аларның авылларында мәэзиннәре һәм имамнары белән мәчетләр һәм башлангыч белем бирү уку йортлары бар», – дип язган.

Бу Болгарның Биләр, Сувар, Кашан, Казан, Җүкәтау, Кирмәнчек һәм башка шәһәрләренең көчле итеп үсүләренә китерә. X-XI гасырларда шәһәрләр төзелү Ислам мәдәниятының үсешенә илтә. Шул сәбәпле, утрак тормышта яшәүче татарларның дини җәмәгатьләре – мәхәлләләр формалаша башлый.

Ул вакытта төп төзү материалы агач була. Әбү Хәмид Әл-Гарнәти төзү эшләре һәм Болгар шәһәренең тышкы кыяфәте турында болай дип

язган: «Болгар тулысынча нарат агачыннан төзелгән зур шәһәр, ә шәһәр диварлары имәннән төзелгән. Диварның теге ягында төрле халыклар яшәгән…»

Болгар җирләрендәге сәүдә турында ул болай дип язган: «Кешеләр бирегә Ислам илләрендә: Зәнҗәндә, Әбһәрдә, Тәбриздә һәм Исфәһәндә эшләнгән, утка чыдам булган кылычлар алып килә. Алар өчен түләү итеп кеш тиреләре ала һәм моннан зур табышка ия була».

Болгар турында мөһим мәгълүматларны Шиһабетдин Габдулла Якут Әл-Хәмәви (1229 елда вафат була) дә һәм танылган сәяхәтче Ибне Баттута (1304–1377) да калдырган.

Исмәгыйль Әбү Әл-Фида: «Болгарда бик яхшы мунчалар бар», – дип язган. Кайбер мәгълүматларга караганда, шәһәр нык итеп үсеш алган вакытта Болгар шәһәрендә 10 меңнән артык бина булган. Шәһәр сәяхәтчеләрне үзенең байлыгы һәм алга киткән сәүдәсе белән таң калдырган.

*Дамир Гайнетдинов язмалары,*
*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Фән

# Әбү Хәнифәнең сәхабәләр белән күрешүе

*(Дәвамы. Башы журналның алдагы санында)*

Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның тормыш юлын тасвирлаган кайсы гына хезмәтне алсак та, аның кайбер сәхабәләр белән күрешүе хакында искә алына. Галимнең биографиясен өйрәнүчеләр, бигрәк тә хәнәфи галимнәре, аның сәхабәләрдән кайбер хәдисләрне тапшыруы хакында әйтә.[1]

Кешенең табигыйн булып исәпләнүе өчен, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре белән очрашып күрешүе җитә, әмма хәдисләрне тапшыру бу очракта мәҗбүри шарт булып тормый. Ибне Һаҗәр Әл-Әскаләни дә, кеше табигыйн дип саналсын өчен, нәкъ менә шушы фикер дөрес дип саный. Имам Ән-Нәвәви дә «табигыйн» сүзенә билгеләмә биргәндә, кешенең табигыйн булуы өчен, аның сәхабәләрнең берәрсе белән генә булса да очрашкан булуы кирәк, ди.[2]

Моннан тыш, кеше табигыйн булып саналсын өчен, аның хәдис тапшыруы кирәк, дигән шартны куйсак, бу Имам Мөслимнән китерелгән хәдискә каршы киләчәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Табигыйннәрнең иң яхшысы – Үвәйс исемле кеше», – дигән. Ә Үвәйс, билгеле булганча, сәхабәләр белән күрешкән генә кеше булган, әмма бернинди дә хәдис тапшырмаган.

Моннан чыгып, Әбү Хәнифә бернинди хәдис тапшырмаса да, ул табигыйн була, дип саный алабыз. Ибне Һаҗәр Әл-Әскаләни болар хакында мондый сүзләр әйтә: «Әбү Хәнифә һиҗри буенча 80 елда Куфада туып, шәһәрдә яшәүче күп сәхабәләрне күреп кала алган. Шуңа да аны табигыйн дип атарга була. Бу мәсьәләдә ул замандаш галимнәренең күбесен

1 Мөхәммәд Әбү Зәһра – «Әбү Хәнифә: Хәятуһу вә әсруһу әрауһу вә фикһуһу», «Дәруль-фикриль-гарәби», Каһирә, 1997, 59 б.

2 Ибне Һаҗәр Әл-Мәкки – «Әл-Хәйратуль-хисан», 59 б.

узып китә»[1].

Шул рәвешле Әбү Хәнифә берничә сәхабә белән күрешкән һәм алардан хәдисләр ишеткән. Бу очрашуларны хронологик тәртиптә түбәндәгечә күрсәтергә була:

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе. Сәхабәнең үлем вакыты хакында өч фараз бар: йә ул һиҗри буенча 91 нче, йә 92 нче яисә 93 нче еллар.[2] Әбү Хәнифә исә һиҗри буенча 80 нче елда туган. Хәтта Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһенең үлем вакыты итеп 91 нче елны алсак та, бу аларның очрашуларына киртә булып тормый. Шулай ук галимнәр дә бу мәсьәләдә бердәм фикердә.[3]

Габдулла бине Җүз Әз-Зәбиди радыяллаһу ганһе. Һиҗри буенча 96 нчы елны, 16 яшендә Әбү Хәнифә рахмәтуллаһи галәйһи әтисе белән бергә хаҗ кылган һәм әлеге сәхабә алып барган хәдис түгәрәгендә катнаша алган, бу вакытта сәхабә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеткәннәрне сөйләгән. Габдулла бине Җүз Әз-Зәбиди радыяллаһу ганһе һиҗри буенча 87 нче елда вафат була.

Габдулла бине Әбү Әфва радыяллаһу ганһе. Имам Әгъзәм аның белән соңгы тапкыр 7 яшендә очрашкан. Сәхабә һиҗри буенча 87 нче елны вафат булган.

Габдулла бине Үнәйс радыяллаһу ганһе. Әлеге сәхабә һиҗри буенча 94 нче елда Куфа шәһәренә килә. Бу вакытта Әбү Хәнифә рахмәтуллаһи галәйһигә 14 яшь була.[4] Имам Әгъзәм әлеге сәхабәдән хәдисләр тапшырганы хакында хәбәр иткән.[5]

1 Шунда ук, 44 б.

2 Әл-Мувәффәк бине Әхмәд Әл-Мәкки, «Мәнәкибү Әбү Хәнифә», «Дарүл-китабелгарәби» нәшрияты, Бәйрут, 1981, I, 27-29 б.

3 Җәләлетдин Әс-Суюти – «Тәбйизүс-сәхифә», «Даруль-әркәм» нәшрияты, Бәйрут, 64 б.

4 Шунда ук, 31 б.

5 Ибне Хәҗәр Әл-Мәкки – «Әл-Хайратүль-хисан», 45 б.

Василә бине Әл-Әска радыяллаһу ганһе. Һиҗри буенча 85 елда фани дөньядан киткән бу сәхабә белән очрашканда Әбү Хәнифә рахмәтуллаһи галәйһигә 5 яшь булган.[1]

Әбү Әт-Түфәйл Әмир бине Вәсилә радыяллаһу ганһе иң соңгы булып бакыйлыкка күчкән сәхабәләрнең берсе. Ул 102 нче елда Мәккә шәһәрендә үлгән.[2]

Әбү Хәнифә рахмәтуллаһи галәйһинең гыйлемгә хирыслыгы һәркем өчен мәгълүм. Хәтта актив рәвештә сәүдә эшләре белән шөгыльләнеп тә, ул дини-фәнни җыелышларга йөрүне дәвам итә. Ул, бәхәсләр һәм фикер каршылыгы чыкканда, әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать карашларын яклавы белән, күп тапкырлар ул чор галимнәренең игътибарын җәлеп итә. Шуңа да Әбү Хәнифә кебек зур галим Куфада яшәгән көе сәхабәләр белән очрашу мөмкинлеген кулдан ычкындырган дип күз алдына да китереп булмый. Димәк, Әбү Хәнифә рахмәтуллаһи галәйһи сәхабәр белән очрашып та, алардан ишеткән бер хәдисне дә тапшырмаган дип күз алдына китерергә мөмкинме?! Бу – зур галимгә карата тиешле хөрмәт хисләрен кичермәүче кешеләрнең фаразлары гына. Моның дәлиле – Имам Әгъзәмнең тормышы. Моннан тыш, Әбү Хәнифә үзе белән булган очрак хакында болай дип сөйләгән: «Һиҗри буенча 96 нчы елны, миңа 16 яшь булганда, мин әти белән хаҗ сәфәренә кузгалдым. Әл-Харам мәчетенә кергәннән соң, мин галимнәрнең зур җыелышын күреп, әтидән: «Бу кемнәрнең мәҗлесе?» – дип сорадым. Әти миңа: «Бу – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе булган Габдулла бине Җүз Әз-Зәбиди радыяллаһу ганһе исемле сәхабәнең түгәрәге», – диде. Моннан соң мин нәкъ аның янына юнәлдем һәм аның Пәйгамбәребездән ишеткән мондый хәдисне тапшыруын ишеттем: «Берәү үзен Аллаһы Тәгаләнең диненә

---

1 Әл-Мувәффәк бине Әхмәд Әл-Мәкки, «Мәнәкибү Әбү Хәнифә», «Дарүл-китабел-гарәби» нәшрияты, Бәйрут, 1981, I, 31 б.

2 Ибне Хәҗәр Әл-Мәкки – «Әл-Хайратүль-хисан», 47 б.

багышласа, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә аны шиктән коткарыр һәм үзе дә көтмәгән җирдән ризык бирер»[1].

Кайбер галимнәр Әбү Хәнифә рахмәтуллаһи галәйһинең Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе белән очрашкан булуын таный, әмма аннан хәдисләр тапшыруын кире кага. Галимнәрнең бер төркеме аның кайбер сәхабәләрне исән вакытларында күрә алуын кабул итсә дә, галимнең алар белән күреп очрашуын һәм алардан хәдисләр тапшыруын кире кага. Галимнәрнең икенче төркеме Имам Әгъзәмнең хәдисләр тапшыруына кагылышлы булуын кире кагып: «Фәлән-фәлән галимнәр Әбү Хәнифәнең нинди дә булса сәхабә белән очрашуын хәбәр итмәгән», – дип әйтә. Мондый каршы фикернең булуы дөрес түгел, чөнки алар дәлил булмауга нигезләнеп фикер йөртә. Әл-Кардари бу хакта болай дигән: «Кайбер мөхәддисләр Әбү Хәнифәнең сәхабәләр белән очрашкан булуын инкарь итә, әмма аның укучылары, дөреслеккә туры килгән чылбыр буенча, моның киресен раслый. Чынлыкта ничек булуы Әбү Хәнифә рахмәтуллаһи галәйһинең укучыларына яхшырак мәгълүм. Моннан чыгып, Имам Әгъзәмнең сәхабәләр белән очрашып, алардан хәдисләр тапшырган дип санаучыларның карашы ул фикерне кире кагучыларныкыннан көчлерәк»[2].

Әбү Хәнифә – сәхабәләр чорыннан соң Ислам дөньясының иң зур мөҗтәһиде һәм табигыйн. Табигыйн буларак, ул Коръәни Кәримдә искә алган кешеләр исәбенә керә:

وَالسَّابِقُونَ الْأَوَّلُونَ مِنَ الْمُهَاجِرِينَ وَالْأَنصَارِ وَالَّذِينَ اتَّبَعُوهُم بِإِحْسَانٍ
رَّضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ

---

[1] Әл-Мувәффәк бине Әхмәд Әл-Мәкки, «Мәнәкибү Әбү Хәнифә», «Дарул-китабел-гарәби» нәшрияты, Бәйрут, 1981, I, 31 б.; Ибне Хәҗәр Әл-Мәкки – «Әл-Хайратүль-хисан», 45 б.

[2] Хафизетдин бине Мөхәммәд Әл-Кардари, «Мәнәкибү Әбү Хәнифә», «Дарул-китабел-гарәби» нәшрияты, Бәйрут, 1981, I, 28 б.

**«Мөһаҗирләр белән әнсардан [ике кыйблага юнәлеп намаз уку фазыйләтенә ирешүдә, Гәкабә бәйгатьләре, Бәдер һәм Бәйгать әр-Ридван кебек мөһим вакыйгаларда катнашуда] алга чыккан әүвәлгеләр һәм аларга [иман, итагать һәм уңай сыйфатларга ия булу кебек] игелекләрдә иярүчеләрдән Аллаһы разый булды [гамәлләрен-гыйбадәтләрен кабул итте], алар да Аңардан [алган әҗерләргә] разый булды».**

«Әт-Тәүбә», 9:100

*Ихсан Шеноджакның «Абу Ханифа – великий муджтахид» китабыннан тәрҗемә*

# Тәрбия

# Әдәпләр

## Ай тотылганда нишләргә?

– Курку халәтендә булырга

– Кайгыру һәм елар дәрәҗәдә булырга

– Тәүбә итәргә

– Игътибарлы булырга һәм намазга ашыгырга

## Яңгыр сорау догасын кылу әдәпләре

– Ураза тотарга һәм кылган гөнаһлар өчен тәүбә итәргә

– Үпкәләтергә мөмкин булган кешеләрдән гафу сорарга

– Бөтен игътибарны догага юнәлтергә

– Дога кылыр алдыннан госел коенырга

– Бер дә сөйләшмәскә

– Яңгыр тоткарлануның сәбәбе булган гөнаһны ачыкларга

– Шул гөнаһлар өчен тәүбә итәргә

– Ул гөнаһларны башка кылмауда ныклы карарга килергә

– Сөйләшмичә хотбә тыңларга

– Тәкбирләр арасында «сөбеханәллаһ» дип әйтергә

– Еш кичерү сорарга

## Авыру кешенең әдәпләре

– Үлем хакында онытмаска

– Тәүбә итеп, үлемгә әзерләнергә

– Аллаһы Тәгаләне берөзлексез мактарга

– Дога кылып ялварырга

– Аллаһы Тәгалә каршында үзеңнең зәгыйфьлегең һәм мохтаҗлыгыңны белдерергә

– Шифа бирүче Аллаһы Тәгаләгә дога кылу белән беррәттән, дәвалану ысулларын да кулланырга

– Савыга башлавыңны хис итә башлау белән, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәргә

– Үз хәлеңнән зарланмаска

– Зиярәт кылучыларны кунак итәргә

– Зиярәт кылучыларга кул сузмаска

## Мәетнең якыннарын зиярәт кылу әдәбе

– Тыйнак булырга

– Кайгыларын уртаклашырга

– Аз сөйләшергә

– Бар көчең белән елмаймаска тырышырга, юкса, мәетнең якыннарында аңа карата нәфрәт уяныргa мөмкин

## Мәетне җирләү белән идарә итү әдәпләре

– Хөрмәт белдерергә

– Башыңны түбән иеп, аска карарга (янга карамаска)

– Сөйләшмәскә

– Мәет хакында уйланырга, аның аяныч кайгылы хәлен күреп, нәтиҗәләр чыгарырга

– Бирелгән сорауларга[1] мәетнең ничек җавап бирүе хакында уйланырга

– Сорау алынудан куркып, җавапка тартылачак гамәлләрне кылу яки кылмау хакында катгый карарга килергә

– Әҗәле кинәт җитәр дә: «Их, шулай эшләгән булсам икән», – дип акланасы булачагын күз алдына китереп борчылырга

---

1 Ягъни, кабердә бирелә торган сорауларга.

## Садака бирү әдәбе

– Фәкыйрь-мескен үзе ярдәм сорап килгәнче, үзең аны эзләп табып, аңа садака бирергә

– Садака биргәнеңне башкаларга белдермәскә

– Садака биргәнең хакында беркемгә дә сөйләмәскә

– Ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән кешегә яхшы мөнәсәбәттә булырга

– Саран булмаска

– Фәкыйрь кешегә сораганын бирергә кирәк, яисә йомшак итеп кире кагарга

– Әгәр шәйтан ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән кешенең садака кабул итәргә хакы юклыгы, аның матди хәле болай да яхшы булуы хакында вәсвәсә кылса, Аллаһы Тәгалә аңа насыйп иткән нигъмәтләрне аннан кире тартып алырга ярамый, чөнки фәкыйрь кеше ул нигъмәтләрне хакы булганга алган

## Ярдәм сорап мөрәҗәгать итү әдәпләре

– Мохтаҗ булсаң гына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә кирәк

– Хаҗәтләреңне ягымлы рәвештә җиткерү тиешле

– Бик аз бирсәләр дә, ярдәм бирүчегә рәхмәт белдерергә кирәк

– Ярдәм иткән кеше өчен ихластан дога кылырга

– Әгәр ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән кеше, ярдәм итә алмыйм, дисә, аның аңлатмасын кабул итәргә һәм кайтып китәргә кирәк

– Киреләнеп, бер үк ишеккә кабат-кабат кагырга ярамый

## Бай кешенең әдәпләре

– Һәрчак тыйнак булырга

– Масаймаска һәм тәкәбберләнмәскә

– Һәрдаим шөкер итүчеләрдән булырга

– Үз байлыгыңны хәерле гамәлләр өчен кулланырга

– Фәкыйрьләрне елмаеп каршы алырга һәм аларга үз вакытыңны кызганмаска

– Барлык кешеләргә дә сәлам кайтарырга

– Сүз һәм гамәлләрең белән үз хәлеңнән риза һәм канәгать булуыңны күрсәтергә

– Яхшы һәм күркәм сүзләр сөйләргә

– Кешеләр белән күркәм мөгамәләдә булырга

– Хәлеңнән килгәнчә хәерле гамәлләрдә ярдәм күрсәтергә

## Фәкыйрь бәндәнең әдәпләре

– Булганы белән һәрчак канәгать булырга

– Бөтен кешегә дә үз хаҗәтләрең һәм мәшәкатьләрең хакында сөйләп йөрмәскә

– Чиста-пөхтә киенергә

– Комсыз булмаска

– Башкалардан ярдәм сорамас өчен, кулыңнан килгәнне эшләргә

– Тәкъва һәм хөрмәткә лаек кешеләр алдында үз хаҗәт һәм мәшәкатьләреңне үзең хәл итә алуыңны белдерергә

– Бай кешеләрне елмаеп-сөенеп каршы алмаска, шул ук вакытта аларга хөрмәт күрсәтергә

– Байларга өмет багламаска, киресенчә, тормыш итәргә малың җитәрлек булган рәвешне күрсәтергә

– Бай кешеләр алдында масаймаска, шул ук вакытта түбәнсенмәскә

– Бай кешене очратканда аннан нәрсә дә булса сорау теләгеннән йөрәгеңне тыярга

– Байларны очратып, дингә җиңел карамаска

## Бүләк бирү әдәпләре

– Бүләк бирелә торган кешене лаеклы күрергә

– Бүләкне кабул итүләрен күреп, шатлыгыңны белдерергә

– Бүләк алган кешене күреп, кабул итүе өчен рәхмәтеңне белдерергә

– Бүләкләреңнең күп һәм кыйммәтле булуына да карамастан, биргәнеңне азсынуыңны һәм әллә ни кыйммәткә ия түгеллеген белдерергә

## Бүләкне кабул итү әдәпләре

– Бүләк әллә ни кыйммәткә ия булмаса да, шатлыгыңны белдерергә

– Бүләк бирүче янәшәңдә булмаса , аның өчен хәер-дога кылырга

– Бүләк җибәргән кеше килгәч, аны елмаеп каршы алырга

– Мөмкинлек булса, бүләк бирүчегә дә бүләк белән җавап кайтарырга

– Бүләк җибәргән кеше хакында күркәм сүзләр әйтергә, мактарга

– Үзе барында ялагайланмаска

– Бүләк аркасында дини кыйммәтләреңә карата мөнәсәбәтеңне үзгәртмәскә

– Бүләк бирүчедән башка берни өмет итмәскә

## Изге гамәл кылучының әдәпләре

– Хәерле гамәлне кеше мөрәҗәгать итеп сорагачны эшләп куярга

– Биргән вәгъдәңне үтәргә ашыгырга

– Күбрәк бирергә тырышырга

– Хәерле гамәлең хакында беркемгә дә сөйләмәскә

– Күрсәткән ярдәмең һәм яхшылыгың белән кешене шелтәләмәскә

– Хәерле гамәл кылуны гадәткә кертергә

– Хәерле гамәл кылырга туктаудан сак булырга

*Имам Әбү Хәмид Мөхәммәд Әл-Газалиның «Әдәпләр» китабыннан*

# Тәфсир

# Сөләйман галәйһиссәлам кыйссасы

*Сөләйман галәйһиссәлам Давыд галәйһиссәламнең улы була. Исраил улларының бу бөек пәйгамбәре Аллаһы Тәгалә тарафыннан сайлап алынган һәм Аның күпләгән рәхмәтләре – хикмәт, гаделлек, байлык һәм тиңсез хакимлек белән бүләкләнгән.*

Сөләйман галәйһиссәлам җирдәге барлык җан ияләренең телләрен һәм башкаларның аңнарына сыймаган бик күп серләрне белгән. Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән белемнәрне һәм сәләтләрне ул кешеләрнең яшәешләрен яхшырту һәм аларны хак дин юлына чакыру өчен файдаланган. Сөләйманның хак патшалыгы турында дан-шөһрәт бар дөньяга таралган була.

## Сөләйман галәйһиссәлам тарафыннан чыгарылган карар

Бервакыт Сөләйманның әтисенә – патша һәм пәйгамбәр Давыд галәйһиссәламгә, килеп туган бәхәсләрендә гадел карар чыгару үтенече белән, ике кеше килгән. Берсенең сарыклары икенче бер кардәшенең йөзем бакчасына кереп, бер сабагын да калдырмыйча барлык чәчүлекләрне ашап бетергән. Давыд галәйһиссәлам аларга түбәндәге карар чыгаруы турында хәбәр биргән:

– Һәлак булган үсентеләр хисабына барлык сарыклар да бакча хуҗасына бирелергә тиеш.

Давыд галәйһиссәламнән чыккач, әлеге ике кеше Сөләйман галәйһиссәламне очратканнар һәм аңа барысын да сөйләп биргәннәр. Әмма, аларны тыңлап, Сөләйман галәйһиссәлам болай дип җавап биргән:

– Әгәр мин сезнең мәсьәләне караган булсам, башка карар кабул иткән булыр идем.

Сөләйман галәйһиссәламнең сүзләре кичекмәстән Давыд галәйһиссәламгә билгеле булган. Ул үзенә улын чакыртып алган һәм ике кешенең бәхәсе буенча аның фикерен сораган. Сөләйман галәйһиссәлам болай дип җавап биргән:

– Сарыклар беркадәр вакытка бакча хуҗасына бирелергә тиеш. Ул чагында дөньяга килгән бәрәннәр, шулай ук сөт һәм йон аныкы булачак. Ә юкка чыгарылган бакча сарык хуҗасына бирелергә тиеш. Бакча элеккеге халәтенә килеп, җимеш бирә башлагач, ул хуҗасына кайтарылып бирелсен. Минем карашка, бу иң дөрес карар.

Улын тыңлаганнан соң Давыд галәйһиссәлам аның белән килешкән һәм моны иң дөрес, гадел карар дип таныган.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَفَهَّمْنَاهَا سُلَيْمَانَ ۚ وَكُلًّا آتَيْنَا حُكْمًا وَعِلْمًا ۚ وَسَخَّرْنَا مَعَ دَاوُودَ الْجِبَالَ يُسَبِّحْنَ وَالطَّيْرَ ۚ وَكُنَّا فَاعِلِينَ ﴿٧٩﴾

**«Без аны Сөләйман [галәйһиссәламгә] аңлаткан идек. Һәрберенә дә хөкем [пәйгамбәрлек] һәм гыйлем биргән идек. [Тәсбих белән мәшгуль булган вакытта] Давыд [галәйһиссәлам] белән бергә тауларны һәм кошларны әмергә буйсындырдык ки, алар [үз телләре белән Безне мактап] тәсбих әйтәләр иде. [Моның кебек эшләр сезгә бик кызык булса да] Без [бөек пәйгамбәрләргә моның кебек могҗизаларны бирү эшен] кылучылар булдык».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:79

## Бала кемнеке?

Ике хатын-кыз яшәгән. Һәм аларның һәрберсенең дә бер яшьләр тирәсендәге балалары булган. Бервакыт алар сабыйларын ияртеп, һава су-

лап йөреп кайтырга чыгалар. Әмма яшь әниләр игътибарсызлык күрсәтә: бүре бер баланы эләктереп алып китә, һәм хатын-кызлар аны коткару өчен берни дә эшли алмый.

Бу ике хатын-кыз арасында исән калган балага бәйле бәхәс килеп чыккан. Аларның берсе: «Бүре синең балаңны алып китте, ә бу минем бала», – дип әйткән. Икенчесе: «Юк, бу минем бала, бүре синең балаңны алып китте», – дип үз сүзен дөреслеккә чыгарырга теләгән.

Әлеге бәхәсне хәл итү өчен, баланы алып, алар Давыд галәйһиссәлам янына барганнар. Мәсьәлә бик катлаулы булган, чөнки ике хатынның берсе дә юл бирергә теләмәгән, һәм аларның сүзләрен раслаучы яки кире кагучы шаһитлар да булмаган. Озак кына уйлаганнан соң Давыд галәйһиссәлам яше буенча өлкәнрәк хатын-кызны яклап чыккан, икенче хатын-кыз исә моның белән килешмичә барысын да Сөләйман галәйһиссәламгә сөйләп биргән. Пәйгамбәр аны тыңлап, болай дип җавап биргән:

– Әгәр сез чыгарылган карар белән килешмәсәгез, баланы урталайга чабыгыз. Ул сезнең икегезгә яртылаш эләксен, икегезгә дә бала булыр.

Карарның коточкыч булуына да карамастан, өлкән хатын-кызны бу тәкъдим канәгатьләндергән, һәм ул баланы урталай ярырга рөхсәт биргән. Ә менә икенчесе, бала гомере өзелүдән куркып, үзенең дәгъваларыннан баш тартып: «Баланы ярмагыз. Мин баладан баш тартам, ул аңа булсын», – дип әйткән.

Шуннан соң Сөләйман галәйһиссәламгә аларның кайсысының чыннан да яратучы әни булуы ачыктан-ачык аңлашылган. Ул баланы газапламас өчен, аның белән аерылышуны артыграк күргән әнигә сабыйны биргән.

Хәзер инде баласын бүре алып киткән өлкән хатынның, шушы кайгылы көннәр авыр мизгелләр булып күз алдына килеп басмасын дип, чит баладан котылырга әзер булуы да аңлашылган.

## Дөньядан китүнең вакыты һәм урыны – үзгәрешсез

Сөләйман галәйһиссәлам хаким булып, көн саен кешеләрнең гозерләрен тыңларга һәм аларның борчуларын хәл итәргә вакыт тапкан. Бервакыт, мохтаҗлар белән шундый әңгәмәләрнең берсендә, аның янына бик тә мәртәбәле бер кеше кергән. Сөләйман каршында үзенең борчулары турында сөйләүче хәерченең утыруын күреп, ул аңа бик тә текәлеп карый башлаган. Аның карашы шулкадәр көчле булган ки, теге мескен куркуга калган һәм Сөләйман галәйһиссәламнән болай дип сораган:

– Ий Аллаһының илчесе! Миңа явызлык белән караучы бу кеше кем?

Сөләйман галәйһиссәлам моның кунакка килгән Газраил галәйһиссәлам булуын әйткән. Әлеге кеше «Газраил» сүзен ишетү белән үк, агарынып, куркудан калтырый башлаган. Коточкыч халәттә һәм дулкынланып ул Сөләйман галәйһиссәламгә түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать иткән:

– Ий Аллаһының илчесе! Мин Газраил галәйһиссәламнең миңа явызлык белән каравын күрдем. Ул мине карашы белән көлгә әйләндерергә әзер иде. Аллаһы Тәгалә сиңа шундый хакимлек биргән ки, Ул сиңа хайваннарны һәм кошларны, шулай ук җилне һәм ташларны буйсындырган. Синнән сорыймын ки, җилгә әмер биреп, ул мине моннан еракка, Һиндстанга алып китсә иде. Бу урыннан еракка китеп, мин Газраил галәйһиссәламнең явызлыгыннан имин булырмын.

Сөләйман галәйһиссәлам бу кешене кызганган һәм, аны Һиндстанга күчерү өчен, җилгә әмер биргән. Җил исә, әмергә буйсынып, аны элэктереп алган да, ерактагы Һиндстан тавына илтеп ташлаган.

Аннары Сөләйман галәйһиссәлам Газраил галәйһиссәламнән:

– Ий Газраил! Ни өчен син миңа килгән кешегә шулкадәр текәлеп карадың? Нигә син аны куркыттың? – дип сораган.

Газраил галәйһиссәлам аның соравына болай дип җавап биргән:

– Ий Аллаһының илчесе! Мин бу кешегә явызлык белән түгел, гаҗәпләнү белән карадым. Мине шунысы гаҗәпләндерде: ул – монда, ә Аллаһы Тәгалә бу кешенең җанын миңа Һиндстанда алырга боерды. Мин уйга калдым: «Мин әмерне үти алыр өчен, кыска гына вакыт аралыгында бу кеше ничек Һиндстанда була алачак?» Ул синнән җилгә әмер биреп Һиндстанга илтүен сорагач, миңа барысы да аңлашылды.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«...Вакытлары җиткәч, аны бер сәгатькә генә дә артка да, алга дә күчерә алмаслар».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:61

## Ризыкны Аллаһы бирә

Сөләйман галәйһиссәлам җил һәм җен белән идарә иткән, шулай ук бөҗәкләрнең, кошларның һәм хайваннарның телен аңлаган. Бервакыт кырмыска белән сөйләшеп, Сөләйман галәйһиссәлам аннан елга никадәр азык кирәк булуы турында сораган. Кырмыска аңа:

– Мин елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм, – дип әйткән.

Әлеге сүзләрнең дөреслегенә ышану өчен, Сөләйман галәйһиссәлам бер пыяла савытка бодай орлыгын һәм кырмысканы салган да, капкачын ябып куйган.

Бер ел узгач, Сөләйман галәйһиссәлам әлеге савытны ачкан һәм кырмысканың бары ярты орлыкны гына ашап бетергәнен күргән. Шулвакытта Сөләйман галәйһиссәлам кырмыскага бер ел элек булган сөйләшү хакында искә төшергән:

– Син елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм дигән идең. Әмма күрәм, син бары яртысын гына ашагансың.

Моңа җавап итеп, кырмыска аңа болай дип әйткән:

– Әйе, барысы да дөрес, мин елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм. Әмма моңа кадәр миңа азыкны Аллаһы Тәгалә биргән иде һәм мин Аның

рәхмәтенә өмет багладым. Ә хәзер минем ризыгым көчсез кеше кулына калды. Мин синең мәрхәмәтле булуыңа ышанмадым һәм бары ярты орлыкны гына ашадым, ә калган яртысын киләчәк көннәргә калдырдым.

Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

وَمَا مِن دَابَّةٍ فِي الْأَرْضِ إِلَّا عَلَى اللَّهِ رِزْقُهَا وَيَعْلَمُ مُسْتَقَرَّهَا وَمُسْتَوْدَعَهَا ۚ كُلٌّ فِي كِتَابٍ مُّبِينٍ ﴿٦﴾

**«Җирдә Аллаһы ризык бирмәгән бер генә җан иясе дә юк. Ул аларның урнашкан урыннарын да, [аналарының карыннарыннан алып, үлгәннәреннән соң дәфен ителгәнчегә кадәр] сакланган урыннарын да белә. [Бөтен җан ияләренең саны, ризыклары, урыннары, әҗәлләре – боларның] Һәммәсе дә апачык [Ләүхүл-Мәхфүз исемле] бер китапта [язылган]».**

«Һуд», 11:6

## Кырмысканың догасы

Бервакыт Сөләйман галәйһиссәламнең илендә корылык һәм ачлык башлана. Дәүләт башлыгы буларак, ул үз халкы белән бергә яңгыр сорап, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәргә карар кылган. Гыйбадәт кылу урынына бару юлында аның игътибарын бер кырмыска җәлеп иткән. Шул кечкенә генә бөҗәк, аягын өскә күтәреп, аркасына ятып дога кылган. Тыңлап торганнан соң, Сөләйман галәйһиссәлам кырмысканың Аллаһыга ничек ялварганын ишеткән. Кырмыска болай дип дога кылган:

– Ий Аллаһы! Син безне бар кылдың. Син бүләкләгән язмышта без Синең Рәхмәтеңә мохтаҗбыз. Башкаларның җинаяте сәбәпле, безне һәлак итмәвеңне үтенәм.

Шулчак Җәбраил галәйһиссәлам килгән дә, әлеге кырмысканың догасы кабул булуы турында хәбәр биргән. Сөләйман галәйһиссәлам җыелган халыкка:

– Кире кайтыгыз. Яңгыр килүен сорап, тиешле дога кылынды инде. Бу кырмыска Аллаһыга мөрәҗәгать итте һәм аның догасы кабул ителде, – дип әйткән.

Менә шулай, кеп-кечкенә кырмысканың бөек һәм ихлас догасы сәбәпле, тулы бер халык ачлыктан котылуга ирешә. Хакыйкатьтә, Аллаһы безне бары тәкъвалыгыбыз һәм иман ныклыгы дәрәҗәсенә карап хөкем итә.

## Сөләйман галәйһиссәлам һәм кырмыска

Сөләйман галәйһиссәлам үзенең зур гаскәре белән юлга чыкканда, кырмыска белән бәйле тагын бер вакыйга булган. Юлда ул янә кырмыскалар күче белән очрашкан. Алар ару-талуны белми кышка әзерләнгәннәр. Сөләйман галәйһиссәламнең гаскәрен күреп, ана кырмыска мондый әмер биргән:

– Ий кырмыскалар! Сөләйман галәйһиссәлам гаскәре сезне ялгыш таптап китмәсен, юл бирегез һәм ояга кереп яшеренегез.

Сөләйман галәйһиссәлам ана кырмысканың әмерен ерактан ук ишетеп елмайган һәм, кырмыскалар ояларына кереп качарга өлгерсеннәр өчен, үзенең хәрбиләренә дә туктарга кушкан.

Фәхреддин Әр-Рази үзенең тәфсирендә бу вакыйгага бәйле рәвештә болай дип әйтә: «Кырмыскаларга ояларына керергә әмер бирелә. Ана кырмыска нидән курка соң? Ана кырмыска Сөләйман галәйһиссәлам хакимиятенең санын, күплеген, зурлыгын күрә калсалар, эшче кырмыскалар Аллаһы аларны бүләкләгән нигъмәтләргә карата рәхмәтсез булырлар, дип курка».

Бу вакыйга Коръәни Кәримдә дә чагылыш тапкан:

حَتَّىٰٓ إِذَآ أَتَوْا۟ عَلَىٰ وَادِ ٱلنَّمْلِ قَالَتْ نَمْلَةٌ يَٰٓأَيُّهَا ٱلنَّمْلُ ٱدْخُلُوا۟ مَسَٰكِنَكُمْ لَا يَحْطِمَنَّكُمْ سُلَيْمَٰنُ وَجُنُودُهُۥ وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ ﴿١٨﴾

**«[Шамның] Кырмыскалар [белән тулы бер] үзәненә барып җиткәч, [аларның хөкемдарлары булган] бер ана кырмыска: «Ий кырмыскалар! Ояларыгызга керегез! Сөләйман [галәйһиссәлам] һәм аның гаскәрләре сезне абайламыйча таптамасын!» – диде».**

«Ән-Нәмл / Кырмыскалар», 27:18

Кырмыска турындагы хикәяттә бер хаким иясе үзенең кул астындагыларга бөек хикмәт, ә икенче берсе чын мәгънәсендә миһербанлык үрнәге күрсәтә. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Сез барыгыз да көтүчеләр һәм үз көтүегез өчен җавап тотасыз...», – дип әйткән. Ә Сөннәт барлык заманнар өчен мәңгелек булып тора, һәм аңа һәр кеше, шул исәптән, хөкемдарлар да үзенең гадел идарә итүе белән иярергә тиеш. Шул чагында алар Аллаһының һәм үз халыкларының ризалыгына лаек булачак.

Бәрәкәтле идарәнең нигезе – үзеңнең кул астында эшләгән барлык кешеләрнең дәрәҗәсенә, байлыгына, диненә һәм милләтенә карамастан, зирәк һәм гадел булу ул. Ә халыкның бурычы – Аллаһы Тәгалә тарафыннан тәкъдир кылынган җитәкче артыннан бару. Карагыз: Сөләйман галәйһиссәлам нинди бөек хаким булган, шуңа аның даны мең еллар узгач та тынмый! Раббыбыз барлык дәүләт җитәкчеләрен һәм хакимнәрне гадел һәм киң күңелле кылса иде. Коръәндә әйтелгәнчә, хәтта бөҗәк тә хакимлек итүчеләрне якларга тырыша бит.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Коръән сүрәләренең мәгънәви тәрҗемәләре

## 57. Әл-Хәдид (Тимер) сүрәсе

Мәдинә чоры, 29 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән!

1. **Күкләрдә булганнар һәм җирдә булганнар Аллаһны** [барлык кимчелекләрдән ерак тотып] **тәсбих итә. Ул – Бөек** [Җиңелмәс], **Хикмәт иясе.**
2. **Ул – әһле китаптан кяфер булганнарны** [Гарәп ярымутравыннан Шамга] **беренче сөрген өчен йортларыннан чыгаручы.** [И, мөселманнар! Аларның көчләрен белгәнегез өчен.Сез алар китәр дип уйламаган идегез, алар исә кальгалары аларны Аллаһтан саклар дип уйлаганнар иде, ләкин Аллаһ [хозурыннан булган газап] **аларга һич көтмәгән җирләреннән килде** [дә, башлыклары Кәгъб ибне Әшрәфнең сөт кардәше Мөхәммәд ибне Мәсләмә кулы белән үтерелүе моны башлап җибәрде]. **Ул аларның йөрәкләренә курку салды. Алар үз өйләрен** [мөселманнарга калмасын дип, эчке яктан] **үз куллары һәм** [тышкы яктан] **мөэминнәрнең куллары белән җимерәләр. И,** [күңел күзләре] **күрә алганнар!** [Боларның башына килгәнне яхшылап уйлагыз да, сүз бозу һәм Аллаһтан башкаларга ышануның китергән җимерелүләре мәсьәләсендә] **Гыйбрәт алыгыз!**
3. **Әгәр дә Аллаһ аларга сөрелүне язмаган булса, әлбәттә, аларны дөньяда ук** [Курайза уллары башына килгән үтерелү һәм әсирлек кебек башка юллар белән] **җәзага дучар итәчәк иде. Ахирәттә дә аларга Ут газабы** [әзерләнгән].
4. [Расүлем!] **Бу** [кяферләр башына килгән бәла] **– Аллаһка һәм Аның расүленә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) каршы торганнары өчен. Кем дә кем Аллаһка каршы торса, һичшиксез, Аллаһның газабы бик каты.**
5. **Хөрмә агачларының кайберләрен кисүегез яки аларны тамырларында басып торган килеш калдыруыгыз** [берсе дә сезнең үз

башбаштаклыгыгыз түгел] **бары Аллаһның рөхсәте белән һәм** [Аңа итагатьтән чыккан] **фасикъларны рисвай итәр өчен** [булды]**.**

6. [Дөньяда яшәү – Раббыларына иман китергән һәм Аңа итагатьле булганнарның хакы, шул сәбәпле, кяферләр хаклары булмыйча яшиләр, шуңа күрә] **Аллаһның алардан расүленә** [сугышсыз] **биргән ганимәтләргә сез атларда яки дөяләрдә юртып бармадыгыз** [Расүлуллаһтан (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) башка, барыгыз да җәяүләп бардыгыз, димәк, сез аларны сугыш юлы белән яуламадыгыз]**, ләкин Аллаһ расүлләрен теләгән кемсәләре өстенә җибәрә. Аллаһ һәрнәрсәгә** [көче җиткән] **кодрәтле.**
7. **Шәһәрләрнең** [кяфер] **халкыннан Аллаһ Үзенең расүленә** [ганимәт буларак] **кайтарган** [мал һәм кучемсез милек кебек] **нәрсәләр – Аллаһ, пәйгамбәре (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) һәм аның** [нәселдәшлек ягыннан] **якыннары, ятимнәр, мескеннәр һәм юлда калганнар өчен. Болар арагыздан байларга бүленеп бирелгән** [һәм аларның көченә көч өстәгән нәрсә] **булмасын. Расүл сезгә нәрсә бирсә, шуны** [кабул итеп] **алыгыз, сезне нәрсәдән тыйса,** [шуннан] **ваз кичегез. Аллаһтан куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһның** [пәйгамбәренә каршы килүчеләргә] **газабы каты!**
8. [Ганимәтләр нахакка] **Йортларыннан һәм малларыннан куылган фәкыйрь мөһаҗирләр өчен дә. Алар Аллаһның фазылына һәм ризалыгына омтылалар һәм Аллаһка вә Аның расүленә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) ярдәм итәләр. Алар – тугрылар.**
9. **Моңа кадәр** [Мәдинә дигән] **йортта яшәгән һәм күңелләренә иманны салган кешеләр үзләренә** [Мәккәдән] **һиҗрәт кылган кешеләрне** [җаннары-тәннәре белән] **сөяләр, аларга** [мөһаҗирләргә] **бирелгән** [ганимәт малы кебек] **нәрсәләрдән бернинди көнләшү хис итмиләр. Үзләрендә ихтыяҗ булса да,** [ашамыйча-ашатып, киенмичә-киендереп] **аларны үзләреннән өстен күрәләр. Кем дә кем нәфесенең комсызлыгыннан саклана** [һәм Аллаһ юлында сарыф итә]**, шулар – уңышка** [һәм котылуга] **ирешүчеләр.**
10. **Алардан** [мөһаҗир һәм әнсарлардан] **соң** [дөньяга] **килгәннәр исә: «И, Раббыбыз! Безне дә, бездән алда иман китерүчеләрне дә ярлыка һәм иман китергән кешеләргә карата күңелләребезгә ачу салма. И, Раббыбыз! Һичшиксез, Син – Аяучан, Рәхимлесең.** [Шул сәбәпле догаларыбызны кабул әйлә]**», – диләр.**
11. [Расүлем! Габдуллаһ ибне Үбәй, Вәдига ибне Малик һәм Сүвәйд кебек]

**Монафикъларның әһле китаптан булган кяфер** [Курайза һәм Надыйр уллары] **кардәшләренә** [кеше җибәреп]**: «Әгәр сез** [йортларыгыздан] **куып чыгарылсагыз, без дә сезнең белән бергә китәчәкбез, сезгә каршы беркемгә дә беркайчан да итагать итмәбез. Әгәр сезнең белән сугышсалар, без сезгә ярдәм итәчәкбез», – дип әйткәннәрен күрмәдеңмени? Аллаһ аларның ялганчы булганлыкларына шаһитлык итә.**

12. **Әгәр алар** [йортларыннан] **куып чыгарылсалар, алар белән бергә китмәячәкләр, сугышка керсәләр,** [сүзләрен бозып] **аларга ярдәм итмәячәкләр, ярдәм итәсе булсалар да, алар артларына борылачаклар, соңыннан аларга ярдәм ителмәячәк.**
13. [И, мөселманнар!] **Сез – аларның** [монафикъларның] **күкрәкләрендә** [һәм күңелләрендә] **Аллаһтан** [куркуга караганда] **да куркынычрак. Шул сәбәпле алар –** [Аллаһның бөеклеген] **аңламый торган кешеләр.**
14. **Алар** [яһүдиләр һәм монафикълар беркайчан һәм беркайда да] **бергә җыелып сезгә каршы сугышмаслар, ныгытылган шәһәрләрдә яки диварлар артыннан булмаса гына.** [Әмма бу аларның көчсезлегеннән һәм куркаклыгыннан түгел, чөнки] **Аларның берберләренә булган дошманлыгы көчле** [ләкин сезнең белән очрашкач, Аллаһ күңелләренә салган курку сәбәпле кул һәм аякларының дәрманы калмый]**.** [Расүлем!] **Син аларны бердәм дип исәплисең, ләкин аларның күңелләре аерым. Бу – аларның акылларын кулланмый торган кешеләр булганы өчен.**
15. [Надыйр улларының хәле] **Үзләреннән бераз элегрәк эшләре өчен** [дөньяда ук] **зарарын татыганнарның** [Курәйзә улларының] **хәле кебек** [Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) аларның кулына корал тота алганнарын үтертте, калганнарын исә әсир итте]**. Аларга** [Ахирәттә дә] **тилмерткеч газап бар.**
16. [Монафикъларның кешеләрне алдаудагы хәле] **Нәкъ шайтанның хәле шикелле, чөнки ул** [мәгарәсендә гыйбадәткә бирелгән Бәрсыйса исемле] **кешегә: «**[Миңа сәҗдә кылып] **Кяфер бул** [да, сине коткарачакмын]**», – дигән иде. Ул кяфер булгач: «Мин синнән ваз кичәм, чөнки мин галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһтан куркамын», – дигән иде.**
17. **Аларның икесенең дә ахыры – Утта. Алар анда мәңге калачак. Бу –** [ширек кушып, иң зур золым эшләгән] **залимнәрнең җәзасы.**

18. **И, иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз һәм** [кешеләрнең күбесе гафләт эчендә булса да, һичьюгы бер генә] **җан** [булса да, үзе яшәгән көннән] **иртәгәлек** [кебек якын булган Кыямәт көне] **өчен элегрәк ни әзерләгәнен карасын! Аллаһтан куркыгыз! Һичшиксез, Аллаһ сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар.**
19. **Аллаһны оныткан, шул сәбәпле Ул да аларга үз-үзләрен оныттырган кешеләр кебек булмагыз. Әнә шулар –** [Аллаһның итагатеннән чыккан] **фасикъләр.**
20. **Ут әһелләре** [булу хакын алган кяферләр] **белән** [иманга һәм тәкъвалыкка ябышып] **җәһәннәм әһеле** [булуны хак иткән кешеләр] **бертигез түгел. Җәннәт әһелләре – уңышка ирешүчеләр.**
21. **Әгәр дә Без бу** [кадәрле әһәмиятле мәсьәләләрне эченә алган] **Коръәнне бер тауга иңдергән** [һәм аңа да сезгә биргән кебек акыл биргән] **булсак, син аны Аллаһтан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең. Бу мисалларны Без кешеләргә фикерләсеннәр дип китерәбез.**
22. **Ул Аллаһ ки, Аннан башка** [гыйбадәткә лаек] **һичбер илаһ юк. Ул –** [бер генә барлыкның да гыйлеме һәм тойгысы ирешә алмаслык] **күренмәгәнне дә,** [һәркем тарафыннан] **күренгәнне дә** [дөньяда да, Ахирәттә дә, юкны да, барны да бик яхшы] **белүче. Ул –** [дөньяда мөэминне, кяферне аермыйча, һәр мәхлугын соң дәрәҗәдә кызганган һәм чын мәгънәсендә нигъмәт биргән] **Шәфкатьле, Рәхимле.**
23. **Ул Аллаһ ки, Аннан башка** [гыйбадәткә лаек] **һичбер илаһ юк. Ул –** [һәрнәрсәнең] **Хуҗасы, Кимчелексез,** [Үзе барлыкка китергәннәргә] **Иминлек һәм тынычлык бирүче,** [Үзенең тугрылыклы колларына] **Ышаныч һәи иминлек бирүче, Үзенә буйсындыручы, Бөек** [Җиңелмәс], [Көч-куәткә ия, бар нәрсә белән дә] **Идарә итүче, Чын бөеклеккә бердәнбер ия булучы. Аллаһ аларның ширек кылган нәрсәсеннән** [соң дәрәҗәдә пакь һәм] **ерак.**
24. **Ул Аллаһ –** [һәрнәрсәне бер хикмәт белән] **Барлыкка китерүче,** [кимчелекләрсез] **Бар итүче,** [бар нәрсәгә] **калып, рәвеш бирүче. Иң күркәм** [мәгънәләрне белдергән] **исемнәр дә – Аныкы. Күкләрдә һәм җирдә булучылар Аны** [мактап] **тәсбих итә. Ул Бөек** [Җиңелмәс]**, Хикмәт иясе.**

## 58. Әл-Мүҗәәдәлә (Сүз көрәштерү) сүрәсе

Мәдинә чоры, 22 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән!

1. [Расүлем!] **Ире хакында синең белән сүз көрәштергән һәм зарын Аллаһка белдергән хатынның сүзен Аллаһ ишетте. Аллаһ һәр икегезнең дә сөйләшүегезне ишетә. Һичшиксез, Аллаһ –** [һәрнәрсәне] **Ишетүче,** [һәрнәрсәне] **Күрүче.**
2. **Сезнең арагыздан хатыннарын аналарының аркалары кебек дип игълан итүчеләр** [дин ягыннан да, акыл ягыннан да] **буш һәм ялган сүз әйтәләр. Алар** [хатыннар] **аларның аналары түгел. Аларның аналары бит аларны тудыручылар гына.** [Шуңа күрә харамлык мәсьәләсендә сөт аналары һәм Расүлуллаһның (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) хатыннары кебек Аллаһы Тәгалә билгеләгән хатын-кызлар гына үз аналарына охшатыла ала. Никахланышкан хатыннары – аларның анасы урынында булудан иң ерак барлыклар]**. Һичшиксез, Аллаһ – Ярлыкаучы,** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче.**
3. **Хатыннарын аналарының аркалары кебек дип игълан итүчеләр соңыннан әйткән сүзләреннән кайтучыларга** [женси мөнәсәбәт яки женес әгъзасына шәһвәт белән карау яисә шәһвәт белән] **бер-берләренә кагылуларыннан алда** [ирнең] **бер кол азат итүе** [тиешле]**. Моның белән сез** [мондый харамнарны бүтән кылмавыгыз өчен] **вәгазьләнәсез. Аллаһ ни кылганнарыгыздан хәбәрдар.**
4. **Кем дә кем** [кол азат итү мөмкинлеге] **таба алмаса, бер-берләренә кагылганчы,** [ир кеше] **бер-бер артлы ике ай ураза** [тотарга тиеш була]**. Ләкин кем дә кем моңа да мөмкинлек таба алмаса, алтмыш мескенне ашату** [өстенә төшә]**. Бу** [хөкемнәрнең аңлатылуы] **Аллаһка һәм Аның расүленә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) иман китерүегез** [һәм җаһилият дәверендәге әшәке гадәтләрегезне калдыруыгыз] **өчен** [башкарыла]**. Болар – Аллаһның** [куйган] **чикләре.** [Боларны кабул итмәгән] **Кяферләр өчен тилмерткеч газап бар.**
5. **Аллаһка һәм Аның расүленә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) дошманлык кылучылар алардан алдагы** [дин дошманы булган] **кешеләр рисвай ителгән кебек, болар да рисвай ителделәр. Без** [илчебезнең хаклыгын күрсәткән] **ап-ачык аятьләр иңдергән идек. Инкяр итүчеләргә каты газап бар.**
6. **Аллаһ аларның барысын да терелтәсе һәм кылган** [начар]

**нәрсәләрен аларга** [берәм-берәм] **хәбәр итәсе** [куркыныч] **көнне** [аларга аңлат]**. Аллаһ аны** [гамәлләрен] **санады, алар исә аны оныттылар. Аллаһ – һәрнәрсәгә шаһит.**

7. [Расүлем!] **Күрмәдеңме, Аллаһ күкләрдә булганнарны һәм җирдә булганнарны белә. Ул** [гыйлеме, ишетүе, күрүе белән аларның] **дүртенчеләре булмый торып, өч кешенең яшерен сөйләшүе** [дигән бернәрсә] **булмый, яки Ул** [Аллаһ] **алтынчылары** [буларак яннарында] **булмый торып, биш кешенең дә** [яшерен сөйләшүе] **булмый. Моннан азрак** [булган ике кешенең бер-берсе белән яшерен сөйләшүе, яки бер генә кешенең нәфесе белән сөйләшүе] **һәм** [алты яки тагын да] **күбрәк** [кешенең пышылдашуы һич] **булмый, кайда гына булсалар да, Ул** [гыйлеме белән] **алар белән бергә була. Шуннан соң, Кыямәт көнендә Ул аларга** [дөньяда чакта] **кылган** [начар] **нәрсәләрен хәбәр итәчәк. Һичшиксез, Аллаһ** [колларының серләренә кадәр] **һәрнәрсәне** [бик яхшы] **белә.**
8. **Яшерен сөйләшү тыелганнарны** [яһүди һәм монафикъларны] **күрмәдеңме? Алар үзләренә тыелган нәрсәгә кабат кайталар һәм** [ялган кебек бер] **гөнаһ белән,** [мөселманнарга] **дошманлык белән, Расүлгә, (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) буйсынмау белән** [бәйле җыелышлар ясап] **яшерен сөйләшәләр. Әмма сиңа килгән вакытларында, Аллаһ сине сәламләмәгән бернәрсә белән сиңа саулык телиләр. Үз араларында исә: «Без сөйләгән нәрсәләр сәбәпле, нишләп Аллаһка безгә җәза бирмәскә!? – диләр. Аларга җәһәннәм җитә,** [тулысынча] **аңа керәчәкләр. Ул – нинди яман бару урыны!**
9. **И, иман китерүчеләр! Яшерен сөйләшкән вакытыгызда, гөнаһ белән, дошманлык белән һәм Расүлгә буйсынмау белән** [бәйле мәсьәләләр турында] **пышылдашмагыз. Игелек белән һәм тәкъвалык белән пышылдашыгыз.** [Һәр эштә] **Аллаһтан куркыгыз ки, сез Аңа җыелачаксыз.**
10. [Гөнаһ һәм золым мәсьәләсендәге] **Яшерен сөйләшү – иман китергән кешеләрне кайгыга салыр өчен шайтаннан** [килгән нәрсә]**. Әмма Аллаһның теләге белән булмаса, ул** [шайтан] **аларга берни белән дә зарар китерә алмый. Иман китерүчеләр Аллаһка гына тәвәккәл кылсын** [да, аларның яшерен-ачык һичбер сөйләшүләренә алданмасын]**.**
11. **И, иман китерүчеләр! Сезгә: «**[Расүлуллаһның (салләллаһу

галәйһи вә сәлләм) сохбәт] **мәҗлесләрдә** [этеш-төртеш аркасында бер-берләрегезгә урын ачып] **Киңәя төшегез!» – диелгәч, киңәя төшегез ки, Аллаһ та сезгә иркенлек бирер.** [Пәйгамбәр мәҗлесенә килүчеләрнең артуы сәбәпле:] **«Торыгыз!» – диелгәч исә,** [һич каршы дәшмичә] **торып басыгыз ки, Аллаһ та арагыздан иман китергәннәрне һәм гыйлем бирелгән кешеләрне дәрәҗә ягыннан күтәрер. Аллаһ сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар.**

12. **И, иман китерүчеләр! Расүл (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) белән яшерен сөйләшкән чагыгызда, ул яшерен сөйләшүегезнең алдыннан** [фәкыйрьләргә] **садака бирегез. Бу сезнең өчен** [саранлыктан] **яхшырак һәм** [малга хирыслык кебек гөнаһлардан] **чистарак. Әмма әгәр дә** [бирергә берни дә] **таба алмасагыз, һичшиксез, Аллаһ –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле.**
13. [И, мөмкинлек ияләре!] **Яшерен сөйләшүләрегез алдыннан садакалар бирүегездән** [нишләп баш тарттыгыз, әллә шайтанның фәкыйрьлек белән куркытуына алданып] **курыктыгызмы? Әгәр дә инде** [моны] **эшләмәдегез икән, Аллаһ** [бу хактагы] **тәүбәгезне дә кабул иткән икән,** [фарыз] **намаз укыгыз, зәкят бирегез һәм** [һәр мәсьәләдә] **Аллаһка да, Аның расүленә дә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) буйсыныгыз. Аллаһ сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар.**
14. [Расүлем!] **Аллаһ ачуланган кешеләрне дус итүчеләрне** [монафикъларны] **күрмәдеңмени?** [И, мөэминнәр!] **Алар сездән дә түгелләр, алардан да түгелләр. Алар, белә торып,** [«мөселманмын» дип] **ялган ант бирәләр.**
15. **Аллаһ аларга каты газап әзерләде. Һичшиксез, алар кылган нәрсәләр нинди яман!**
16. **Алар антларын бер калкан иттеләр, шул сәбәпле Аллаһның юлыннан тайпылдырдылар. Алар өчен хурлыклы газап бар.**
17. **Маллары да, балалары да Аллаһтан** [Аның газабыннан] **бернәрсәне дә алардан ераклаштырмаячак. Алар – Ут әһелләре. Алар анда мәңге калачаклар.**
18. **Аллаһ аларны барысын бергә терелтәсе** [куркыныч] **көнне ки,** [бүген] **сезгә** [«мөселманбыз» дип алдап] **ант иткәннәре кебек,** [ул көнне дә: «Раббыбыз булган Аллаһ белән ант итәбез, без мөшрикләр түгел идек», – дип] **Аңа да ант итәчәкләр. Алар** [Ахирәттә бирәчәк ялган антлары белән] **үзләренә ярдәм итәрләр дип санаячаклар.**

**Һичшиксез, алар –** [һәрнәрсәне белгән Затның хозурында хәтта ялган сөйләргә батырчылык итәрлек хәлгә җиткән] **ялганчылар.**

19. **Шайтан аларны яулап алды һәм Аллаһның зикере турында оныттырды. Алар – шайтанның фиркасы. Һичшиксез, шайтанның тарафдарлары –** [чиксез нигъмәт урынына мәңгелек газапны сайлап] **зарар күрүчеләр.**

20. **Аллаһка һәм Аның расүленә дошман булган кешеләр кимсетелгәннәр арасында.**

21. **Аллаһ** [әзәлдән бирле карар биреп, соңыннан Ләүхелмәхфүзгә]**: «Тулысынча Мин җиңәчәкмен, расүлләрем дә!** [Әмма аларның бу җиңүе я дәлил һәм кылыч белән, я икесеннән берсе белән гамәлгә ашачак]**», – дип язды. Һичшиксез, Аллаһ – Иң көчле, Бөек** [Җиңелмәс]**.**

22. **Аллаһка һәм Соңгы көнгә иман китергән кешеләрне – Аллаһка һәм Аның пәйгамбәренә дошман булган кешеләрне дус иткән хәлдә тапмассың, хәтта ки алар, аларның аталары яки уллары, яки кардәшләре, яки ырулары булса да. Аларның йөрәкләренә Ул иманны язды** [аны нык итте] **һәм аларны Үзеннән бер рух** [булган һәм җаннарының җаны урынында торган иман һәм Коръән нуры] **белән куәтләндерде. Ул аларны** [сарайлары һәм агачлары] **асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә кертәчәк, һәм алар анда мәңге калачак. Аллаһ алардан разый, алар исә Аннан** [Ул вәгъдә иткән әҗер-саваплардан] **разый. Алар – Аллаһның тарафдарлары. Әйе, Аллаһның тарафдарлары, һичшиксез,** [ике җиһан бәхетен казаначак] **уңышка ирешүчеләр.**

## 59. Әл-Хәшр [Җыен] сүрәсе

Мәдинә чоры, 24 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Күкләрдә булганнар һәм җирдә булганнар Аллаһыны** [барлык кимчелекләрдән ерак тотып] **тәсбих итә. Ул – Бөек** [Җиңелмәс]**, Хикмәт иясе.**
2. **Ул – әһле китаптан кяфер булганнарны** [Гарәп ярымутравыннан Шамга] **беренче сөрген өчен йортларыннан чыгаручы.** [Ий мөселманнар! Аларның көчләрен белгәнегез өчен] **Сез алар китәр дип уйламаган идегез, алар исә кальгалары аларны Аллаһыдан саклар дип уйлаганнар иде, ләкин Аллаһы** [хозурыннан булган газап] **аларга һич көтмәгән җирләреннән килде** [дә, башлыклары Кәгъб бине Әшрәфнең сөт кардәше Мөхәммәд бине Мәсләмә кулы белән үтерелүе моны башлап җибәрде]. **Ул аларның йөрәкләренә курку салды. Алар үз өйләрен** [мөселманнарга калмасын дип, эчке яктан] **үз куллары һәм** [тышкы яктан] **мөэминнәрнең куллары белән җимерәләр. Ий** [күңел күзләре] **күрә алганнар!** [Боларның башына килгәнне яхшылап уйлагыз да, сүз бозу һәм Аллаһыдан башкаларга ышануның китергән җимерелүләре мәсьәләсендә] **Гыйбрәт алыгыз!**
3. **Әгәр дә Аллаһы аларга сөрелүне язмаган булса, әлбәттә, аларны дөньяда ук** [Курайза уллары башына килгән үтерелү һәм әсирлек кебек башка юллар белән] **җәзага дучар итәчәк иде. Ахирәттә дә аларга Ут газабы** [әзерләнгән]**.**
4. [Расүлем!] **Бу** [кяферләр башына килгән бәла] **– Аллаһыга һәм Аның расүле** салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә **каршы торганнары өчен. Кем дә кем Аллаһыга каршы торса, һичшиксез, Аллаһының газабы бик каты.**
5. **Хөрмә агачларының кайберләрен кисүегез яки аларны тамырларында басып торган килеш калдыруыгыз** [берсе дә сезнең үз башбаштаклыгыгыз түгел] **бары Аллаһының рөхсәте белән һәм** [Аңа итагатьтән чыккан] **фасикъларны рисвай итәр өчен** [булды]**.**
6. [Дөньяда яшәү – Раббыларына иман китергән һәм Аңа итагатьле булганнарның хакы, шул сәбәпле, кяферләр хаклары булмыйча яшиләр, шуңа күрә] **Аллаһының алардан расүленә** [сугышсыз] **биргән ганимәтләргә сез атларда яки дөяләрдә юртып бармады-**

**гыз** [Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән башка, барыгыз да җәяүләп бардыгыз, димәк, сез аларны сугыш юлы белән яуламадыгыз]**, ләкин Аллаһы расүлләрен теләгән кемсәләре өстенә җибәрә. Аллаһы һәрнәрсәгә** [көче җиткән] **кодрәтле.**

7. **Шәһәрләрнең** [кяфер] **халкыннан Аллаһы Үзенең расүленә** [ганимәт буларак] **кайтарган** [мал һәм күчемсез милек кебек] **нәрсәләр – Аллаһы, пәйгамбәре** салләллаһу галәйһи вә сәлләм **һәм аның** [нәселдәшлек ягыннан] **якыннары, ятимнәр, мескеннәр һәм юлда калганнар өчен. Болар арагыздан байларга бүленеп бирелгән** [һәм аларның көченә көч өстәгән нәрсә] **булмасын. Расүл сезгә нәрсә бирсә, шуны** [кабул итеп] **алыгыз, сезне нәрсәдән тыйса,** [шуннан] **ваз кичегез. Аллаһыдан куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһының** [пәйгамбәренә каршы килүчеләргә] **газабы каты!**
8. [Ганимәтләр нахакка] **Йортларыннан һәм малларыннан куылган фәкыйрь мөһаҗирләр өчен дә. Алар Аллаһының фазылына һәм ризалыгына омтылалар һәм Аллаһыга вә Аның расүле** салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә **ярдәм итәләр. Алар – тугрылар.**
9. **Моңа кадәр** [Мәдинә дигән] **йортта яшәгән һәм күңелләренә иманны салган кешеләр үзләренә** [Мәккәдән] **һиҗрәт кылган кешеләрне** [җаннары-тәннәре белән] **сөяләр, аларга** [мөһаҗирләргә] **бирелгән** [ганимәт малы кебек] **нәрсәләрдән бернинди көнләшү хис итмиләр. Үзләрендә ихтыяҗ булса да,** [ашамыйча-ашатып, киенмичә-киендереп] **аларны үзләреннән өстен күрәләр. Кем дә кем нәфесенең комсызлыгыннан саклана** [һәм Аллаһы юлында сарыф итә]**, шулар – уңышка** [һәм котылуга] **ирешүчеләр.**
10. **Алардан** [мөһаҗир һәм әнсарлардан] **соң** [дөньяга] **килгәннәр исә: «Ий Раббыбыз! Безне дә, бездән алда иман китерүчеләрне дә ярлыка һәм иман китергән кешеләргә карата күңелләребезгә ачу салма. Ий Раббыбыз! Һичшиксез, Син – Аяучан, Рәхимлесең.** [Шул сәбәпле догаларыбызны кабул әйлә]**», – диләр**[1]**.**
11. [Расүлем! Габдулла бине Үбәй, Вәдига бине Малик һәм Сүвәйд кебек] **Монафикъларның әһле китаптан булган кяфер** [Курайза һәм Надыйр уллары] **кардәшләренә** [кеше җибәреп]**: «Әгәр сез**

1 Бу аяте кәримә сәбәпле, голәмә сәхабәләрнең һәммәсен дә сөю һәм яхшылык белән искә алу кирәклеген таныганнар һәм: «Сәхабәләрдән теләсә кайсына карата күңелендә генә булса да кинә һәм нәфрәт йөрткән кеше мөэминнәр белән бәйлә бу һәм моннан алдагы ике аяте кәримәдә санап узылган өч төркемгә керми һәм чын мөселманнар арасында бернинди дә насыйбы юк», – дигәннәр.

[йортларыгыздан] **куып чыгарылсагыз, без дә сезнең белән бергә китәчәкбез, сезгә каршы беркемгә дә беркайчан да итагать итмәбез. Әгәр сезнең белән сугышсалар, без сезгә ярдәм итәчәкбез», – дип әйткәннәрен күрмәдеңмени? Аллаһы аларның ялганчы булганлыкларына шаһитлык итә.**

12. **Әгәр алар** [йортларыннан] **куып чыгарылсалар, алар белән бергә китмәячәкләр, сугышка керсәләр,** [сүзләрен бозып] **аларга ярдәм итмәячәкләр, ярдәм итәсе булсалар да, алар артларына борылачаклар, соңыннан аларга ярдәм ителмәячәк.**
13. [Ий мөселманнар!] **Сез – аларның** [монафикъларның] **күкрәкләрендә** [һәм күңелләрендә] **Аллаһыдан** [куркуга караганда] **да куркынычрак. Шул сәбәпле алар –** [Аллаһының бөеклеген] **аңламый торган кешеләр.**
14. **Алар** [яһүдиләр һәм монафикълар беркайчан һәм беркайда да] **бергә җыелып сезгә каршы сугышмаслар, ныгытылган шәһәрләрдә яки диварлар артыннан булмаса гына.** [Әмма бу аларның көчсезлегеннән һәм куркаклыгыннан түгел, чөнки] **Аларның берберләренә булган дошманлыгы көчле** [ләкин сезнең белән очрашкач, Аллаһы күңелләренә салган курку сәбәпле кул һәм аякларының дәрманы калмый]. [Расүлем!] **Син аларны бердәм дип исәплисең, ләкин аларның күңелләре аерым. Бу – аларның акылларын кулланмый торган кешеләр булганы өчен.**
15. [Надыйр улларының хәле] **Үзләреннән бераз элегрәк эшләре өчен** [дөньяда ук] **зарарын татыганнарның** [Курәйзә улларының] **хәле кебек. Аларга** [Ахирәттә дә] **тилмерткеч газап бар.**
16. [Монафикъларның кешеләрне алдаудагы хәле] **Нәкъ шайтанның хәле шикелле, чөнки ул** [мәгарәсендә гыйбадәткә бирелгән Бәрсыйса исемле] **кешегә: «**[Миңа сәҗдә кылып] **Кяфер бул** [да, сине коткарачакмын]**», – дигән иде. Ул кяфер булгач: «Мин синнән ваз кичәм, чөнки мин галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыдан куркамын», – дигән иде.**
17. **Аларның икесенең дә ахыры – Утта. Алар анда мәңге калачак. Бу –** [ширек кушып, иң зур золым эшләгән] **залимнәрнең җәзасы.**
18. **Ий иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм** [кешеләрнең күбесе гафләт эчендә булса да, һичьюгы бер генә] **җан** [булса да, үзе яшәгән көннән] **иртәгәлек** [кебек якын булган Кыямәт көне] **өчен элегрәк ни әзерләгәнен карасын! Аллаһыдан куркыгыз!**

**Һичшиксез, Аллаһы сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар.**
19. **Аллаһыны онытткан, шул сәбәпле Ул да аларга үз-үзләрен оныттырган кешеләр кебек булмагыз. Әнә шулар –** [Аллаһының итагатеннән чыккан] **фасикълар.**
20. **Ут әһелләре** [булу хакын алган кяферләр] **белән** [иманга һәм тәкъвалыкка ябышып] **җәһәннәм әһеле** [булуны хак иткән кешеләр] **бертигез түгел. Җәннәт әһелләре – уңышка ирешүчеләр.**
21. **Әгәр дә Без бу** [кадәрле әһәмиятле мәсьәләләрне эченә алган] **Коръәнне бер тауга иңдергән** [һәм аңа да сезгә биргән кебек акыл биргән] **булсак, син аны Аллаһыдан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең. Бу мисалларны Без кешеләргә фикерләсеннәр дип китерәбез.**
22. **Ул Аллаһы ки, Аннан башка** [гыйбадәткә лаек] **һичбер илаһ юк. Ул –** [бер генә барлыкның да гыйлеме һәм тойгысы ирешә алмаслык] **күренмәгәнне дә,** [һәркем тарафыннан] **күренгәнне дә** [дөньяда да, Ахирәттә дә, юкны да, барны да бик яхшы] **белүче. Ул –** [дөньяда мөэминне, кяферне аермыйча, һәр мәхлугын соң дәрәҗәдә кызганган һәм чын мәгънәсендә нигъмәт биргән] **Шәфкатьле, Рәхимле.**
23. **Ул Аллаһы ки, Аннан башка** [гыйбадәткә лаек] **һичбер илаһ юк. Ул –** [һәрнәрсәнең] **Хуҗасы, Кимчелексез,** [Үзе барлыкка китергәннәргә] **Иминлек һәм тынычлык бирүче,** [Үзенең тугрылыклы колларына] **Ышаныч һәм иминлек бирүче, Үзенә буйсындыручы, Бөек** [Җиңелмәс], [Көч-куәткә ия, бар нәрсә белән дә] **Идарә итүче, Чын бөеклеккә бердәнбер ия булучы. Аллаһы аларның ширек кылган нәрсәсеннән** [соң дәрәҗәдә пакь һәм] **ерак.**
24. **Ул Аллаһы –** [һәрнәрсәне бер хикмәт белән] **Барлыкка китерүче,** [кимчелекләрсез] **Бар итүче,** [бар нәрсәгә] **калып, рәвеш бирүче. Иң күркәм** [мәгънәләрне белдергән] **исемнәр дә – Аныкы. Күкләрдә һәм җирдә булучылар Аны** [мактап] **тәсбих итә. Ул Бөек** [Җиңелмәс], **Хикмәт иясе.**

# 60. Әл-Мүмтәхәнә (Сыналучы хатын) сүрәсе

Мәдинә чоры, 13 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Ий иман китерүчеләр! Минем дә, сезнең дә дошманыгыз булганнарны дус итмәгез. Сез аларга дусларча ачыласыз, алар исә сезгә килгән хакны** [һәм хакыйкатьне] **инкяр итәләр. Раббыгыз булган Аллаһыга ышанганыгыз өчен, алар Расүл** салләллаһу галәйһи вә сәлләмне **һәм сезне** [Мәккәдән] **куып чыгаралар. Әгәр сез Минем юлымда җиһад кылу өчен һәм ризалыгыма ирешер өчен** [мөһаҗир буларак] **чыксагыз** [дошманнарыгызны дус итүне ташлагыз]**! Сез яшерен генә аларга дуслык саклыйсыз** [ләкин Минем катымда яшерен дә, ачык та бертигез]**. Мин исә сезнең яшергән нәрсәләрегезне дә, ачып салган нәрсәләрегезне дә беләмен. Арагыздан кем дә кем болай итсә, ул инде туры юлдан язган**[1]**.**
2. **Әгәр дә алар сезнең белән очрашса, сезгә дошман булачаклар, кулларын һәм телләрен** [үтерү, әсир итү һәм мыскыл итү кебек] **начарлыклар белән сезгә сузачаклар. Алар сезнең кяфер булуыгызны телиләр.**

---

1 Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе болай дигән: Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Зөбәйр һәм Микъдад белән бергә миңа: «Туп-туры китегез. Мәдинәдән ерак булмаган бер урында Хах бакчасына барыгыз, анда үзе белән хаты булган бер хатынны очратачаксыз, аңардан ул хатны алыгыз», – диде. Без юлга чыктык. Ул бакчага барып җиткәч тә, теге хатынны очраттык һәм аңа: «Тиз генә хатны бир!» – дидек. Ул үзе белән хат булмаганын әйткәч: «Йә хатны бирәсең, йә киемеңне саласың!» – дидек. Шуннан соң ул тиз генә чәч толымнары арасыннан хатны чыгарып бирде. Без аны алып Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына кайттык. Соңыннан хатның Хатыйб бине Әбү Бәлтәга тарафыннан Мәккәдәге мөшрик кешеләргә язылганлыгын, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәне алуга бәйле кайбер серләрен аларга хәбәр иткәнен аңладык. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ий Хатыйб! Бу ни бу?» – дип сорагач, ул: «Йә Расүлуллаһ! Минем хакта ашыгып карар бирмә! Мин Корәешнең үзеннән түгелмен, ләкин синең белән бергә булган мөһаҗирләрнең Мәккәдә гаиләләрен һәм малларын саклаган туганнары бар. Мин андагы туганнарымны саклап калыр өчен: «Инде нәселдәшлегем булмагач, һичьюгы бер игелегем тисен дә, шул сәбәпле якыннарымны сакласыннар», – дип уйладым. Мин моны көферлек һәм диннән кайту нияте белән эшләмәдем. Мин Исламны кабул иткәннән соң көферлеккә һич разый түгелмен», – дип җавап бирде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янындагыларга: «Ул сезгә дөресен сөйләде», – диде. Бу хәлгә кызып киткән Гомәр радыяллаһу ганһе: «Йә Расүлуллаһ! Рөхсәт бир дә, мин шул монафикъның башын чабыйм!» – дигәч, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул Бәдердә катнашты. Син ни беләсең, Аллаһы Бәдер әһелен күрде һәм: «Теләгәнегезне кылыгыз. Һичшиксез, Мин сезне (алдан ук) ярлыкадым!» – дип әйтте», – диде. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә бу аятьләрне индерде (Бәйдави, Нәсәфи, Хазин, Алуси).

3. **Туганлык җепләре дә, балаларыгыз да** [бер зарарны китәрү һәм бер файда кылу кебек] **сезгә ярдәм итмәячәк. Кыямәт көнендә Ул сезнең арагызда аерма ясаячак. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгызны күреп тора.**
4. **Сезгә Ибраһим** [галәйһиссәламдә] **һәм аның белән бергә булганнарда яхшы үрнәк булды. Менә алар кавемнәренә әйттеләр: «Без сездән дә, Аллаһыны калдырып табынган нәрсәләрегездән дә еракбыз. Без сезне** [динегезне] **инкяр иттек. Сез Аллаһының бер генә булганына иман китергәнчегә кадәр, безнең белән сезнең арада мәңгелек дошманлык һәм нәфрәт** [барлыкка килде, бу күңелләребездә генә калмыйча, гамәлләребездә дә ныклап] **урнашты». Бары Ибраһимның** [галәйһиссәлам] **атасына: «Мин синең өчен Аллаһыдан** [киләчәк газаплардан] **бернәрсәгә дә ия булмасам да, синең өчен ярлыкау сораячакмын!» – дию булмаса гына.** [Ий мөэминнәр! Ибраһим [галәйһиссәламнең], аның янындагыларның шул сүзләреннән дә үрнәк алыгыз:] **«Ий Раббыбыз! Сиңа гына тәвәккәл кылдык һәм Сиңа гына юнәлдек. Кайту да Сиңа гына** [булачак].
5. **Ий Раббыбыз! Безне кяферләр өчен бер фетнә** [сәбәбе] **итмә.** [Аларны безнең өскә җибәрмә, безне мыскыл итә алмасыннар һәм безне җәфалый алмасыннар. Син дә безгә газап бирмә, алар ялгыш юлда була торып, үзләрен хак юлда дип санап, безнең сәбәпле фетнәгә төшмәсеннәр]. **Ий Раббыбыз! Безне ярлыка. Һичшиксез, Син – Бөек** [Җиңелмәс], **Хикмәт иясе».**
6. **Алар** [Ибраһим [галәйһиссәлам] һәм янындагылар] **сезнең өчен Аллаһыга һәм соңгы көнгә өмет иткән кешеләр өчен яхшы үрнәк булды. Кем дә кем** [Безнең әмеребездән] **йөз чөерә** [дә, кяферләр белән дус була], **һичшиксез, Аллаһы – Бай, Мактауга лаеклы.**
7. [Хәзергә сезгә Мәккә мөшрикләре белән дус булу тыелса да, тиздән] **Бәлки, Аллаһы**[аларга да иман китерергә юл ачып] **сезнең белән алардан** [ширек кушкан якыннарыгыздан] **дошманлык кылган кешеләр арасында дуслык барлыкка китерәчәк. Аллаһы– Кодрәт иясе. Аллаһы–** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле.**
8. **Аллаһы сезне дин өчен сезгә каршы сугышмаганнарга һәм сезне йортларыгыздан куып чыгармаганнарга карата игелекле булудан һәм гадел эш итүдән тыймый. Һичшиксез, Аллаһы гадел булганнарны сөя** [һәм алардан разый була].
9. **Аллаһы сезне дин өчен сезгә каршы сугышканнар, сезне йорт-**

**ларыгыздан куып чыгарганнар һәм сезне куып чыгаруда бер-берләренә ярдәм иткәннәр белән дус булуны гына тыя. Кем дә кем аларны дус итсә, алар – золым итүчеләр.**

10. **Ий иман китерүчеләр!** [Тыштан караганда] **Иман китергән** [булып күренгән] **хатыннар** [кяферләр арасыннан] **һиҗрәт иткән кешеләр буларак сезгә килгәч, сез аларны** [телләре белән күңелләренең бер-берләренә туры килү-килмәүләрен] **сынагыз. Аларның иманын Аллаһы яхшырак белә. Әгәр дә аларны иман китергән хатыннар дип белсәгез, аларны инде кяферләренә** [ирләренә] **кайтармагыз, чөнки болар да алар өчен хәләл түгел, тегеләр дә болар өчен хәләл түгел.** [Мәһәр буларак] **Сарыф иткән нәрсәләрне аларга** [ирләренә] **бирегез. Мәһәрләрен биргәч, аларга өйләнүегездә сезгә һич гөнаһ юк** [чөнки Исламга керүләре алар белән ирләре арасында киртә барлыкка китерә]**. Сез кяфер хатыннарның** [никах] **җепләрен тотмагыз** [аларны аерыгыз] **һәм** [мәһәр буларак] **сарыф иткән нәрсәләрегезне** [алар кияүгә чыгасы мөшрик ирләреннән] **сорагыз, алар да** [сезгә һиҗрәт кылган иманлы хатыннарга мәһәр буларак] **сарыф иткән нәрсәләрен** [сездән] **сорасыннар. Бу – Аллаһының хөкеме. Ул** [шушылай] **арагызда хөкем бирә. Аллаһы –** [һәрнәрсәне] **Белүче, Хикмәт иясе.**
11. **Әгәр хатыннарыгыздан берәрсе качып, кяферләргә китсә** [һәм ул кяферләр сезгә мәһәрләрегезне бирмәсәләр]**, шуннан соң сез** [сугышта аларны] **җәзаласагыз** [һәм ганимәт алсагыз]**,** [мәһәр буларак] **сарыф иткән нәрсәләре кадәрне үк** [алган ганимәтегездән] **хатыннары киткән кешеләргә бирегез. Үзегез иман китергән Аллаһыдан куркыгыз.**
12. **Ий Нәби! Иман китергән хатыннар, сиңа килеп, Аллаһыга һичбернәрсәне уртак кушмаячакларына, урлашмаячакларына, зина кылмаячакларына,** [кызларын тере килеш күмеп] **балаларын үтермәячәкләренә,** [башка берәүдән тудырган балаларын ирләренә алып килеп: «Бу синең балаң!» – дип әйтеп] **куллары белән аяклары арасында бер яла уйдырып китермәячәкләренә һәм** [Аллаһыга вә Аның пәйгамбәренә итагать мәсьәләсендә] **яхшы дип беленгән теләсә нәрсә хакында синең сүзеңнән чыкмаячакларына сиңа бәйгать иткәч, син аларның бәйгатьләрен кабул ит һәм алар өчен Аллаһыдан мәгъфирәт сора. Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһларны

күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле**[1]**.**

13. **Ий иман китерүчеләр! Аллаһы ачуланган кешеләр белән дус булмагыз.** [Үзләреннән алда үлеп, дәфен ителгән] **Кабер әһелләреннән булган кяферләр** [Ахирәтнең мәңгелек нигъмәтләреннән] **өметләрен өзгән шикелле, алар да Ахирәттән өмет өзделәр**[2]**.**

1 Риваять ителгәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәне алган көнне ир-атның бәйгатен кабул итеп бетергәннән соң, хатын-кыздан бәйгать ала башлаган. Бу вакытта ул Сафа калкулыгында торган, Гомәр радыяллаһу ганһе исә бераз астарак утырган, аның әмере белән Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм исеменнән аларга динне тәблигъ кылып торган һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм тарафыннан аларның бәйгатен кабул иткән. Әбү Суфьянның хатыны Һинд радыяллаһу ганһүмә, хәзрәти Хәмзәгә кылган явызлыклары сәбәпле, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм танымасын өчен, каплаулы кыяфәттә хатын-кыз арасында булган. Иң башта «ширек кушмау» шарты куелганнан соң «урламау» шарты телгә алынгач, ул: «Әбү Суфьян – бик саран кеше. Мин аның малыннан бер әйбер алган идем, бу миңа гафу ителерме?» – дип әйткән. Шулвакыт Әбү Суфьян: «Элек алганнарың сиңа хәләл булсын!» – дигән. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны танып елмая башлагач, ул: «Ий Аллаһының пәйгамбәре! Элеккене гафу ит!» – дигән. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә: «Аллаһы сине гафу итсен!» – дигән. «Зина кылмау» шарты белдерелгәч, ул: «Хөр хатын да зина кыламыни?» – дип гаҗәпләнүен белдергән. «Яла якмау» шарты әйтелгәч, ул: «Аллаһы белән ант итәмен, яла ягу – бик яман эш, син безгә игелек һәм күркәм әхлак кына әмер итәсең», – дип әйткән. Иң ахырдан «яхшы дип беленгән нәрсәләрдә пәйгамбәргә каршы килмәү» шарты әйтелгәч: «Валлаһи, без бу мәҗлескә нинди дә булса мәсьәләдә сиңа каршы төшү фикере белән утырмадык», – дигән (Нәсәфи, Алуси).

2 Кайбер фәкыйрь мөселманнарның җимешләреннән һәм игеннәреннән файдалану өчен, яһүдиләр белән дус булуларына карата бу аяте кәримә иңгән (Алуси).

# 61. Әс-Сафф (Саф) сүрәсе

Мәдинә чоры, 14 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Күкләрдә булганнар һәм җирдә булганнар Аллаһыны** [барлык кимчелекләрдән ерак тотып] **тәсбих итә. Ул – Бөек** [Җиңелмәс], **Хикмәт иясе.**
2. **Ий иман китерүчеләр! Ни өчен эшләмәячәк нәрсәләрегезне сөйлисез?**
3. **Эшләмәячәк нәрсәләрне сөйләвегезгә Аллаһының ачуы** [һәм нәфрәте] **бик зур.**
4. **Һичшиксез, Аллаһы Аның юлында коеп куйган бина кебек тыгыз саф тотып сугышучыларны сөя.**
5. **Муса** [галәйһиссәлам] **кавеменә: «Ий кавемем! Ни өчен сез мине рәнҗетәсез? Сез бит минем Аллаһының сезгә** [җибәргән] **илчесе икәнемне беләсез!» – дигән иде. Әмма алар** [хактан] **тайпылгач, Аллаһы да аларның йөрәкләрен** [хактан] **авыштырды. Аллаһы** [теләгән һәм көчен һидаять юнәлешендә сарыф итмичә, әмереннән чыккан] **фасикъ кешеләрне** [туры юлны табуга] **һидаять итми.**
6. **Мәрьям улы Гайсә** [галәйһиссәлам] пәйгамбәр итеп җибәрелгән яһүдиләргә мөрәҗәгать итеп]**: «Ий Исраил уллары! Мин – үземнән алдагы Тәүратны дөресләүче һәм миннән соң киләчәк Әхмәд исемле бер расүл турында сөенечле хәбәр китерүче, Аллаһының сезгә җибәргән илчесемен», – дигән иде. Ләкин ул аларга ап-ачык могҗизалар белән килгәч: «Бу бит – ап-ачык сихер!» – дигәннәр иде.** [Гайсә [галәйһиссәламгә] ышанмаган яһүдиләрнең ул хәбәр иткән ахыр заман пәйгамбәренә ышануларын ничек өмет итеп була?]
7. **Исламга дәгъват ителгән хәлендә** [Аллаһы җибәргән пәйгамбәргә – «ялганчы», аятьләренә «сихер» дип] **Аллаһыга карата ялган уйдырган кешедән дә залимрәк кем бар? Аллаһы залим кешеләрне һидаять итми.**
8. **Алар Аллаһының** [Китап иңдереп балкыткан] **нурын авызлары** [эченнән чыккан ширек һәм инкяр тулы сүзләре] **белән сүндермәкче булалар. Хәлбуки, кяферләргә ошамаса да, Аллаһы** [тәүхидне күтәреп, Исламны изге кылу белән] **нурын тәмамлаячак.**
9. **Ул – мөшрикләргә ошамаса да, диннәрнең барысыннан да**

**өстенрәк итәр өчен, Расүлен** салләллаһу галәйһи вә сәлләм **һидаять** [булган Коръән] **һәм хак дин** [булган Ислам] **белән җибәрүче.**

10. **Ий иман китерүчеләр! Сезне тилмерткеч газаптан коткарачак сәүдәне сезгә күрсәтимме?**
11. **Аллаһыга һәм Аның расүле** салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә **иман китерегез, малларыгыз һәм җаннарыгыз белән Аллаһы юлында җиһадта булыгыз. Бу – сезнең өчен** [һәрнәрсәдән] **яхшырак. Әгәр сез** [никадәр файдалы булганын] **белсәгез иде** [иманны һәм җиһадны өстен куяр идегез]**.**
12. [Әгәр дә болай итсәгез] **Ул сезнең гөнаһларыгызны ярлыкар һәм сезне** [сарайлары һәм агачлары] **асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә һәм Гаден җәннәтләрендә булган күркәм торакларга кертер. Бу – бөек котылу.**
13. **Әле сез яраткан башка** [нәрсә] **– Аллаһыдан ярдәм һәм якын җиңү** [булыр]**.** [Ий Расүлем!] **Мөэминнәрне** [ике җиһан бәхете белән] **сөендер!**
14. **Ий иман китерүчеләр! Аллаһының** [дине] **ярдәмчеләре булыгыз. Мәрьям** [радыяллаһу ганһә] **улы Гайсә** [галәйһиссәлам] иң якын кешеләре булган] **хәвариларына: «Аллаһыга** [юнәлүчеләр буларак минем] **ярдәмчеләрем кем** [булачак]**?** [Аллаһыга ярдәм Аның пәйгамбәренә ярдәм белән була]**», – дигән иде. Хәварилар: «Без – Аллаһының ярдәмчеләре!» – диделәр. Исраил улларыннан бер таифә** [Гайсәгә [галәйһиссәлам] **ышанды, башка фирка инкяр итте. Без иман китергәннәрне дошманнарына каршы куәтләндердек, һәм алар җиңүчеләр булдылар.**

# Нәсыйхәт

# Гөнаһлардан үкенеп, Аллаһы Тәгаләгә кайту бүлеге

Әбү Ләйс Әс-Сәмәрканди рахмәтуллаһи галәйһи үзенең иснәде белән Габдулла бине Гобәйд бине Гамир радыяллаһу ганһедән риваять итә. Ул болай дип әйткән: «Адәм галәйһиссәлам: «Әй, Раббым, дөреслектә, Син миңа Иблисне солтан кылдың. Ул Иблистән тыелырга көчем җитмәде», – дип әйткән. Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән: «Синең балаң туса, ул балага Иблиснең мәкереннән һәм явыз иптәшләрдән саклаучыны вәкил кылырмын». Адәм галәйһиссәлам: «Әй, Раббым, минем изгелекләремне арттыр», – дип әйткән. Аллаһы Тәгалә: «Изгелекне ун өлешкә арттырырмын, явызлыкны бер белән санармын һәм ул явызлыкны бетерермен», – дигән. Адәм галәйһиссәлам: «Йә, Раббым, миңа тәүбә кылуны арттыр», – дигән. Аллаһы Тәгалә: «Тәндә җаның булган кадәр сиңа тәүбә кылуны һәм аны кабул итүне арттырырмын», – дигән.

Аннан соң Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

۞ قُلْ يَا عِبَادِيَ الَّذِينَ أَسْرَفُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ ﴿٥٣﴾

**«Әйт: «Ий үз-үзләренә каршы зарарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы [ширектән тыш] барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

Факыйһ (ягъни, Әбү Ләйс Әс-Сәмәрканди) рахмәтуллаһи галәйһи болай дип әйткән: «Миңа үзенең иснәде белән, Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять итеп, ышанычлы бер кеше сөйләде. Дөреслектә, Вәхши Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы ягыннан бертуган

абыйсы Хәмзәне үтерүче иде. Ул Мәккәдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мондый хат язды: «Дөреслектә, мин мөселман булырга телим. Ләкин мине Исламны кабул итүдән Коръәннән сиңа иңгән бер аять тыя. Ул аять Аллаһы Тәгаләнең сүзедер:

وَالَّذِينَ لَا يَدْعُونَ مَعَ اللَّهِ إِلَٰهًا آخَرَ وَلَا يَقْتُلُونَ النَّفْسَ الَّتِي حَرَّمَ اللَّهُ إِلَّا بِالْحَقِّ وَلَا يَزْنُونَ ۚ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ يَلْقَ أَثَامًا ﴿٦٨﴾

**«Янә алар Аллаһы белән беррәттән башка илаһка табынмыйлар [үтергән бер кеше өчен кыйсас, Исламга кергәннән соң диннән чыгу һәм өйләнгән килеш зина кылу кебек] хак белән булмыйча, Аллаһы тыйган җанны үтермиләр, зина да кылмыйлар. Кем дә кем боларны кылса, [гөнаһының] җәзасын алачак».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:68

Бу кеше: «Дөреслектә, мин бу өч нәрсәне кылдым, миңа тәүбә бармы?» – дип сорады. Моннан соң Аллаһы Тәгалә әлеге аятьне иңдерде:

إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُولَٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٧٠﴾

**«Тик [көферлектән] тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның [тәүбәләре сәбәпле сөртелгән] начарлыкларын Аллаһы күркәм нәрсәләр белән алмаштырачак. Аллаһы Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:70

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу аятьне Вәхшигә язды. Вәхши Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә яңадан язды: «Дөреслектә, аятьтә бер шарт бар, ул шарт – изге гамәлдер. Минем изге гамәлгә көчем җитәрме яки юкмы икәнен белмим». Шуннан соң Аллаһы

Тәгаләнең аяте инде:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَغْفِرُ أَن يُشْرَكَ بِهِ وَيَغْفِرُ مَا دُونَ ذَٰلِكَ لِمَن يَشَاءُ ۚ

**«Һичшиксез, Аллаһы Үзенә ширек кушылуын ярлыкамый. Моңардан тыш булганны исә Үзе теләгән кешегә ярлыкар».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:48

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу аятьне дә Вәхшигә язды. Вәхши янә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә язды: «Дөреслектә, бу аятьтә янә бер шарт бар. Аллаһы Тәгалә мине ярлыкарга теләрме яисә юкмы икәнен белмим». Моннан соң Аллаһы Тәгаләнең сүзе инде:

۞ قُلْ يَا عِبَادِيَ الَّذِينَ أَسْرَفُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ ﴿٥٣﴾

**«Әйт: «Ий үз-үзләренә каршы зарарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы [ширектән тыш] барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Вәхшигә бу аятьне язды һәм Вәхши бу аятьтә шарт тапмады, Мәдинәгә килеп Исламны кабул итте».

Факыйһ рахмәтуллаһи галәйһи үзенең иснәде белән Мөхәммәд бине Габдрахман Сәлмидән, ул атасыннан риваять итә. Атасы болай дип әйткән: «Мәдинәдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләренең кайберләре белән утырдым. Аларның берсе болай дип әйтте: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеттем, ул: «Бер кеше үлеме җиткәнче тәүбә кылса, Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен

кабул итәр», – диде. Икенче сәхабә болай дип әйтте: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеттем. Ул: «Берәү үлеменә бер сәгать кала тәүбә итсә, Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул итәр», – диде. Икенче берәү болай дип әйтте: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеттем. Ул: «Берәү җаны чыкканга кадәр тәүбә кылса, Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул итәр», – диде.

Факыйһ үзенең иснәде белән Мөхәммәд бине Мотрафтан риваять итә. Ул болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Гөнаһ кыла торган адәм баласының хәле гаҗәеп, ул Минем гафу итүемне теләсә, аны ярлыкармын. Ул кешегә ни гаҗәп хәл, ул гөнаһысын да ташламый һәм Минем рәхмәтемнән өметен дә өзми. Әй, фәрештәләр, сезне шаһит итәм, дөреслектә, Мин рәхмәтемнән өмет өзмәгән бәндәмне ярлыкадым».

Факыйһ рахмәтуллаһи галәйһи үзенең иснәде белән Мөгаес бине Сәмидән риваять итә. Ул болай дип әйткән: «Сездән элек булган кешеләр арасында гөнаһларны кылучы бер ир бар иде. Бер көнне ул кылган гөнаһлары хакында уйлады, исенә төшерде һәм өч мәртәбә: «Әй, Аллаһым, ярлыкавыңны телим», – диде. Аңа бу хәлдә үлем иреште, Аллаһы Тәгалә аны ярлыкады».

Мөхәммәд бине Гаҗлән Мәкхуләдән риваять итә. Мәкхулә болай дип әйткән: «Миңа болай дип иреште, дөреслектә, Ибраһим галәйһиссәлам күкләр милкенә ашкан вакытта зина кыла торган колны күрде һәм аңа бәддога кылды, аны Аллаһы Тәгалә һәлак итте. Моннан соң урлый торган колны күрде, аңа да бәддога кылды, аны да Аллаһы Тәгалә һәлак итте. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй, Ибраһим, Минем бәндәләремне калдыр, дөреслектә, Минем колым өч сыйфат һәм тәүбә кылу арасындадыр, аның тәүбәсен кабул кылырмын. Дәхи үзе өчен балалар һәм оныклар чыгару арасындадыр. Алар, ягъни бәндәмнең балалары Миңа гыйбадәт кылыр. Аның явызлыгы җиңү арасында һәм аның артында җәһәннәмдер».

Факыйһ рахмәтуллаһи галәйһи болай дип әйткән: «Әгәр берәү тәүбә кылса, бу хәбәр Аллаһы Тәгаләнең кабул итүенә дәлилдер. Бәндә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметен өзәргә тиеш түгел. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّهُ لَا يَيْأَسُ مِن رَّوْحِ اللَّهِ إِلَّا الْقَوْمُ الْكَافِرُونَ ﴿٨٧﴾

**«Аллаһының рәхмәтеннән өметне өзмәгез. Һичшиксез, [Раббыларының чиксез нигъмәтләрен инкяр иткән] кяферләр кавеме генә Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзә».**

«Йосыф», 12:87

Икенче аятьтә болай дип әйтә:

وَهُوَ الَّذِي يَقْبَلُ التَّوْبَةَ عَنْ عِبَادِهِ وَيَعْفُو عَنِ السَّيِّئَاتِ

**«Ул [Үзе теләгән] колларыннан тәүбәне кабул итә, [кылган] начар нәрсәләрен гафу итә».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:25

Акыллы кешегә һәрвакыт Аллаһыга тәүбә кылу, үзен гөнаһлы гамәлләрдән саклау тиешле буладыр, чөнки Аллаһыга тәүбә кылган, ә аннары гөнаһысына кайткан кеше, гәрчә бер көндә җитмеш мәртәбә ул гөнаһысына кайтса да, ул гөнаһысын кылуны дәвам итмәс.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһыдан ярлыкауны сораучы кеше, көненә җитмеш мәртәбә гөнаһысына кайтса да, гөнаһысында даимчылык кылмады».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителде. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Дөреслектә, мин Аллаһы Тәгаләгә көненә йөз мәртәбә тәүбә кылам».

Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Әгәр Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән нәрсәне дә булса ишетсәм, Аллаһы Тәгалә Үзе теләгәнчә, аны минем өчен файдалы кыла торган булды. Әгәр башка кеше Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзен миңа сөйләсә, аны ант иттерә идем. Әгәр ант итсә, аның сүзен дөрес дип ала идем. Миңа Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе сөйләде: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Гөнаһ кылмый торган кол булмас. Әгәр ул күркәм рәвештә тәһарәт алып, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһыдан ярлыкауны сораса, Аллаһы Тәгалә аны ярлыкар. Моннан соң бу аятьне укыды:

وَمَن يَعْمَلْ سُوءًا أَوْ يَظْلِمْ نَفْسَهُ ثُمَّ يَسْتَغْفِرِ اللَّهَ يَجِدِ اللَّهَ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿١١٠﴾

**«Кем дә кем [башка берәүгә карата] начарлык эшләп яки [үзе белән бәйле бер-бер гөнаһ кылып] үз-үзенә золым итеп, соңыннан Аллаһыдан ярлыкау сораса, Аллаһыны [гөнаһларны] Гафу итүче, [тәүбә итүчеләргә карата бик] Рәхимле дип табар».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:110

Икенче риваятьтә Пәйгамбәребез әлеге аятьне укыган:

وَالَّذِينَ إِذَا فَعَلُوا فَاحِشَةً أَوْ ظَلَمُوا أَنفُسَهُمْ ذَكَرُوا اللَّهَ فَاسْتَغْفَرُوا لِذُنُوبِهِمْ
وَمَن يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا اللَّهُ وَلَمْ يُصِرُّوا عَلَىٰ مَا فَعَلُوا وَهُمْ يَعْلَمُونَ ﴿١٣٥﴾
أُولَٰئِكَ جَزَاؤُهُم مَّغْفِرَةٌ مِّن رَّبِّهِمْ وَجَنَّاتٌ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ
فِيهَا ۚ وَنِعْمَ أَجْرُ الْعَامِلِينَ ﴿١٣٦﴾

**«Янә алар [тәкъвалык ияләре, зур гөнаһлар кылып] бик кабахәт бернәрсә эшләсә яки [кечерәк гөнаһ кылып] үзләренә золым китерсә, Аллаһыны искә төшерәләр дә, [шунда ук үкенә-үкенә тәүбә итеп] гөнаһлары өчен ярлыкау сорыйлар. Гөнаһларны исә Аллаһыдан башка кем гафу итә? Һәм алар белә торып гөнаһларын кабатлауда үҗәтлек күрсәтмиләр. [Расүлем!] Әнә шуларның әҗерләре – Раббыларыннан [киләчәк] мәгъфирәт һәм алар мәңге калачак [сарайлары вә агачлары] асларыннан елгалар аккан җәннәтләр [булыр]. [Болай] Гамәл кылучыларның савабы нинди яхшы!»**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:135-136

Хәсән Әл-Басри радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять иткән. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: Аллаһы Тәгалә Иблисне җиргә сөргән вакытта Иблис әйтте: «Гыйззәтең һәм олуглыгың белән ант итәм, дөреслектә, Адәм улының җаны тәненнән аерылганга кадәр аны дөрес юлдан тайпылдырудан туктамам». Аллаһы Тәгалә аңа болай дип әйтте: «Үземнең гыйззәтем һәм олуглыгым белән ант итәм, бәндәмнән җаны бугазына килгәнгә кадәр тәүбәне пәрдәләмим».

Әбү Касыйм Әбү Үмәмәдән риваять иткән. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Уң як фәрештәсе сул як фәрештәсенә сакчыдыр. Әгәр бәндә изгелекне кылса, аның өчен уң як фәрештәсе ун итеп язар. Бәндә явызлык кылса, ул начарлыкны сул як фәрештәсе язарга теләсә, уң як фәрештәсе «тукта», дип әйтер. Ул фәрештә алты яки җиде сәгать язмыйча торыр. Әгәр бәндә Аллаһыдан ярлыкауны сораса, сул як фәрештәсе ул бәндәгә һичнәрсә язмас. Әгәр ярлыкауны сорамаса, аның өчен бер явызлыкны язар».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гөнаһысыннан тәүбә кылучы – гөнаһысы булмаган кеше кебектер», – дип әйткән.

Икенче риваятьтә болай дип китерелгән: дөреслектә, бәндәгә гөнаһ, хәтта икенче гөнаһ кылганчыга кадәр язылмыйча торыр. Моннан соң икенче гөнаһны кылса, аның өчен янә икенче гөнаһны кылганчыга кадәр язылмас. Әгәр гөнаһлары бишкә җыелса һәм ул бер изгелек кылса, аңа биш явызлык өчен биш изгелек язылыр. Бу вакытта Иблис (аңа ләгънәт булсын) кычкырыр һәм: «Кешегә ничек көчем җитсен, мин аның зарарына тырышсам да, бер изгелек белән барча тырышлыгымны юкка чыгара», – дип әйтер.

Сафуан бине Гассәл Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мәгъриб тарафыннан ишек булыр. Аллаһы Тәгалә аны тәүбә өчен яратты. Аның киңлеге җитмеш яки кырык ел йөрерлек урындыр. Һәрвакыт ачылган хәлдә булыр, хәтта кояш үзенең бата торган урыныннан туганчыга кадәр ул ишек бикләнмәс».

Сәгыйд бине Мөсәййәбтән риваять ителә. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә гөнаһ кылып тәүбә иткән һәм янә гөнаһ кылып тәүбә иткән кешеләргә ярлыкаучы булды. Сәгыйд бине Мөсәййәб болай дип әйткән: «Әүвәб – ул гөнаһ кылганнан соң тәүбә иткән һәм моннан соң янә гөнаһ кылып, янә тәүбә иткән кешедер».

Хәсән Әл-Басри радыяллаһу ганһедән: «Бу кайчанга кадәр?» – дип соралган. Хәсән Әл-Басри радыяллаһу ганһе: «Моны белмим, бары мөэминнәрнең әхлагыннан гына беленер», – дип җавап биргән.

Хакимнәрнең кайберләре болай дип әйттеләр: «Гарифнең (Аллаһыны танучы кешенең) һөнәре алты нәрсәдер: әгәр Аллаһыны зикер итсә – мактала, үзен искә төшерсә – хурлана, Аллаһының аятенә караса – фикерли, гөнаһны яки нәфес теләгән максат итсә – тыела, әгәр Аллаһының гафу итүен зикер итсә – шатлана, үзенең гөнаһларын искә төшерсә – ярлыкауны сорый».

Факыйһ рахмәтуллаһи галәйһи иснәде белән Зөһри радыяллаһу ганһедән риваять итә. Ул радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына елаган хәлдә керде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Әй, Гомәр, сине нәрсә елатты?» – дип сорады. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әй, Расүлуллаһ, капкада бер егет бар, дөреслектә, минем йөрәгемне яндырды, ул егет елый», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Әй, Гомәр, аны миңа керт», – диде. Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе аны чакырды, ул егет елаган хәлдә керде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул егеттән: «Сине нәрсә елатты?» – дип сорады. Егет: «Әй, Расүлуллаһ, мине күп гөнаһ елатты, минем өчен булган ачулы җәбердән курыктым», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләгә ширек кылдыңмы?» – дип сорады. Егет: «Юк», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хаксыз кешене үтердеңме?» – дип сорады. Егет: «Юк», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул гөнаһың җиде күкләр һәм җиде җирләр, беркетелгән таулар кебек булса да, Аллаһы Тәгалә синең гөнаһыңны ярлыкый», – диде. Егет: «Әй, Расүлуллаһ, минем гөнаһым җиде күкләрдән һәм җиде җирләрдән дә, беркетелгән таулардан да олуграк», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гөнаһың олугракмы яки Көрсиме?» – дип сорады. Егет: «Гөнаһым олуграк», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гөнаһың олугракмы яки Гарешме?» – дип сорады. Егет: «Гөнаһым олуграк», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гөнаһың олугракмы яки Аллаһыңмы, ягъни Аллаһының гафу итүеме?» – дип сорады. Егет: «Аллаһы Тәгалә олуграк һәм зуррактыр», – дип җавап бирде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, андый олуг гөнаһны бары тик олуг Аллаһы гына ярлыкый. Гөнаһыңнан миңа хәбәр бир», – диде. Егет аңа: «Йә, Аллаһының Расүле, дөреслектә, мин синнән ояламын», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу

галәйһи вә сәлләм: «Гөнаһыңнан миңа хәбәр бир», – диде. Егет болай дип әйтте: «Әй, Расүлуллаһ, мин кәфен җыюны сөюче ир булдым, җиде елдан бирле каберләрне ачып, кәфен ала идем. Бер көнне Мәдинә сәхабәләренең кызларыннан берәү үлде. Мин аның каберен ачтым, аны кәфеннән чыгардым. Ерак та китмәдем шул вакытта мине шәйтан җиңде, кире кайтып ул кәнизәк[1] белән якынлык кылдым. Ерак китмәгән идем, шулвакыт кыз торып болай дип әйтте: «Әй, егет, сиңа ни үкенеч, җәза көнендә җәза торгызылачак, ягъни үч алучыдан оялмыйсыңмы? Золым кылынучы залимнең хакын алыр. Үлекләр гаскәрендә мине ялангач калдырдың, Аллаһы Тәгалә каршында мине җөнеб кылдың». Бу егетне тыңлап бетергәннән соң, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сикереп торып, аның җилкәсенә сукты һәм: «Әй бозык! Утка, тәмугка синнән кирәклерәк юк, минем янымнан чык», – дип әйтте. Егет Аллаһы Тәгаләгә кырык кич дәвамында гөнаһысы өчен тәүбә кылды. Кырык кич тәмам булгач, башын күтәреп күккә карады һәм: «Әй, Мөхәммәд, Адәм һәм Хавваның Илаһы, әгәр мине ярлыкаган булсаң, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның сәхабәләренә белдер. Әгәр гафу итмәгән булсаң, күктән ут җибәр, ул ут мине яндырсын, Ахирәт газабыннан мине коткар», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килеп: «Әй, Мөхәммәд, Раббың сиңа сәлам укый», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Үзе Сәлам, Аннан сәлам һәм Аңа сәлам кайтыр», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтә: «Халыкны син яраттыңмы?» Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бәлки халыкны ератучы Зат мине һәм аларны да Ератучы Заттыр», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Аларны син ризыкландырасыңмы?» Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Юк, бәлки аларны һәм мине Аллаһы Тәгалә ризыкландырадыр», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Аллаһы

[1] Кол.

Тәгалә әйтте: «Аларның тәүбәсен син кабул итәсеңме?» Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Юк, бәлки минем һәм аларның тәүбәсен Аллаһы Тәгалә кабул итә», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Бәндәмнең тәүбәсен кабул ит, дөреслектә, Мин аның тәүбәсен кабул иттем». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм егетне чакырды һәм Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул итте дип, аны сөендерде.

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Акыллы кеше бу хәбәрне игътибарга алырга һәм шуны аңларга тиеш: гөнаһ йөзеннән терек кеше белән зина кылу үлек кеше белән зина кылудан олуграк. Кешегә чын тәүбә белән тәүбә кылу тиешле. Югарыда хәбәр ителгән егетнең тәүбәсе чын икәнен белгәч, Аллаһы Тәгалә аны кичерде».

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Аллаһы Тәгаләнең:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللَّهِ تَوْبَةً نَّصُوحًا

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга ихлас бер тәүбә белән тәүбә итегез»,**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:8

– дигән аятен укыганнан соң болай дип әйтте:«Чын тәүбә – ул күңел белән үкенү, тел белән ярлыкауны теләү һәм ул гөнаһка мәңге кайтмауны күңелгә ирештерүдер».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителә. Дөреслектә, ул салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Тел белән генә ярлыкауны теләүче һәм аннары гөнаһларга кайтучы Аллаһыны хурлаучы кебектер».

Хәзрәти Рабига радыяллаһу ганһедән хәбәр ителә. Дөреслектә, ул әйтә торган булган: «Дөреслектә, без Аллаһының ярлыкавын телибез. Кеше тел белән ярлыкауны сораганда, нияте гөнаһка кайту булса, дөреслектә, ул алдаучыларның тәүбәседер һәм бу чын тәүбә булмый. Тәүбә – ул тел

белән ярлыкауны кабатлау, ярлыкауны күңелдән теләү һәм беркайчан да гөнаһка кайтмауны ният итүдер. Әгәр кеше шулай тәүбә кылса, гөнаһысы зур булса да, Аллаһы Тәгалә аның гөнаһысын ярлыкар, чөнки Аллаһы Тәгалә гафу иясе, Үз бәндәләренә рәхмәт итүчедер».

Дөреслектә, Исраил угыллары арасында бер патша бар иде, дип хәбәр ителде. Ул патшага коллары арасында күркәм сөйләмле берәү бар дип бәян ителде. Патша бу колның килеп-китеп йөрүен һәм аның капкасында һәрдаим булуын теләде. Кол аңа: «Әй, патша, син әйткән нәрсәне хуш һәм күркәм күрдек. Шулай да, мин синең йортыңа керсәм, син мине кәнизәгең белән уйнаган хәлдә тапсаң, ягъни күрсәң, нәрсә кылыр идең?» – диде. Патша ачуланды һәм: «Әй фәҗир![1] Ничек миңа мондый сүзләр әйтә аласың?» – диде. Кол аңа болай дип әйтте: «Дөреслектә, минем юмарт Раббым бар, көнендә минем җитмеш гөнаһымны күрсә дә, миңа ачуланмас, Үзенең капкасыннан кумас, ризыгыннан мине мәхрүм кылмас иде. Ничек мин Аның ишегеннән аерылыйм? Һәм ничек, аңа гөнаһ кылмыйча да, беренче булып миңа ачулана торган кешенең капкасында даими булыйм? Әгәр мин гөнаһ кылсам, нәрсә эшләрсең?» – диде. Моннан соң бу кол патша яныннан китте.

Факыйһ рахмәтуллаһи галәйһи болай дип әйткән: «Гөнаһ ике төрледер: берсе – синең белән Аллаһы Тәгалә арасындагы гөнаһ, икенчесе – синең белән бәндәләр арасындагы гөнаһтыр. Синең белән Аллаһы Тәгалә арасында булган гөнаһның тәүбәсе – тел белән ярлыкауны теләү, күңел белән үкенү һәм аңа яңадан әйләнеп кайтмау. Бары фарызларыннан берәр нәрсәне калдырып, калган нәрсәләренә каза кылмый торып, аңа тәүбәсе файда итмәс. Моннан соң үкенер һәм ярлыкауны теләр. Әмма синең белән бәндәләр арасында булган гөнаһка тәүбә, ул кешеләрне разый кылганчыга кадәр, сиңа файда бирмәс, алар

[1] Гөнаһлы.

сине кичерсәләр генә тәүбә файда бирер».

Табигыйннәрнең берсеннән риваять ителде. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Дөреслектә, гөнаһ кылучы гөнаһ кылып, җәннәткә кергәнчегә кадәр даими рәвештә үкенүче һәм ярлыкауны теләүче булса, шәйтан: «Әй, аны бу гөнаһка кертмәгән булса идем», – дип үкенер.

Әбү Бәкер Әл-Вәситыйдан зикер ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Һәрнәрсәне соңга калдыру күркәмдер, бары өч нәрсәдә генә күркәм булмас: намаз вакытында, мәетне күмгәндә һәм гөнаһ кылган вакытта тәүбә кылуда».

Хакимнәрнең берсе болай дип әйткән: «Ирнең тәүбәсе дүрт нәрсәдә генә беленә: беренчесе – телне артык сүздән, гайбәттән, ялганнан тоту, икенчесе – һичберәү өчен күңелендә көнчелек һәм дошманлык күрмәү, өченчесе – явыз иптәшләреннән аерылу, дүртенчесе – үлемгә үкенүче булган, гөнаһларның үткәненә ярлыкауны теләгән һәм Аллаһы Тәгаләнең тәгатендә тырышкан хәлдә әзер булу».

Кайбер хакимнәрдән: «Тәүбә кылучының тәүбәсе кабул ителгәнлеге беленә торган галәмәт булырмы?» – дип соралды. Алар болай дип әйткән: «Әйе, бар. Тәүбәнең кабул булуының галәмәте дүрт нәрсәдер: беренчесе – явыз иптәшләрдән аерылу һәм изгеләргә катнашу, икенчесе – гөнаһтан киселү һәм итагатькә юнәлү, өченчесе – күңеленнән дөнья шатлыкларының барчасы китү, Ахирәтнең кайгысын һәрвакыт калебенә күрсәтү, дүртенчесе – нәфес теләкләрен күрә алмау. Әгәр анда бу галәмәтләр табылса, ул Аллаһы Тәгалә алар хакында әйткән кешеләр җөмләсеннәндер.

Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә тәүбә итүчеләрне һәм пакьләнүчеләрне сөя. Ул бәндәгә кешеләр хозурында дүрт нәрсә вәҗиб булды: беренчесе – ул бәндәне сөярләр, чөнки, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә аны сөйде, икенчесе – Аллаһы Тәгалә аны тәүбәгә нык кылу өчен аны дога белән саклау, өченчесе – гөнаһларыннан үткән нәрсә белән бәндәне гаепләмәү,

дүртенчесе – ул бәндәгә утырдаш булу һәм аның белән сөйләшү, аңа ярдәм итү.

Аллаһы Тәгалә ул бәндәне дүрт дәрәҗә белән хөрмәтләр. Беренчесе, Аллаһы Тәгаләнең аны, гүя гөнаһны һич кылмаган кебек, гөнаһлардан чыгаруы. Икенчесе, Аллаһы Тәгаләнең аны сөюе. Өченчесе, аның өчен шәйтанны солтан кылмавы һәм ул шәйтаннан саклавы. Дүртенчесе, аны дөньядан киткәнче куркынычтан имин кылуы, чөнки Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

تَتَنَزَّلُ عَلَيْهِمُ الْمَلَائِكَةُ أَلَّا تَخَافُوا وَلَا تَحْزَنُوا وَأَبْشِرُوا بِالْجَنَّةِ الَّتِي كُنتُمْ تُوعَدُونَ ﴿٣٠﴾

**«...ныклык күрсәтүчеләргә фәрештәләр [дөньяда һәм Ахирәттә юлыккан һәр кыенлыкларда, бигрәк тә курку һәм борчылуга бирелгән чакларында, үлем сәгатендә, кабердә һәм терелү вакытында] иңәләр: «[Киләчәгегез белән бәйле бернидән дә] Курыкмагыз һәм [артыгызда калдырганнарыгыз өчен] борчылмагыз, сезгә [пәйгамбәрләр аша дөньяда] вәгъдә ителгән җәннәткә сөенегез».**

«Фуссыйләт / Аңлатылды», 41:30

Халид бине Мәгъдәннән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Әгәр тәүбә кылучылар җәннәткә керсәләр: «Әй, безнең Раббыбыз, җәннәткә кергәнчегә кадәр тәмугка килүебезне вәгъдә кылган идең түгелме?» – дип әйтерләр. Аларга: «Дөреслектә, сез ул тәмугны үттегез, хәзер сөенегез», – дип әйтелер.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителде. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Әгәр бер кеше икенче берәүне фәхешлектә гаепләсә, ягъни сүксә, ул гаепләгән бәндә шул фәхешлекне кылучы кебектер. Әгәр бер кеше берәүне гөнаһ кылуда гаепләсә, ул

гөнаһны үзе кылганчы һәм шул гөнаһ сәбәпле рисвай[1] булганчы дөньядан китмәс».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Дөреслектә, мөэмин гөнаһка төшүне теләми һәм гөнаһ кылуны максат та итми, чөнки Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَكَرَّهَ إِلَيْكُمُ الْكُفْرَ وَالْفُسُوقَ وَالْعِصْيَانَ ۚ

**«Аллаһы сезгә [ялганчыны куәтләү, гаепсезгә ташлануны хуплау һәм хакны үз карашларынча уйдыру кебек начар хәлләрне яраттырмады] иманны яраттырды, күңелләрегездә сезгә аны бизәде, көферлекне, фасикълыкны [ялганчылыкны] һәм гөнаһларны сезгә яман итеп күрсәтте».**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:7

Аллаһы Тәгалә хәбәр бирде. Дөреслектә, мөэминнәргә гөнаһ дошман кылынды. Мөэмин кеше ул гөнаһны максат итмәс, шулай да наданлык хәлендә мөэмин гөнаһка төшәр. Әгәр ул мөэмин тәүбә кылса, аны гөнаһысы сәбәпле гаепләү дөрес булмас.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Әгәр бәндә тәүбә кылса, Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул итәр. Сакчы фәрештәләрнең яза торган нәрсәләрен оныттырыр, аның гамәленең явызларын, хата эшләрдән кылган нәрсәсен, әгъзаларын да оныттырыр. Җирдә һәм күктә булган гөнаһ кылган урыныннан, Кыямәт көнендә бу гөнаһка шәһадәт бирүче бер мәхлүкъ та булмас».

Хәзрәт Гали аркылы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Гареш тирәсендә мәхлүкълар яратылмастан дүрт мең ел элек болай дип язылган:

[1] Хур булганчы.

وَإِنِّي لَغَفَّارٌ لِّمَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا ثُمَّ اهْتَدَىٰ ﴿٨٢﴾

**«Һичшиксез, Мин тәүбә иткән, иман китергән, изге гамәл кылган, шуннан соң һидаятьтә нык торганнарны, әлбәттә, гафу итүчемен».**

«Та Һа», 20:82

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан*

# Коръәндә үләннәрнең шифалы үзенчәлекләре турында ниләр әйтелгән?

Янәшәбездә генә үсеп яткан үләннәрнең күптөрлелеге һәм бу күптөрлелекнең сәбәбе турында кайчан да булса уйлап караганыбыз бармы? Төссез кара туфрактан төрле төстәге, бер-берсенә охшамаган, әле шундый хуш исле чәчәкләрнең ничек үсеп чыкканлыгы турында?! Менә – аклы-сарылы ромашкалар, ә менә – сирень куагы, зәңгәр һиндыба (цикорий) чәчәге, ә янәшәсендә генә – сары һәм мамыктай йомшак тузганаклар! Еллар һәм гасырлар үтү белән әлеге үсемлекләр үз төсләрен, рәвешләрен һәм чәчәк ату вакытларын үзгәртми. Бу исә – бу үсемлекләрдә үзләренә генә хас генетик кодлар барлыгына бер ишарәт. Шул ук нәрсәне хайваннар, кошлар, балыклар һәм бөҗәкләр дөньясында да күзәтергә мөмкин. Бака уылдыгыннан – балык, ташбака йомыркасыннан – крокодил чыкмаган кебек; мәчедән эт тууы, чия төшеннән дә кузаклы фасоль үсеп чыгуы һич мөмкин түгел. Күзләребезне бу хакыйкатьләргә ачып, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә болай дип хитап кыла:

> **«Җирдә [кайсы уңдырышлы, кайсы коры, кайсы иген игәргә, кайсы агач үстерергә яраклырак төрле-төрле сыйфатларга ия] бер-беренә күрше кишәрләр, йөзем бакчалары, [төрле] игеннәр, тамырлары уртак һәм аерым булган хөрмәлекләр дә бар, һәммәсе дә [табигатендә бернинди аерма булмаган] бер үк су белән сугарылалар. Әмма [һәрьяктан бердәй булсын өчен моның кадәр сәбәп була торып] Без [җимешләрнең] берләрен [шәкел, тәм, исләре белән] икенчеләреннән өстен кылабыз. Һичшиксез, акыл ияләре өчен монда [бар итүченең өстен көченә күрсәткән ачык] билгеләр бар».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:4

Башка аятьтә болай дип әйтелә:

**«[Бодай һәм арпа кебек] Яфраклы игеннәр һәм хуш исле үләннәр бар».**

«Әр-Рахмән / Мәрхәмәтле», 55:12

Янәшәбездәге хайван һәм үсемлекләрнең тышкы кыяфәтләрендәге пропорция һәм симметрияләргә күз салсак, Аллаһының бу эшләрдә катнашы тагы да ачыграк күренә. Бу хакта Әл-Әгъләә сүрәсенең беренче аятьләрендә болай диелгән:

**«Бөек булган Раббыңның исемен тәсбих ит. Ул [һәрнәрсәне] ярат-ты һәм төзек итте. Ул [барлыкларның җенесләрен, төрләрен үлчәп] тәкъдир итте һәм [яратылыш максатына] юнәлдерде. Ул [терлекләргә] утлауларны чыгарды. Шуннан [аның яшел хәленнән] соң аны кап-кара чүпкә әйләндерә».**

«Әгъләә / Иң өстен», 87: 1–5

## «Авыруны таныган – дәвасын табар»

Чир һәм вәбаларга каршы көчсезлеге һәм үлемнән курку кешене элек-электән әйләнә-тирә табигатькә ярдәм артыннан мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткән. Сиземләве белән кеше бу җирдә ялгыз түгеллеген, исән калу өчен әйләнә-тирә мохиттан котылу чарасын эзләп табып кына котылачагын ул аңлап яшәгән. Адәм баласының дөньяга мондый карашын Коръәни Кәрим дә раслый:

**«Без әйттек: «Барыгыз бергә моннан төшегез! Әгәр Миннән сезгә һидаять килсә, кемнәр Минем һидаятемә иярә, шуларга бернинди курку да булмас, алар хәсрәт тә чикмәс»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:38

**«[Шулвакыт Аллаһы Адәм, Хава һәм Иблискә мөрәҗәгать итеп] Әйтте: «Бер-берләрегезгә дошман буларак [җәннәттән] чыгыгыз. Сезгә яшәү урыны һәм [әҗәлегез җитеп үлгәнчегә кадәр] вакытлыча файдалану урыны – җирдә».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:24

Ягъни, җиргә килгәннән соң, кеше имин тормыш көтәр өчен Раббысыннан күрсәтмә көтеп утырырга гына тиеш түгел, бәлки үзе дә шундый күрсәткечләрне эзләп табарга тиеш булган. Моның хакта пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Аллаһы Тәгалә нинди генә авыруны җибәрсә дә, һичшиксез, аның белән бергә дәвасын да җибәрә. Аны (авыруны) таныган – дәвасын белер, танымаган – белмәс», – дигән («Мөснәд», Әхмәд бине Хәнбәл).

Һәм кеше әлеге дәваны эзләгән. Аллаһыга ышанучылар гына түгел, атеистлар да эзләгән. Мәсәлән, СССРда 1931 елда, хәзерге көндә дә эшләп килә торган, дару һәм хуш исле үсемлекләрне өйрәнүче Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институты ачыла. Бу институт инде менә йөз елга якын СССРда, Рәсәй Федерациясендә һәм чит илләрдә үсә торган кыргый дару үсемлекләрен өйрәнү белән шөгыльләнә; өйрәнелгән үсемлекләрдән бүленеп чыгарылган биологик актив матдәләр нигезендә, дәвалау препаратларын җитештерү технологияләрен эшләп чыгара. Институтның эшләү дәверендә аның лабораторияләрендә үсемлекләрдән 120 дән артык дәвалау препараты уйлап табылган.

## Дару үләннәрендәге шифа кайдан килгән?

Әмма мәкаләбезнең темасына әйләнеп кайтып, дару үләннәрендәге дәвалау үзлеге нидән гыйбарәт икәнлеге турында да бераз фикер йөртеп карыйк. Үсемлекләр дәвалау матдәләре чыганакларының берсе булуы турында Коръәни Кәримдә болай диелә:

**«[Расүлем!] Синең Раббың бал кортына вәхи итте: «Тауларда, агачларда һәм [кешеләр төзегән] корылмаларда оялар кор. Шуннан соң, һәртөрле җимешләрдән туклан һәм Раббың җиңеләйткән юлларда йөр». Аларның карыннарыннан [ел фасылларының, чәчәкләрнең, бал кортларының яше үзгәрүгә бәйле] төрле төсле һәм кешеләр өчен шифа булган бер эчемлек чыга. Һичшиксез, боларда фикер йөртүчеләр өчен билге бар».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:68-69

Димәк, балдагы дәвалау сыйфатларына ия булган матдәләр иң элек бал корты туклана торган чәчәкләрнең серкәләрендә тупланган. Бу исә – кешеләр һәм хайваннар өчен шифалы матдәләрнең беренчел чыганагы – үсемлекләр булып торганлыгына ишарәт булып тора.

## Витаминнарның барлыкка килүе

Әле 1880 елда рус табибы һәм галиме Н.И. Лунин ашый торган ризыгыбызда, углеводлардан, майлардан, аксымнардан һәм минераль матдәләрдән тыш, ул вакытта әле фәнгә билгеле булмаган, организмның эшчәнлегенә этәргеч бирә торган махсус матдәләр булырга тиешлеген күрсәткән. 1895 елда рус патофизиологы В. В. Пашутин да сәяхәтчеләр һәм диңгезчеләр арасында киң таралган, миллионлаган гомерләрне алып киткән цинга кебек авыру түбән сыйфатлы туклану белән бәйле рәвештә алга китүен фаразлый. Бу, организмның үзендә түгел, ә үсемлек продуктларында синтезлана торган кайбер органик матдәләрнең ризыкта җитмәве белән бәйле булганлыгы турында фикер әйтелә. 1932 елда бу фараз Америка галимнәре тарафыннан раслана, цинга авыруының организмда бары С витамины җитмәүдән барлыкка килүе хакында әйтелә. Бу ачышны ясаучы галимнәр физиология һәм медицина өлкәсендә Нобель премиясенә лаек була. 1929 елда Нидерланд табибы Христиан Эйкман

«бери-бери» авыруының туклану рационының кимчелекле булуы сәбәпле барлыкка килүе турында әйтә, бу B төркеме витаминнарның ачылышына сәбәп була. Моның өчен дә галим Нобель премиясенә лаек була.

Кеше организмының нормаль эшчәнлеге өчен гаять мөһим роль уйнаган бу биологик актив матдәләрне лаборатория ысулы белән үләннәрдән чыгарырга өйрәнеп, кеше аларны «витаминнар», ягъни терелтеп җибәрүче, яшәешкә этәргеч бирүче матдәләр дип атый. Һәм кешенең тәүлеккә витаминнарга ихтыяҗы зур булмаса да, ул миллиграммнарда гына санала, аларның кеше сәламәтлеге һәм тормышы өчен роле гадәттән тыш зур.

## Үсемлекләр кеше өчен хәзинә

Бу тылсымлы матдәләр турында 1400 ел элек иңгән Коръәни Кәримдә дә әйтелми калмаган:

**«Без җирне дә [файдалансыннар дип] җәеп салдык, өстенә какшамас таулар куйдык, һәм үлчәүле [җимешләрдән] һәртөрле нәрсәне анда үстердек. Сезнең өчен дә, сез ризыкландырмаганнар өчен дә [азык-төлек һәм кием-салым кебек] яшәү кирәк-яракларын анда яралттык. Хәзинәләре Бездә булмаган бер генә нәрсә дә юк. Әмма [туфракка яңгыр һәммә җиргә дә бертигез яумаганы кебек, һәр җан иясенә кирәкле нигъмәт вә рәхмәт тә төрлечә булганлыктан] Без аны] билгеле бер микъдарда гына иңдерәбез».**

«Әл-Хиҗр», 15:19-21

Әлеге аятьтән аңлашылганча, җирдә үсә торган үсемлекләр, санап бетергесез күп булса да, һәрберсе кирәкле күләмдә һәм билгеле бер микъдарда гына үсә. Аятьтә кулланылган «мәүзүн» сыйфат фигыле «вәзн» тамырыннан ясалып, гарәп телендә «микъдар», «авырлык», «пропор-

ция» дигән мәгънәдә килә Аятьтә шулай ук мәхлүкъларның тереклеген куәтләп һәм баетып тору өчен, кирәкле күләмдә генә «иңдерелә» торган кыйммәтләр турында да әйтелә, бу байлыклар тупланып саклана торган «келәтләр» – гарәпчә «хәзинә» сүзенең күплек саны – «хазәин» сүзе белән тасвирлана

Шулай булгач, сорау туа: кеше һәм, гомумән, тереклек өчен гаять файдалы, әмма билгеле бер микъдарда гына үсемлекләрдә хасил булган шушы биологик актив матдәләрнең барлыгы турында хәзерге заман фәнендә дә билгеле булып та, Коръәни Кәримдә искә алынмавы мөмкинме? Һәм аятьттәге «хәзинәләр» – табигатьтә яшеренгән һәм тереклек өчен билгеле әһәмияткә һәм кыйммәткә ия булган витаминнар икәнен әйтеп буламы? Моны укучы үзе уйлап әйтсен

Табигатьтә яшеренгән һәм тереклек яшәеше өчен мөһим булган ви-таминнар булуын расларга буламы? Укучыларга бары фикер йөртергә генә кала.

*Альберт Кадыйров,*

*Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе мәчетенең мәхаллә әгъзасы, тәрҗемәче*

# Әдәби сәхифә

# Иман нуры берүк сүнмәсен

Инде ничә көн бертоташтан көзге яңгыр ява. Хәер, төшенкелеккә бирелгән җиһан берара күз яшен түгүдән туктап ала, ләкин соңыннан хисләнеп, янәдән сулкылдап еларга тотына. Менә бүген дә иртән авыр, кургаш болытлар белән капланган шомлы күк, җиргә якынайган сыман, үзенең киеренке сулышы илә берникадәр вакыт хафаландырып торганнан соң, төш авышкач, тын гына елый да башлады. Инде төн җитүгә карамастан, җиһан сагышлы сыктавыннан әле һаман туктамый…

Шәһәр мәчетенең икенче катындагы тоныкдивар кәндиле яктырткан ярым караңгы намаз бүлмәсендә инде байтак утырса да, Нурислам тулай торакка кайтырга ашыкмады. Имамнан: «Беразга калыйм әле, киткәндә үзем бикләп чыгармын», – дип рөхсәт сорагач, хәзрәт каршы килмәде, чөнки егетнең янәшә урнашкан мәдрәсәдә белем алучы шәкерт булуын белә иде ул.

Яңгыр ява да ява… Түбә калаена шыбырдатып төшкән тамчылар тавышы Нурисламның авылдагы йортын, андагы гамьсез, ипле тормышын исенә төшерде. Мондый сыйсыз көннәрдә авылда пычрак, күңелсезрәк булса да, аның каравы – анда, әнкәй, әби һәм энекәш янында, җаны тыныч, кальбе чиста иде аның…

Кара көзне тагын да ямансулатып, октябрь ае үзенең сүрән, салынкы көннәре белән сагыш өстәүдән тыш, Нурислам тормышына уйландырырлык үзгәрешләр дә алып килде. Ай ярымлап укыганнан соң булган бер хәл сәбәп иде моңа…

Бервакыт Нурисламны мөдир бүлмәсенә чакырдылар. Шәһәр мәдрәсәсенә авылдан укырга килгән бу егет башта ярыйсы гына тәртипле, әдәпле булып күренсә дә соңыннан әллә нәрсә булды үзенә: укуы да начарланды, үз-үзен тотышы буенча да мөгаллимнәр шелтә белдерә башлады… Дөрес, җан өтәрлек эш-гамәл кылмады, әмма вакытында чара

күрү максатыннан мөдир шушы шәкерт белән сөйләшеп алырга кирәк дигән фикергә килеп, аны үзенең эш бүлмәсенә дәште.

Сәлам бирешкәннән соң, әңгәмәнең җеп очын эләктерәм дип, мөдир шәкерткә сорау бирде:

– Йә, дус-кардәш, ничек хәл-әхвәлләр?

– Хәлем ару гына әлегә… – дип җаваплады ул, күңелендә барлыкка килгән шомлы хистән гасабилана төшеп.

– Бигүк ару түгел шул, ару түгел… – диде мөдир, егеткә каш астыннан кырыс карап. – Шуны ишеткәнгә күрә чакырдым да инде мин сине бирегә. Пырдымсызланып, тәртип бозып йөрүләрең турындагы сүзләр хакмы, әллә нахакмы? Ни диярсең моңа, шәкерт?

Гаебе булганын белгәнлектән, егет ни дип җавап бирергә белмичә, башын иеп сүзсез калды. Авылдагы тормыш икенче иде шул. Әбисе белән әнисенең даими күзәтүендә булгач, ниндидер кырын гамәлләр кылу турында уйлап та карамады Нурислам. Ә шәһәргә киткәч… күңел әллә нишләп китте: монда бит адым саен вәсвәсә! Шуңа күрә хәлен ничек бар шулай аңлатырга тәвәккәлләп, шәкерт остазына болай диде:

– Әй хәлфәм! Яшермим, бераз абындым… Ләкин нишлим соң – шайтан гел вәсвәсә кыла, гел котырта…Нигә икән шул мәлгунь миңа һаман шулай бәйләнә?..

Акланырга теләп, җаваплылыкны шайтанга аудармакчы булган егетнең тел төбендә ниләр ятканын аңлаган мөдир шунда көтелмәгән бер фикер әйтә:

– Ярый, аңлашылды. Мин бу хакта аның үзеннән сорармын.

– Кемнән? – диде шәкерт башын күтәреп һәм мөдир абзасы әйткәнгә төшенеп җитә алмаудан бераз сәерсенеп.

– Шайтаннан, – диде хәлфә бер дә исе китмәгәндәй. – Нигә сине шулай котыртып, юлдан яздырырга маташа икән ул? Бу хакта, ягъни мәсәлән, бүген шайтанның үзеннән белешермен. Әлегә исә кайт, ә иртәгә

шушы вакытта ук сугылырсың – мәлгунь җавап бирсә, сиңа җиткерермен.

Ни уйларга да белмичә, шәкерт гаять аптырашлы халәттә чыгып китте. «Шайтанның үзеннән сорармын ди… Менәтрә-әк!.. Әстәгъфируллаһ үә әтүбү иләйһи… Әллә зәһәрләнеп көлүе булдымы бу миннән? Һа-ай!.. Әллә чыннан да сораячак?..»

Шулай үзалдына сөйләнеп, гаҗәпләнүдән хәйран калган егет көчхәл белән тулай торагына кайтып җитте. Борчулы йокысыз төннән соң күктәге болытлар арасыннан күренеп алган кояш та яңа туган көнне нурландырмады. Мөгаллимнәрнең дәресләрдә аңа каты бәрелмәүләре дә күңелендә сөенечле халәт булдырмады. Билгеләнгән вакытны түземсезлек илә көтә-көтә, шәкерт изаланып бетте, шайтан нәрсә әйтер икән дигән уйдан бичараның башы тубал булды.

Дәресләр бетүгә шәкерт бисмилласын әйтеп өске каттагы мөдир бүлмәсенә менде. «Ләә хәүлә үә ләә куввәтә илләә билләәһ»,– диеп бүлмә ишеген шакыганнан соң, җавап булмагач, бермәл урыныннан кузгалмыйча басып торды. Шуннан тоткасына тотынып ишекне ачмакчы булды, әмма ишек бикле иде. «Кая булыр икән ул? Әллә шайтан белән һаман сөйләшеп бетермәгәнме?» – дип уйлап куюы булды – каршыдагы бүлмәдән уку-укыту бүлеге җитәкчесе чыкты да, мөдирнең тәҗел кирәктә мөфтияткә чакырылганын әйтеп: «Бер-ике сәгатьсез кайтмас», – дигән хәбәр ирештерде.

«Тагын көтәсе икән…» – дип көрсенеп куеп, шәкерт әлеге билгесезлектән аптырап калды, һәм бермәл нәрсә эшләргә дә белмичә басып торганнан соң китеп барды. Тышка чыккач, ул үзе дә сизмәстән, башын күтәреп өскә бакты: шомлы томсарган куе соры күк йөзеннән, әрнүле күз яшьләре сыман, яңгыр тамчылары тама иде. Нурисламның чандыр гәүдәсен кабып йотарга әзер торган күкнең дәһшәтле шәүләсе төшенкелек халәтен көчәйтеп, шомландырды, күңелдәге борчу хисен тагын да арттырды. Бу вакытта бөтен җиһан рухи мәгънәдә сөрлегеп тор-

мыш сазына егылган шушы бәндәгә сорау бирә иде кебек: «Нишләдең соң син?!». Күңелдә барлыкка килгән авыр хистән һәм туңудан бөрешеп, егет, өзгәләнгән рухын ияртеп, көч-хәл белән атлап китте.

Бер яктан караганда, кырын гамәл кылуыннан читенсенде, оялды Нурислам, икенче яктан исә – күңеле никтер шуңа омтылганын, тартылганын, кызыкканын тоя иде ул. Дәресләрнең берсендә укытучы шайтанның кешегә ясаган йогынтысы турында сөйләгәч, Нурислам кем гаепле булганын чамалый башлады, тик ни өчен мәлгунь аңа шулай бәйләнгәнен аңлап кына бетермәде. Мөдирнең шушы мәсьәләгә ачыклык кертәм дию аны шуңа күрә кызыксындырды да инде.

Остазы вәгъдә иткән җавапны ишетмичә җаны тынгы тапмаячагын белгәнгә, ике сәгать үтүгә шәкерт янә мөдир бүлмәсенә юнәлде, әмма ишеккә кадәр килеп җиткәч, дулкынланудан хәлсезләнеп, тәмам мәлҗерәеп китте…

Хәлфә бу юлы урынында иде, ләкин телефоннан сөйләшү сәбәпле, диванга ымлап, Нурисламга утырып көтәргә кушты. Күңеленнән шөкер итеп, ул остазы сөйләшкән арада бераз хәл алды.

– Килеп җиттекме, кардәш? – диде мөдир телефоннан сөйләшеп бетергәч. – Сорадым мин шайтаннан синең хакта, сорадым.

– Ш-шулаймы?.. Н-нәрсә диде соң м-мәлгунь? – диде шәкерт дулкынлануыннан тотлыгып.

– Аның җавабын җиткергәнче, сорау бирим әле сиңа: нәрсә ул гөнаһ?

– Гөнаһмы? Ну… Аллаһы Тәгалә яратмаган нәрсәне эшләү… Ул билгеләгән канунны бозудыр инде…

– Әйе, дөрес. Ә хикмәт ияләре «гөнаһ ул – шайтан бакчасыннан бер җимеш» дигән аңлатма да бирә. Ни өчен моны сиңа әйтәм? Чөнки синең турыда шайтаннан сорагач, ул болай диде: «Бу шәкерт минем бакчама кереп, җимешләремне урлый. Шуннан туктаса, аны тынычлыкта

калдырырмын».

…Мөдир шайтан белән ничек, ни рәвешле сөйләшкән – шәкерт анысын сорап тормады. Бәлки, остаз үзенең тормыш тәҗрибәсенә, хикмәтенә таянып, белгәннәрен файдаланып җавап биргәндер – анысы әһәмиятле түгел. Иң мөһиме – бу җавап бик нык тәэсир иткәнгә, Нурислам күңелендә «үзгәрергә, кырын гамәлләр кылудан туктарга кирәк» дигән фикер барлыкка килде. Хәлфәнең җавабы кинаяле булса да шәкерт аның нәрсә әйтергә теләгәнен шундук аңлады. Шайтан бакчасы ул – хәрам саналган гөнаһлы гамәлләр биләмәләре, шул бакчадагы җимешләр – гөнаһлы гамәлне кылудан тойган кичерешләр. Шушы хисләр вакытлыча ләззәт, канәгатьлек бирсә дә, алар кешеләрне рухи баткаклыкка, куркыныч кара чоңгылга батырып һәлак итәргә мөмкин…

– Исемең нинди матур бит синең! – диде аңа остаз, елмаеп. – «Исламның нуры»! Шул исемең җисеменә туры килсен дисәң, һәр гамәлнең нәтиҗәсе хакында фикерләргә тырыш. Халык мәкалендә билгеләп үтелгәнчә, «тауның күрке таш белән, адәм күрке баш белән»… – уйла нәрсә кылганыңны!

Ә уйланырлык, җитди нәтиҗәләр ясарлык сәбәпләр чыннан да бар иде. Әйтик, күптән түгел аның шушы шәһәрдәге техникумнарның берсендә укып йөргән яшьтәш авылдашы наркотик матдәләр белән тотылып кулга алынды. Ә бит гади генә тәмәкедән башлаган иде…

Шәкертнең фикерен күзләреннән укыгандай, остаз әйтте:

– Кеше гөнаһ кылса, аның зыяны Ахирәттә генә түгел, бу дөньяда да ирешә: Аллаһы билгеләгән чикләрне бозу аркасында кешенең ризыгы киселә, әйберләренең бәрәкәте китә, җанын борчу, бимазалану чолгап ала. Шайтан әзерләгән тозакларга инде ничә тапкыр эләктең, ә шуны абайладыңмы? Шуңа күрә, агай-эне, тормыш коймаң түнмәсен һәм үзеңә зыян килмәсен өчен кичектергесез чара күрергә кирәк…

Бүгенге хәле өчен читенсенеп утырса да, мөдир сөйләгәнне тыңлаудан тынычланды, юанды Нурислам. Күңелдәге кара болыт тарала башлаганга, тормыш офыклары яктырып, ачылып киткәндәй булды. Шуннан кинәнеп, ул остазына ихлас рәхмәтен җиткерде һәм шайтан зарарыннан сакланыр өчен нинди чара барлыгын сорады.

– Шушы мәсьәләгә бәйле бер хәдисне искә төшерәсем килә, – диде мөдир. – Бервакыт пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү гәләйһи үә сәлләм сахәбәләренә дәшеп: «Иң зур сырхау турында сезгә әйтимме?» – дип сорады. Сахәбәләр: «Әйе», – дигәч, Мөхәммәд салләллаһү гәләйһи үә сәлләм әйтте: «Адәм баласы өчен иң зур сырхау ул – гөнаһ». «Шушы авыруны ничек дәвалап була соң?» – дигән сорауга исә ул болай җавап бирде: «Аның шифасы – төн караңгысында Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, гөнаһ чиреннән котылуны сорап дога кылуда»...

Шул төнне Нурислам мәдрәсә белән янәшә урнашкан мәчеттә үткәрде. Бая кемнәндер зарланган сыман үксеп яуган яңгыр тавышы хәзер инде күңелгә ятышлы бер нәсыйхәт кебек яңгырый иде. Остазы белән сөйләшкәннән соң аның күңелендәге үкенү һәм өмет хисләре бербөтен булып, алда «тәүбә» дигән яктырткыч нурына күмелгән киң һәм якты юл ачылды. Яшь егетнең кайчандыр пакь, чиста җаны вәсвәсәләр корымына пычранса да, аны сафландыру ысулы аңа инде билгеле иде. Иң мөһиме – садә, юаш җанны басып алмакчы булган кара көчкә каршы тору кирәклеген аңлады бу төнне егет. Саташкан күңел төпкелендә «иман» дигән утның әкрен генә пыскып януын тоюдан аның иләсләнгән кальбендә куанычлы өмет туды. Әрсез, явыз шайтанның бакчасына кереп аның җимешләрен урлап чыгуның ләззәте алдавыч һәм бик зарарлы булуын аңлау исә мәлгунь богауларыннан арынырга, иншәАллаһ, ярдәм итәчәк. Моның бердәнбер ышанычлы ысулы – Аллаһының Рәхмәте капкасына кайтаручы ихлас тәүбә.

Әйе, иблис бик хәйләкәр һәм мәкерле, ләкин син әле көчсезрәк булсаң да, өметсезлеккә бирелеп, күңел төшерәсе түгел: Аллаһы Тәгалә Үзенең тырыш, игелекле, ихлас бәндәләрен ярдәменнән ташламый. Кара көчләргә Аллаһыга сыенып каршы торсаң, алар сиңа бернинди дә зыян сала алмый. Начарлыктан читләшеп, изгелеккә омтылып, син җан төбендә әле көйрәп торган Бәхет утын тәмам сүнүдән саклап каласың. Сабырлык исүеннән ул ут ялкыны көчәеп китсә, аңа гыйбадәт җиле дә өреп куйса, ялкын инде дөрләп яна башлаячак…

– Ий Аллаһым, ий Раббым минем! – дип пышылдады Нурислам, ике учын догага күтәреп. – Синнән башка илаһ юк! Син мине бар кылдың… Мин Синең колың, зәгыйфь колың… Нәрсә булса да, Сиңа итагать итәргә, Сиңа тугры булырга тырышачакмын… Гөнаһларымны, хата-кимчелекләремне кичер, ий Раббым… Шайтан зарарыннан, барлык явызлыклардан Үзеңә сыенам! Миңа бүләк иткән саулыгым, игелекле туганнарым, газиз әнкәем, дини белем алу мөмкинлегем өчен рәхмәт Сиңа, Раббым! Барча нигъмәтләрең өчен шөкер кылам һәм гөнаһларымны гафу итүеңне сорыйм… Синнән башка мине беркем ярлыкамас, Синнән башка мине беркем коткармас…

Җиһан тынды сыман. Түбә калаен шакылдатып сикерешкән тамчылар, сөенечле хәбәр уртаклашкандай, тып-тып килеп, үзара серләшәләр иде шикелле. Тышта салкын һәм караңгы булса да, ихлас дога җанны җылытты, өзгәләнгән күңел ертыкларын ямап, аны савыктырды, юатты. «Иман нурың берүк сүнмәсен!..» – дип нәсыйхәт кылып, яңгыр шыбыр-шыбыр килеп һаман яуды да яуды, яуды да яуды…

# Ихлас дога көче

Менә инде бер сәгатькә якын Фәһим тирән уйга батып, үзен битәрли-битәрли, күңелен биләп алган үкенеч тойгысыннан арынмакчы булды. Ләкин үзен борчуга салган нәрсә турында күбрәк уйлаган саен җан әрнүе басылмады, киресенчә – арта гына барды. Чарасызлыктан нишләргә белмичә, ул гасабиланып, түрле-ишекле йөренергә тотынды, әмма бераздан киләп сарып йөрүеннән алҗыгач, диванга утырып, суырылып калган төмсә чыраен аска иде. Шулай идәннең бер ноктасына төбәлгән килеш Фәһим соңгы еллардагы тормышын исенә төшереп, байтак уйланып утырды.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул авыл хуҗалыгы академиясенә укырга керә, ә диплом алгач, үзләштергән белгечлеге буенча шәһәрдә эш булмаганлыктан, авылга кайта. Әмма биредә дә аны колач җәеп көтмиләр: үз колхозлары таралган, тирә-яктагы авылларда исә агроном вакансияләре булмый. Шулай тиен санап яшәүдән гарык булган, өлкән яшьтәге пинсәнир әти-әнисенең хисабына җан асрарга теләмәгән егет үз эшен башлап җибәрергә ният кыла. Бергә укыган курсташы киңәше белән ул кабер ташлары ясау буенча махсус укуларда катнаша. Әле мәктәптә укыганда ук мәчеткә йөреп, гарәп язуын өйрәнгән, намаз укыган егет өчен бу эшнең серләренә төшенү әллә ни авыр булмый. Һөнәр үзләштерелгәч, Фәһим авылдагы ихатасында урын көйләп, кабер ташлары ясый башлый, ә инде бераздан гранит-мәрмәр кебек кыйммәтле чималдан затлы өй җиһазлары ясарга да өйрәнгәч, интернетка белдерү урнаштыра. Әүвәл заказлар күп булмый, соңрак исә, интернет сәхифәсендәге фотоларга кызыгыпмы, ясалган әйберләрнең шактый матур һәм сыйфатлы булуына инангангамы, заказ бирүчеләр күбәя, Фәһимнең эше, шулай итеп, бер тәртипкә салынып, бәрәкәт эзенә төшә. Авылдашлары да аны мактап: «Ташка җан кертә диярсең – шаккатмалы күркәм булып чыга...»

– дип күңелне күтәргәч, егет канатланып, тагын да югарырак үрләргә күтәрелергә теләп, бик тырыша.

«Оста – дөнья тоткасы» дигәндәй, матди хәле яхшыргач, Фәһим үз авылындагы Зәлифә исемле кыз белән гаилә корып җибәрә. Яшь хатынның да үзе пешергән ризыклары белән сыйлый-сыйлый шаярыбрак: «Ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен!» – дип һәрдаим дәртләндереп торуы ир-егетнең күңелен үстереп, аны тагын да ныграк илһамландыра иде.

Көннәр бер-берсенә охшаш булса да, тырыш хезмәтнең нәтиҗәсен, клиентларның канәгать йөзләрен күрүеннән һәм аларның чын күңелдән рәхмәт белдерүләрен ишетүеннән ниндидер аңлатып булмаслык рәхәтлек кичерә иде Фәһим. Заказ бирүчеләр арасында, кем әйтмешли, аласы да, коласы да бар иде: кемдер гадирәк кабер ташы кирәк дип килсә, икенче берәүләр өйләренә кыйммәтлерәк затлы җиһаз ясатырга дип мөрәҗәгать итте. Ә менә бүген…

***

Кояш зәүвәл ноктасына җитеп, авыл өстен кайнар нурлары белән бар көченә кыздырып маташкан бер мәлдә Фәһимнәрнең капка төбенә шактый зур чит ил машинасы килеп туктый. Машинадан чыккан кара күзлекле өч ир кешенең кыяфәтеннән каршыдагы йортның түр бакчасына терәлеп торган эскәмиядә утыручы берничә әби пошаманга төште:

– Бер генә карале син боларга… Башкисәрләр килеп җиткән, диярсең, шәйтан алгыры… – диде берсе пышылдап.

– Кемнәр соң болар? Күреп бетермим.. – диде икенчесе, күзлеген сөртергә керешеп.

– Кем булсын… – дип авызын кулы белән капларга тырышып җаваплады өченчесе. – Бөтен район үзәген өркетеп торган теге әзмәвер Халид бит инде… Элгәре еллардатанылган талаучы иде, хәзер кайсыдыр зур оешманың җитәкчесе диләр… Район Советында депутат та әле бугай…

Капка ишеген ачып ишегалдына кереп киткән ирләрне күз карашлары белән озаткан әбиләр: «Хәерлегә булсын…» – дип теләпкалдылар.

Мондый «кәттә кунакларны» күрүгә Фәһим коелып төшмәде үзе, әмма күңеленә ниндидер борчу-хәвеф үтеп керде. Әйе, Халид Фоатович турында ул ишетеп белә иде. Яшь чагыннан ук үзенең явыз кыланмышлары белән билгеле булган эре гәүдәле, таза беләкле, җирән чәчле бу бәндәне «Буржуй»дип йөрттеләр. Ниндидер урау юллар аша җитәкче дәрәҗәсенә күтәрелгәч тә, аның тискәре гадәтләре белән бергә шушы кушаматы да сакланып калды. Фәһимгә заказ бирүчеләр арасында төрле кеше булды, әмма Буржуй кебек яманаты еракка таралган клиентны моңарчы күрергә туры килмәгән иде аңа.

– Гөл савыты ясап бирә аласыңмы? – дип сорады Халид Фоатович. – Менә шундыйрак…

Ялтыравыклы бер журналның битендә сурәтләнгән бизәкле зур савытның рәсеменә карагач, Фәһим:

– Ясамаслык түгел, ләкин моның өчен затлы, бик кыйммәтле мәрмәр кирәк, – дип белгечләрчә үз фикерен әйтте.

– Анысы булыр, – диде Буржуй вәкарьлек белән, үзе белән килгән ике юлдашына ым кагып.

Ике минут та үтмәде, кунаклар чүпрәккә төрелеп тартмага салынган ярыйсы авыр бер әйберне алып керделәр.

– Италиядән кайтартылган иң кыйммәтле «каррара» дигән мәрмәр бу! – диде «кәттә» клиент, горурлыгын яшерә алмыйча. – Акчамны җәлләмәдем, чөнки минем өчен бик кадерле булган бер кешенең туган көненә яхшы бүләк ясыйсым килде. Әгәр матур итеп ясап бирсәң бу әйберне, сиңа да хакын мулдан түләрмен…

Күңел төбендә ниндидер шикләнү хисе шытып чыкса да, олы кунакның үтенечен кире кагарга кыймаган Фәһим: «Ярар, тырышып карармын», – дип ишегалдында басып калды. Капкадан чыгып барган Ха-

лид Фоатович исә борылып:

– Кара аны! Ыштоп җиренә җиткереп эшләнгән булсын! Минем өчен бик кадерле кешемнең туган көне киләсе шимбәдә. Димәк, заказны нәкъ бер атанадан алырга киләм. Аңладыңмы? Давай, уңышлар! – диде дә машинасына утырып, кузгалып китеп барды.

***

Махсус заказ өчен китерелгән таш чыннан да бик затлы иде: урыны белән каралҗым, урыны белән куе шәмәхә төстәге шоп-шома мәрмәрне беренче күрүгә Фәһим «сүбехәәнәллаһ...» дип гаҗәпләнүен белдермичә булдыра алмый. Материалны мастерскоена күчереп куюга ук ул вакытны озакка сузмыйча эшкә керешә: булачак савытның рәсеменә тагын бер күз ташлый да, чүкеч белән өтергесен кулына алып, ташны чокый башлый. Беренче мәлдә эш гадәттәгечә бара, әмма бераздан... Фәһимнең аз гына кыеграк киткән уелдыкны төзәтәм дип сугып җибәрүе була – затлы мәрмәр чатнап китеп урталай ярыла... «Аһ!..» – дип кенә әйтергә өлгергән Фәһим катып кала һәм күпмедер вакыт нәрсә булганын абайламагандай, ярылган ташка аптырап карап тора. «Бетте баш... боздым материалны...» – дип уйлап куйган ирнең тыны кысылып, йөрәге чәнчергә тотына. Ишегалдына чыккач та аяз күкле, кояшлы көн кап-караңгы булып тоела Фәһимгә. «Харап булдым... Алынасы түгел иде бу эшкә... Хәзер ни дип әйтермен Буржуйга? Аннан ни көтәсен дә белгән юк... Һәрхәлдә, ул моны болай гына калдырмас... тиешле чарасын күрер... Харап булды-ым...». Күңел һәм баш мие аша узып киткән уйларның бөтенесе дә курку һәм имәнеч бер хис илә өртелгән иде. Шушы нык каушаган хәлдә Фәһим урамга чыгып, капка алдындагы эскәмиягә утырды. Нәүмизләнеп, ни эшләргә, ни уйларга белмичә аптырап утырган шушы чагында аның янына күршесе Хисам килеп басты.

– Бәй... Әллә балтаң суга төшеп киткәнме? – диде ул мескен кыяфәтле егет янына утырып. – Нәрсә булды?

Фәһим хәлне аңлатып биргәч, Хисам өч иҗекле аваз белән сызгырып алды да: «Да-а... Эшләр чыннан да бик хөрти икән...» – дип авыр сулап куйды.

– Бу әзмәвер үтереп ташларга да күп сорамас! – диде ул, «өметләндереп». – Мәрмәрне ничек тә ялгап куярга кирәк!

– Комнан аркан ишеп күлне күккә асып куеп булмый шул, агай-эне. Ялгый торган түгел ул ташны, берничек тә ялгап булмый аны... – дип җавап бирде Фәһим, аска иелгән башын күтәрмичә.

– У-уу... Алай булгач, кәфенлегеңне әзерлә! – диде Хисам, әллә янап, әллә шамакайланып. – Ул явыздан котылыр хәл юк! Куркып гомер сөргәнче, капланып үлүең артык...

– Уф, күрше... – диде Фәһим башын күтәреп. – Нинди үлү? Яңа гына өйләндем бит әле мин...

– Алай булгач, выше хвост, егет! Кем әйтмешли, онытчак бүреген югалтыр, куркак башын югалтыр. Үз көчеңә сыен: сарык булмасаң – бүре ашамас!

– Ник, мин аны нишләтим? –диде Фәһим, болай да буталган фикерләрен ныграк чәбәләндереп бетергән күршесенә. – Аның белән сугыша алмыйм ич инде. Якасына яшь түгеп тә торасы килми. Шушы көннәрдә эшне башкарып, заказны иясенә тапшырырга кирәк...

Шулай итеп, күршесе Хисамның өзек-тәтек «киңәшләре» аның киләбен чуалтып, бернинди җиңеллек бирмәде. Сантыйланып, юкны бушка аударып сөйләнеп торырга була ул. Авыз сөйли инде ул...Ләкин йөрәк хәлнең асылын аңламагач, телдән ни файда? Үч иткәндәй, Зәлифә дә кичә әниләренә дип киткән иде, бүген кич кенә кайтырга тиеш...Аның белән киңәшергә кирәк булыр. Бәлки, бер акыллы фикер әйтер? Ул да бит диндә, намаз укый, шәт, иншәАллаһ, берәр төпле киңәш бирмичә калмас...

Менә шулай уйлый-уйлый, күңелен биләп алган үкенеч тойгысыннан арынырга теләп, Фәһим башта бүлмәнең бер ягыннан икенче ягына йөренде, аннары диванга утырып, беравык идәннең бер ноктасына төбәлеп, кымшанмыйча утырды. Зәлифә кайтып кергәндә, кояш батарга әзерләнеп, дөнья Җомга кичен каршыларга әзерләнгән иде.

– Булган икән! – диде ул кырт кисеп, ире аңа хәлне аңлаткач.

– Күрше Хисам курыкмаска, үз көчеңә ышанырга кирәк, ди...

– Хисам, Хисам... – дип борын астыннан гына мыгырданып алды Зәлифә. – Ул белгәнне без инде киптереп элгән! Борыныңа карап төчкерәләр аны. Шул бандитны җиңә торганмыни?

Урындыкка утырып, хатын яндагы өстәлнең өстенә бармаклары белән шакылдатып алды. Аннары аңына килгәндәй:

– Син икендене укыдыңмы соң әле? – дип сорап куйды.

– Аһ... – дип тертләп куйды Фәһим. – Уйга батып, онытылып киткәнмен...

– Тәк, бераз вакыт бар әле, – диде Зәлифә торып. – Әйдә, тәһарәтеңне алып икенденңне укы да, бар әле син мәчеткә. Ахшамнан соң Нурулла хәзрәт белән киңәшерсең.

– И-и, нәрсә әйтим инде мин аңа... – дип икеләнүен белдергән иренә Зәлифә болай диде:

– Телең авызыңда бит – сөйлә! Барысын да ничек булды – бәйнәбәйнә сөйләп бир! Безнең әби дә әйтә торган иде: яшь беләгенә ышаныр, карт белгәненә ышаныр. Хәзрәт белән киңәшергә кирәк, олы кеше берәр төпле фикер әйтмичә калмас...

***

...Икенде укып урамга чыккач, Фәһим, ахырына авышып килгән көннең аның күңел халәтенә тәңгәл килүенә игътибар итте: күк йөзен каплаган хафалы болытлар авыл өстенә ачы яшьләрен түгәргә җыенган

иде сыман. Әүвәл алан-йолан шөбһәле каранып барганнан соң, ул, күңелендәге өркү хисен бастырырга теләп, карашын өскә юнәлтте, әмма алгысытып җиргә ишелергә әзер торган авыр, шомлы күк күренешеннән күңеле тагын да күбрәк төшенкелеккә бирелеп, Фәһимнең кәефе тәмам кырылып китте.

Егет мәчеткә килеп җиткәндә, мәхәлләне яңгыратып, манарадан моңлы итеп азан әйтәләр иде. Йончулы халәтенә тынычлык иңдергән азан тәмамланганда, Фәһим намаз бүлмәсенә кереп җитешкән иде инде. Камәт әйтелеп, берничә кеше катнашында ахшам намазы укылганнан соң, ул имамга дәшеп, сөйләшеп алырга рөхсәт сорады. Җыйнак кына бүлмәгә кереп утырып дога кылынгач, Фәһим сүзен башлап, сорау бирде:

– Хәзрәт, әйтегезче миңа: авыр хәлгә тарыгач, сез, гадәттә, нишлисез?

– Адәм баласы моннан да авыррак хәлдә калырга мөмкин бит, дип уйлыйм, – диде имам. – Чынбарлыкта авырлык кешегә ул Аллаһыга ярдәм сорап мөрәҗәгать итсен өчен бирелә.

– Минем белән шундый хәл булды бит әле, – диеп,күңелен каплаган шом пәрдәсен ачып җибәрде Фәһим. – Район үзәгендә яшәүче урындагы бер зур түрә миңа затлы гөл савыты ясатыр өчен бик кыйммәтле, чит илдән кайтартылган мәрмәр ташыкалдырып китте. Шуны ясап маташкан чакта таш урталай ярылды. Аның иясе булган шул түрә – яманаты таралган хәтәр, холыксыз кеше, һәм мин аңа бу заказны вакытында тапшырмасам, аннан зур зыян килергә мөмкин. Ә чималы бозылган булгач, әйберне берничек тә ясап булмый…

– Аңлашылды, энем, аңлашылды. Нәрсә дип әйтим? Аллаһының рәхмәте киң, һәм Коръәндә билгеләп үтелгәнчә, Ул теләсә, һәрбер хәлдән чыгу юлын күрсәтә. Үзеңнең Аллаһы колы булуыңны танып, ихластан сорарга гына кирәк.

– И хәзрәт… Могҗизалар буламыни ул? Сорасаң да, сорамасаң да, ул ярылган ташны берничек тә ялгап булмый ич…

– Аллаһы Тәгалә могҗиза булдырырга да кадир.Таш хуҗасы кырыс, усал кеше дисеңме? Ә менә мин сиңа бер хикәят сөйлим, тыңлап кара әле...

...Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү гәләйһи үә сәлләм вафатыннан соң икенче хәлиф, ягъни мөселманнарның әмире булып Гомәр радыяллаһу гәнһү сайлана. Нык иманлы мөэмин, хикмәткә ия акыллы җитәкче булудан тыш ул физик мәгънәдә бик көчле баһадир һәм кырыс холыклы җитәкче буларак та билгеле иде.Шулай бервакыт кырыс әмир шәһәр урамы буйлап кылыч тотып барганда, аны күргән кешеләр «берәр нәрсә өчен эләкмәгәе» дип хафаланып: «Гомәр хәлиф бара!.. Гомәр хәлиф бара!..» – дип тыз-быз килеп, кабалана-кабалана юлның читенә ыргылып, качарга тотынды. Фәкать бер генә кеше бернигә исе китмәгәндәй юлның уртасыннан нәкъ Гомәр ибне Хәттабка каршы баруын дәвам итте. Алар йөзгә йөз очрашып, бер-берсе янына килеп баскач, хәлиф туктап, бу кешегә сорау бирде:

– Йә, ә син нигә качмыйсың?

– Мин бит сукыр, – дип җавап бирде бу кеше. – Синең юлдан барганыңны абайламыйча калганмын...

Җавапның дөрес булуына инангач, Гомәр радыяллаһу гәнһү сукыр кешегә болай ди:

– Күзләрем сәламәтләнсен, күрә башласын, дип Аллаһыдан сорамыйсыңмыни?

– Нишләп сорамаска? Сорыйм... Ләкин әлегә үзгәреш юк әле...

– Ярар, – диде Гомәр хәлиф. – Алай булгач, күзләре күрми торган бу башың сиңа нәрсәгә? Иртәгә иртәнге 8 гә килерсең – чабабыз башыңны!

Сукыр кеше ни дип җавап бирергә белмичә, куркуга төшеп басып кала, хәлиф исә тыныч кына китеп бара. Шушы сөйләшүне ишеткән кешеләр: «Әмиребез моңарчы вәгъдәсен үтәмичә калганы булмады әле. Ни әйтсә – шуны һичшиксез үти торган кеше ул...» – дигәч, сукырның

күңелендә кабынган курку уты дәһшәт ялкынына әверелә.

Көч-хәл белән өенә кайтып җиткән сукыр елый-елый: «Ий Раббым, ий Ярдәмчем, ий Терәгем, йә бердәнбер Илаһым… Күз күрүемне кайтарсаң иде, юкса Гомәр башымны чаба бит…» – дип, төне буе дога кылып чыга. Исән калырга бик теләгәнгә күрә, ул шундый ихласлык белән сорый ки, иртән таң атып кояш чыкканда… аның күзләре күрә башлый. Моңа чиксез сөенеп, ул билгеләнгән вакытка Гомәр радыяллаһу гәнһү янына килеп, шатлыгы белән уртаклаша. Хәлиф исә елмаеп әйтә: «Аллаһу әкбәр! Менә шулай сорыйлар аны! Ихлас дога галәмәт зур көчкә ия ул, кардәш. Андый дога могҗиза булдырырга да сәләтле! Чын күңелдән эчкерсез сораганга, Аллаһы Тәгалә җавап бирмичә калмый…».

– Сүбехәәнәллаһ… – дип әйтеп куйды Фәһим, имам хикәятеннән тәэсирләнеп. – Инде күрмәгән күз дә күрә башлагач… Ярый хәзрәт, аңладым. Бик үтенеп сорарга кирәк инде алайса Аллаһтан. Шулай да… ялганырмы соң инде ул таш?..

– Анысын уйлама син, – диде хәзрәт күзләре белән елмаеп. – Икеләнгән шикләнер – шиге белән чикләнер. Бүген дога кылып ихластан сора, догаң кабул булса, Аллаһының рәхмәте белән берәр уңай нәтиҗәсе булмыйча калмас.

Ястү намазын да җәмәгать белән мәчеттә укыгач, Фәһим кайтып китте. Хатынының «нәрсә диде хәзрәт?» дигән соравына «ихлас дога кылып Аллаһыдан ярдәм сорарга кушты» дигәч, Зәлифә:

– Син чәй эчеп ал да ят, төнлә тәһәҗҗүд намазына торып, дога кылырсың, – диде, әмма Фәһим уйларына бирелеп, ясалган чәен дә эчмичә, түшәгенә ауды. Хатынының шалтыр-шолтыр килеп табак-савыт юган тавышына йоклап киткән ир бераздан төш күрепме, саташыпмы ыңгыраша башлады. Моны ишеткән Зәлифә кулын сөртте дә янына килеп утырып, башын сыйпый-сыйпый: «Борчылма, җаныкаем, барысы да яхшы булыр, иншәәАллаһ…» – дип ирен дә, үзен дә тынычландырды.

Аның саф күңелдән әйтелгән шушы сүзләре уртак доганың башы булды…

Төн өченче өлешенә күчеп тәһәҗҗүд вакыты кергәч, Зәлифә хәләл җефетенең иңбашына җиңелчә төртеп:

– Әйдә, тор… Тәһарәт алып ике рикәгать намаз укы да хәзрәт өйрәткәнчә дога кыл!.. – дипаны уятып торгызды.

Шушы дога Фәһимнең соңгы өмете иде. Куркудан битәр, «заказ бирүченең әйберсен боздым» дигән оялу хисе дә тынгылык бирмәде аңа. Менә шушы ике тойгы кушылудан хасил булган талпыну йогынтысында ул нәфел намазыннан соң ихластан, күз яшьләре илә дога кылып, Аллаһыдан ярдәм сорады.Төнге лампаның сүрән утында иренең ярымпышылдап әйткән сүзләрен аермаса да, караватында тып-тын яткан Зәлифәнең эчтән генә тәкрарлап әйткән «әмин,әмин» дигән сүзләре тамак төбенә төер булып утырды. Ире янына килеп яткач та: «Шәт иншәәАллаһ, барысы яхшы булыр…» – дип йокы аралаш әйткән кебек рәвеш китерде, үзе исә диварга таба борылып, тавыш-тынсыз гына елап алды.

***

Яңа көн бик матур булып туды. Җете кояш балкып торган зәңгәр күктә болытларның әсәре дә калмаган. Фәһимнең күңелендәге рәхәт җиңеллек аларның ихатасы өстеннән үтеп, авылга – бар җиһанга таралып китте сыман. Һөнәрханәсе ишеге янына килеп баскач та, егет беравык керергә кыймыйча бер урында таптанып торды. Аннан тәвәккәлләп ишекне ачып кергәч, түрдәге «каррара» мәрмәренә күз салды. Таш кичтән ничек калган – шулай урталай ярылган хәлдә ята иде.«Ярар, нишлисең инде… Күрәсең, бу дөньяда могҗизалар чыннан да булмый», – диде ул үз-үзенә, ташның ялганмаганлыгын бүтән үзгәрмәячәк ахыргы хөкем буларак кабул итеп.

Өенә кереп, табын алдына утыргач, газ плитәсе каршында коймак пешереп маташкан хатынына ул таш турында берни дә әйтмәде, гомумән, бу теманы кузгатмыйча, башка нәрсәне сөйләштеләр. Тәмле итеп чәй эчеп алганнан соң гына Фәһим «кабул булмады бит догам» дип әйтергә талпы-

нып авызын ачкач, капкалары янына машина туктаган тавыш ишетелде. Тәрәзәгә карап алган Зәлифәнең: «Ниндидер зур чит ил машинасы», – диюеннән Фәһимнең йөрәге кысылып куйды. Пәрдә аша урамга баккач, ул Буржуйның машинасын танып алды.«Бер атна үтмәде бит әле… Эшнең ничек барганын тикшерергә килгәндер…» – дип үз алдына сөйләнеп алган Фәһимнең йөзе агарынган иде.

– Шулмы? – диде Зәлифә, иренә кыю, хәтта усалрак карап куеп. – Хәзер үзем чыгып сөйләшәм!

– Юк инде, кирәкми, – дип җавап бирде Фәһим, тынычлыгын җуймаска тырышып. – Ир кеше белән ир сөйләшергә тиеш. Ничек тә аңлашырбыз әле.

Зәлифә өстәлне сөртеп, читләре сыпылган тастымал белән ризыкны каплаган арада Фәһим урамга чыгарга өлгерде. Ул вакытта килгән кеше бикле капкага ярыйсы каты шакылдатып тора иде инде.Коты очып китәргә әзер булган хәлдә Фәһим «әгузү-бисмилләһ» белән «тәүәккәлтү гәләллаһ» догаларын укып, капка аратасын этеп җибәрде. Капка ачылгач исә ул Буржуйны түгел, ә аның белән килгән ике ярдәмчесенең берсен – машина йөртүчесен күрде.

– Бер килешме хәлләр? – дип күтәренке кәеф илә сүзен башлады килгән ир. – Халид Фоатович аванс кертеп бирергә кушты. Әлегә биш меңне калдырабыз, калганын заказ әзер булгач үзе бирер. Мә, тот!

– Т-туктагыз әле, тукта… – диде Фәһим, акча сузган иргә.– Монда бер проблем килеп чыкты бит әле…

– Беләм, заказларың күптер, ләкин үзең аңла – бу бит Халид Фоатович! Аныкы иң беренче нәүбәттә эшләнергә тиеш! Кыскасы, атнакич «кровь из нос» – ләкин заказ әзер булсын! – диеп, Буржуй ярдәмчесе акчасын тоттырды да борылып машинасына таба атлады.

Очып китәргә әзер торган котының инде очып киткәнен анык тойган Фәһим телсез калды. Башта кулындагы бишмеңлеккә, аннан килгән

кешегә мескен караш ташлап, ул сүз таба алмыйча басып торды. Ир-ат исә машинасына утырып китәм дигәндә генә башын тәрәзәдән чыгарды да:

– Ә-ә!!! Карале син аны, ә?! Онытa яздым әйтергә: хуҗа бит заказын бераз үзгәртергә кушты! – дип кычкырды.

– Н-ничек… үзгәртергә?.. – дип сорады Фәһим, күкрәк төпкеленнән гырылдап чыккан үз тавышын танымыйча.

– Менә бүген иртән башына шундый фикер килгән: бер зур чүлмәк урынына ике кечкенәне ясарга, диде! Кыскасы ташны урталай кисеп, нәкъ рәсемдәгечә ике кечкенәрәк чүлмәк ясарга кушты хуҗа! Аңладыңмы?

– Аң…ладым…

– Башына нинди тай типкәндер – анысын әйтә алмыйм, ләкин хуҗа сүзен үтисе! Дав-вай, брат, уңышлар!

Көпчәкләре астындагы юл тузанын тузгытып, иномарка капылт кузгалып китеп барды. Сүзсез-хәрәкәтсез басып калган Фәһим исә «аңына» килгәч, әүвәл борын астыннан гына «сүбехәәәнәллаһ…» диде, аннан: «Мә шәә Аллаһ, әлхәмдүлилләһ!» – дип кычкырып куйды. Ишегалдына кергәч тә ул капканың эчке ягында басып торган хатынын күргәч: «Кабул булды бит догабыз, бичә, кабул булды!!!» – дип аны кулына күтәреп, әйләндерергә тотынды. «Ишеттем, барысын да тыңлап тордым! Ур-рра!!!» – дип кычкырып, Зәлифә шатлыклы көлә башлады.

– Нәрсә – әллә сират күперен кичтегезме? – дигән тавыш ишеткәч кенә туктап, алар киртә аркылы аларга карап торган Хисамны күреп алдылар.

– Ә-ә, күрше!.. – диде Фәһим йөзеннән сөенечле елмаюның югалтмыйча. –Алай ук булмаса да, зур бәладән имин булдык! Фәкать Аллаһының олы рәхмәте белән!

– Ну-ну… Алай булгач, коймак белән чәй эчертәсез инде…

Өлкән яшьтәге әнисе белән кергән күршене сыйлаганда алар ихлас дога кылуның, намаз укуның файдасы турында бер-берсен бүлә-бүлә сөйләделәр. Ахырда күрше апа ризыкка дога кылганда, шундый теләк теләде:

– Таңнар бәхет белән тусын, ил-көннәребез тыныч булсын, җаннар иман белән тулсын, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын…

*Ришат Курамшин,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*